А. Г. ЯХИН
Әдәбият
5

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

5



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

мәгънә

каршылык

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

Татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен дәреслек

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән

Дүртенче басма

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2011

УДК 373.167.1:821.512.145*05
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Я89

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Яхин, А. Г.

Я89 Әдәбият : татар телендә төп гомуми белем бирү мәкт. 5 нче с-фы өчен д-лек / А. Г. Яхин.— 4 нче басма.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2011.— 239 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-02076-3

УДК 373.167.1:821.512.145*05
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721

ISBN 978-5-298-02076-3

© «Мәгариф» нәшрияты, 2005, үзгәрешләр белән
© Татарстан китап нәшрияты, 2011

КЕРЕШ

Әдәби әсәрне вакыт үткәрү өчен генә дә, укы дип кушканга күрә дә укыйлар. Тукта әле, моның ахыры ничек бетәр икән дип кызыксыну — әдәби әсәрне ярата башлау дигән сүз.

Әдәби әсәр ул — язучының үз укучысы белән сөйләшүе. Язучы миңа, укучысына, нидер әйтә, мин аны йә аңлыйм, йә аңламыйм. Аңламасам, шигырь яки хикәяне укый белгәнгә күрә, укырга кирәк булганга күрә генә укыйм. Аңласам, аңлый алуыма шатланып укыйм.

Язучы әйтәсе килгән сүзен ничек әйтә соң?

—Ничек булсын, сөйләм теле белән. Татар кешесе үз телендә аңлаша алмыймы әллә?Әсәрнең теләсә кайсысын укып кара — барысы да аңлаешлы тел белән язылган бит,— диярсез.

Анысы шулай. Әдәби әсәрләр без барыбыз да сөйләшә торган тел белән языла. Язучы, телгә баерак булган саен, яхшырак яза. Ләкин әле әдәби әсәрнең үз теле дә бар.

Әйе, әйе, әдәби әсәрнең аны әсәр итә торган үз теле бар. Әдип безнең белән, ягъни үзенең укучылары белән, сөйләм телендә дә, әдәбиятның үз телендә дә сөйләшә. Сөйләм телен аңлаган укучы әдәби әсәрне кызыклы бер вакыйга итеп кенә кабул итә. «Бу тормышта ниләр генә булмый!» — дип, башын да кашып куя.

Әдәби әсәрләр телен аңлаган кеше өчен әсәр эчендә әллә никадәр хәзинә ята. Язучының нәрсә әйтергә теләвен аңлау — үзе бер ачыш ул. Ачыш булмыйча, әдәби әсәр теле андагы фикерне бервакытта да ахырынача әйтеп бетерми бит. Язучының хикмәтле теле шул фикерне табар өчен шартлар гына тудыра. Ә мин, әсәрне укыганда, әдипнең табышмагын укып барам, шунда ук аны чишәм дә. Язучы миңа шартларын куя бара, мин аны үтим. Үзем язучы кебек акыллы кеше белән иркенләп сөйләшә алуыма шатланып туя алмыйм.

Әдәбият телен аңлый белгән кешегә, ул — уку культурасын өйрәнгән кеше, диләр. Уку культурасын өйрәнгән кеше — бәхетле кеше. Чөнки ул үзе күргәннәрне, үзе уйлаганнарны, үз күңеленнән кичергәннәрне белү белән генә чикләнми. Язучы кайгысы белән кайгыра, аның шатлыгы белән шатлана, аныңча

уйлый ала. Хәзер ул кешеләрнең фикер матурлыгына соклана ала. Әдәбият телен өйрәнсә, билгеле.

Әдәби әсәр кадакланган агач тартма кебек. Тартманы тегеләй әйләндереп карыйсың, болай әйләндереп карыйсың — барыбер агач тартма. Ә эчендәниләр генә юк! Ләкин анда ниләр барын каян белергә? Моның өчен ким дигәндә бер тактаны каерып ачарга кирәк. Тактаны болай гына ачып булмый, нинди дә булса корал кирәк.

Әдәби әсәрнең эчендә ниләр барын белер өчен дә, корал кирәк. Әсәр телен белү — әсәр тактасын каерып ача торган корал ул.

Быелгы дәресләрнең барысы да бәя бирү темасына багышлана. Бу тема 11 нче сыйныфка кадәр дәвам итәчәк, чөнки матур әдәбиятның төп гамәле — бәя бирү. Быел без бу гамәлнең гаргади алымнарын һәм максатын өйрәнәбез. Чагыштыру да, каршылык та, сыйфат дәрәҗәсен билгеләү дә, кабатлау да, мәгънә табу да — бәя бирү чаралары гына.

Сез быел да, алдагы елларда да әсәр телен аңларга өйрәнәчәксез. Бу — бик кызык шөгыль. Әсәр телен белгән кеше мөстәкыйль фикер йөртергә, мәкалә, хикәя, шигырь, повесть язарга өйрәнә.

Хикәяләр, шигырьләр язган кеше язучы була бит инде, диярсез. Ә сез язучыларны күктән төшкән дип уйлыйсызмы әллә? Алар да кечкенә чакта, сезнең кебек, мәктәптә укыганнар. Сез дә, алар кебек үскәч, язучылар, инженерлар, җир белгечләре... тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр булырсыз. Әмма, кем генә булсагыз да, матур әдәбият укуны дәвам иттерерсез. Матур әдәбиятны укымаган кеше юк ул.

Ләкин ничек укыячаксыз? Кеше укый дипме, укый белгәнгәме, тукта эле, моның ахыры ничек бетәр икән дип кызыксынгангамы? Әллә аңлапмы?

БӘЯ

БӘЯ БИРҮ ЫСУЛЛАРЫ

Борынгы заманда Италиядә бик мәшһүр Галилео Галилей дигән галим яшәгән. Көннәрдән бер көнне ул үзенең укучыларын су буена алып килгән. Аягы белән комга бер сызык сызган да:

— Комны сөртмичә, шушы сызыкны кыскарта аласызмы? — дип сораган.

Мәшһүр галимнең акыллы укучылары уйга калганнар. Комдагы сызыкның әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып караганнар. Алай да кыскарту юлын таба алмаганнар. Аннары галим сызыгын үзе кыскартып күрсәткән. Укучылар мәсьәләнең шулай җиңел чишелүенә шаккатканнар.

Биремнәр һәм сораулар

1. Галим соравына җавап бирегез.
2. Сызыкны дәвам итмичә озынайтыгыз.
3. Сызык озынмы, кыскамы?
4. Сызыкны таяк дип уйласак, таяк яхшымы, начармы?

Сорауларга җавап биргәннән соң, түбәндәге **нәтиҗәләргә** киләбез:

1. Әйбергә бәя бирү өчен, аны башка нәрсә белән чагыштырып карарга кирәк.
2. Әйбер бер үк вакытта озын да, кыска да була ала. Икенче төрле әйткәндә, ул үз-үзенә каршылыкта тора.
3. Әйбернең озынлыгын, төсен, катылыгын; кешенең акыллылыгын, көчлелеген, кайгысын һәм башка шуңа охшашлы якларын бер сүз белән «әйбернең яки кешенең **сыйфаты**» диләр. Сыйфатның төрле куәтлелектә булуына **«сыйфат дәрәҗәсе»** диләр. Сыйфат дәрәҗәсен бәяләү нәтиҗәсендә генә белеп була.

4. Бер эчтәлектәге әйберләрнең күплегенә **«кабатлау»** диләр.

5. Әйберләрнең, күренешләрнең безгә кирәк ягына **«мәгънә»** диләр.

ЧАГЫШТЫРУ ЮЛЫ БЕЛӘН БӘЯ БИРҮ

Шәүкәт Галиев

Кем белә?

Чыккач чаңгы
Шуарга,
Гаҗәпләндем
Шуңарга —

Иң беренче
Кигәндә,
Озын иде
Миннән дә.

Ел да чаңгым
Кыскара!
Ышанмасаң,
Дус, кара:

Аннан булды
Борыннан,
Инде күкрәк
Турыннан...

Кыскарырмы
Гел генә,
Кем әйтәлә,
Кем белә?

Бирем һәм сораулар

1. Чагыштырылучы якларны табыгыз.
2. Шигырьдәге вакыйгага кемнәр, нәрсәләр катнаша?
3. Кемнәргә бәя бирелә?
4. Нинди бәя бирелә?

Ә хәзер белемегезне сынап карагыз. Ике мәзәкне укып чыгыгыз. Сораулар белән танышкач, ашыкмыйча, тагын бер кат укыгыз. Уйлагыз.

1 сорау. Мәзәкләрдә чагыштыру бармы? Җавабыгызны дәлилләгез.

2 сорау. Мәзәкләрдәге чагыштыруларның охшашлыгы бармы? Булса, кайсы яклары белән охшауларын аңлатыгыз.

3 сорау. Чагыштыру аша нәрсәгә нинди бәя бирелә?

Бәхетле

(Халык мәзәге)

Бер ярлы күршесендәге ярлыга кергән дә:

— Хәлләр ничек?— дип сораган.

— Хәл начар,— дигән хуҗа,— бүген ач утырам, авызга кабарга бер бөртек икмәгем юк.

— Алайса, син бәхетле икәнсең әле,— дигән күршесе,— минем дә бер бөртек ипием юк. Ләкин миңа иртүк кунак килде.

Балыкчы

(Халык мәзәге)

Бер кеше балык тотып утыра икән. Дусты килә. Күрә: аның бер балыгы да юк.

— Хәлләр ничек? — дип сорый дусты.

— Әйбәт,— дип җавап бирә балыкчы.

— Ничек әйбәт булсын, бер балыгың да юк бит? — дип сорый дусты...

Бирем

Мәзәк тәмамланмады. Ахырын уйлап табыгыз. Балыкчы үз эшенең яхшылыгын ничек исбат итә ала?



Бирем

Рәсемне яхшылап өйрәнегез. Шул рәсемдәге вакыйгадан файдаланып, кыска гына хикәя языгыз. Хикәя каршылыкка корылырга тиеш.

Нәтиҗәләр:

1. Бер үк таяк озын таяк белән чагыштырганда кыска була, кыска белән чагыштырганда озын була. Димәк, чагыштыру юлы белән бер үк нәрсәне ике итеп була икән.
2. Таякны озын да, кыска да итеп бәяләсәк, аны үзенә-үзен каршылыкка китердек, диләр.
3. Чагыштырып бәя бирү алымы белән шигырьләр язалар, мәзәкләр уйлап табалар. Чагыштыру юлы чаңгыны да, кешенең хәлен дә каршылыкка китерә.
4. Чагыштыру юлы белән иң бәләкәй нәрсәне дә тагын да бәләкәйрәк итеп була. Иң озын әйберне дә тагын да озынрак итеп була. Яхшы — начар, начар яхшы була ала.

Габдулла Тукай

Баскыч

Сөялгән, өй түрендә бар иде гаять тә зур баскыч,
Кырыклап басмасы бар — бик авыр һәм дә озын баскыч.

Кирәклектә бәрабәр булсалар да басмалар бергә,
Югаргы басма тиңләшми түбәнге басмалар берлә.

Югаргы басма мәгърур: «Мин югары, сез түбәнсез, ди,
Ничек гали минем урным, түбәнгеләр, күрәмсез?» — ди.

Бер адәм килде дә шул чакта, әйләндерде баскычны:
Түбәнге басмалар менде, югаргысы түбән төште.

Биремнәр һәм сораулар

1. Габдулла Тукай турында кем нәрсә белә, сөйләгез.
2. Шигырьдә чагыштыру юк, әмма бер үк әйбер барыбер үзенә үзе каршы китерелгән. Нәрсә үзенә үзе каршы китерелгән? Нинди юл белән?
3. «Баскыч» шигыре белән Габдулла Тукай безгә ниләр әйтә? Үз сүзләрегез белән сөйләгез.

Нәтиҗә:

Әйберне башка юллар белән дә каршылыкка китереп була икән.

КАРШЫЛЫК

Бернәрсә икенчесенең киресе булса, алар каршылыкта торалар, диләр. Мәсәлән, ак белән кара, озын белән кыска, акыллы белән тиле, ялкау белән эшчән, юмарт белән саран янәшә торсалар, алар **каршылыкта** торалар. Күрәсез, янәшәдә торсалар, дидек. Димәк, алар бер-берсе белән сугышмыйлар, бер-берсен мыскыл итмиләр.

Инде каршы яклар тату гына яши алмасалар, үзара ызгышсалар, каршылык бетә. **Конфликт** башлана.

Конфликт дип әсәр персонажларының бер-берсе белән көрәшенә әйтәләр.

Ә **персонаж** дип әсәрдә катнашучыларга әйтәләр.

Каршылык та, конфликт та әдәби әсәрне ике өлешкә бүләләр. Без аларны **каршы яклар** дибез. Әдәби әсәрнең күбесе каршылык белән конфликтка корыла.

Әйдәгез, каршылык ясалу ысуллары белән танышыйк.

Шәүкәт Галиев

Чабалар

Исхак та чаба,
Мисбах та чаба.
Берсен зурлыйлар,
Берсен хурлыйлар.

Исхакта чалгы —
Болында чаба.
Ә Мисбах бушка
Урамда чаба.

Бирем һәм сораулар

1. Үзенә үзе каршылыкта торган сүзне табыгыз.
2. Шигырьдә чагыштыру бармы?
3. Кемгә ничек бәя бирелә?

Шәүкәт Галиев

Атлап чыктым Иделне

Сызгандым да балакны,
Таяндым да таякны,
Атлап чыктым Иделне.
«Булмас, булмас»,— дисеңме?

Кем ялган сөйли, минме?
Чын-чынлап чыктым инде;
Нәни иде Иделе —
Башланган җире иде.

Бирем һәм сораулар

1. Иделне атлап чыктым дип Шәвәли алдыймы, юкмы?
2. Каршылыкка килгән сүзне табыгыз.

3. Шигырьдән чыгып, малайның нинди сыйфатларын әйтә аласыз?
4. Каршылык малайга бәя бирергә булышамы?

Хәйләкәр әтәч

(Әкият)

Борын-борын заманда бик матур, бик батыр бер Әтәч булган. Әтәч бервакыт, урамда йөргәндә, алтын балдак таба да муенына кия. Моны бер бай, күреп:

— Алтын балдагыңны бер атнага миңа биреп торсаң, мин сиңа тары бирәмен,— ди.

Әтәч тиз күнә. Байга бер атнага балдакны биреп, тары алып кайтып китә.

Бер атна үткәч, Әтәч байдан барып балдакны сорый, ә бай бирмичә куып чыгарып җибәрә. Әтәч, ике көн үткәч, бай янына тагын бармакчы була. Бара-бара Әтәчкә бер зур Аю очрый.

— Әтәч, кая барасың? — ди.

— Мин байга алтын балдагымны сорарга барам,— ди Әтәч.

— Алтын балдак тапкан идем. Бай шуны алдалап алды.

— Мин дә барыйм әле,— ди Аю.

— Әйдә, кер эчкә,— ди Әтәч.

Аю Әтәчнең авызыннан эчкә керә. Тагын китә бу, барабара Бүре очрый моңа. Шулай сөйләшкәннән соң, Бүре дә Әтәч эченә керә. Әтәч тагын үз юлына китә. Шуннан Әтәчкә Төлке очрый. Төлке дә, Әтәч белән сөйләшеп, шулай ук Әтәчнең эченә кереп, Әтәч белән китәләр.

Байга барып җиткәч, Әтәч капка башына менә дә:

— Бай абый, алтын балдакны бир! — дип, берничә мәртәбә кычкыра.

Бай, хезмәтчеләренә әйтеп, Әтәчне тотарга куша. Әтәчне тотып, атлар тибеп үтерсен дип, атлар абзарына ябалар. Әтәч, абзарга ябу белән:

— Аю, чык эчтән! — ди.

Аю, чыгып, бөтен атларны кыйнап үтерә дә Әтәч эченә яңадан керә.

Икенче көнне, казлар талап үтерсен дип, Әтәчне казлар янына ябалар. Абзарга ябу белән, Әтәч:

— Төлке, чык эчтән! — ди.

Төлке, Әтәч эченнән чыгып, бөтен казларны үтереп ашап бетерә дә Әтәч эченә керә...

Болай да булмагач, өченче көнне Әтәчне сарыклар, тәкәләр абзарына ябалар. Ябу белән, Әтәч тагын:

— Бүре, чык эчтән! — ди.

Бүре, Әтәч эченнән чыгып, бөтен сарыкларны буып үтерә дә Әтәч эченә керә.

Инде болай булмый икән дип, Әтәчне дүртенче көнне коега ташлыйлар. Коега төшү белән, Әтәч:

— Су, кер эчкә! — ди. Коедагы бөтен су Әтәч эченә кереп бетә. Әтәч үлми кала.

Бишенче көнне, мичкә бик көчле ягып, янып үлсен дип, Әтәчне мичкә аталар. Әтәч, мичкә керү белән:

— Су, чык эчтән! — ди.

Су, Әтәч эченнән чыгып, мичне сүндерә дә яңадан Әтәч эченә керә.

Болай да булмагач, шул көнне, пешереп ашарга дип, Әтәчне казанга салалар. Казанга салгач, Әтәч:

— Су, чык эчтән! — ди.

Бөтен кое суы Әтәч эченнән чыгып кайнап торган казанны суындыра. Су казаннан ташып учакка керә, учакны сүндерә. Шуннан соң Әтәч:

— Аю, Төлке, Бүре, чыгыгыз эчтән,— ди.

Аю, Бүре, Төлке, чыгып, байны гаиләсе белән кыйнап ташлыйлар. Балдакны, байның бөтен малын алып, көлешә-көлешә кайтып китәләр, ди.

— Менә, алтын балдакка кызыксаң, шулай була ул,— ди Әтәч.

ӘКИЯТТӘГЕ КАРШЫЛЫКЛАР

Әкияттәге төп каршылык сюжетта.

Әдәби әсәрләрдәге, әкиятләрдәге вакыйгаларның берберсенә ялганып баруына **сюжет** диләр.

Сюжетның башында бай үзеннән көчсез Әтәчне рәнҗетә: аның байлыгын алдап ала. Сюжет ахырында Әтәч дуслары ярдәмендә балдагын кире кайтара, ләкин аның белән генә дә канәгатьләнми, үзен рәнҗетүчегә җәза бирә һәм, балдакка өстәп, аның бөтен байлыгын алып кайта.

Вакыйгалар каршылыгына игътибар итик: бай байлык ала — байның байлыгын алалар.

Нәтиҗә:

Әкиятләрнең күбесе шундый каршылыкка нигезләнгән. Башында ни әйтелсә, әкият ахырында шуның киресе була.

Әкияттә тагын бер вакыйга бар. Әтәч дусларын йота, кирәк чакта чыгара да тагын йота.

Бу вакыйганың каршылыгы — Әтәчнең үзеннән зур Аюны, Бүрене һәм башкаларны йотып, кирәк чакта чыгаруында. Бу хәл чынбарлыкта була алмый, шуңа күрә бу вакыйганы чынбарлык белән каршылыкта тора, дибез.

Әкиятләрнең тагын бер сыйфаты: аларның күбесе дөньяда була алмый торган вакыйгалар турында сөйлиләр. Шуңа күрә аларга **тылсымлы әкиятләр** диләр.

Ә хәзер сюжет каршылыгын искә төшерик. Бу каршылык ярдәмендә Әтәч үзеннән көчле байны җиңде. Башка әкиятләрдә дә һәрвакыт көчсез җиңеп чыга, чөнки ул хаклы була. Димәк, барлык әкиятләрдә дә хаклык һәрвакыт җиңеп чыга.

Хаклыкны яклавы һәм дөньяда булмаган нәрсәләр уйлап чыгарганы өчен без әкиятләрне яратабыз.

Төлке белән торна

(*Әкият*)

Торна белән Төлке дус булдылар, ди, ашка дәшештеләр, ди. Әүвәле Төлке дәште, ди. Тары боткасы пешерде, ди. Тары боткасын карбыз турый торган сай гына табакка состы, ди. Торнаны дәшеп килде, ди.

— Аша, кунак,— дип әйтте, ди, Төлке. Торна «тук» иттереп чукый, ди, бер ярма да эләкми, ди. Төлке үзе ялап кына ала икән. Шуннан Торна әйтте, ди:

— Төлке дус, син сыйладың, инде мин сине сыйлармын. Чакыргач барырсың,— дип әйтте, ди.

Торна пешерде, ди, сөтле чумар. Аны состы, ди, гөбегә. Килеп дәште, ди, Төлкене кунакка. Төлке китте, ди, кунакка. Ашарга утырдылар, ди. Төлкенең авызы шулпага гына җитте, чумарга җитми, ди. Торна үзе «тук» иттереп чумарын гына эләктереп ала, ди.

Шуннан әйтте, ди:

— Төлке дус, син дә сыйладың, мин дә сыйладым, бик рәхмәт,— дип әйтте, ди.

Биремнәр һәм сораулар

1. Әсәрне өлешләргә бүлегез. Ни өчен шулай бүлүегезне аңлатыгыз.
2. Төлкегә һәм Торнага бәя бирегез.
3. Әкият безгә нәрсә турында әйтә? Ни дип кисәтә?

Әләкче

(*Әкият*)

Бервакыт Арыслан киек авырый башлаган. Барча җанвар, киек хайваннар Арысланның хәлен белергә килгәннәр. Монда бары Төлке генә булмаган. Бүре Арыслан патшага әйткән:

— И патша, хәл белергә килү түгел, Төлке сине патша дип тә белми,— дигән.

Ул арада Төлке дә килеп җиткән. Арыслан, Төлкене күреп, бик каты кычкырган:

— Әһә, син шулай икәнсең әле, мине патша дип тә белмисең икән,— дигән.

Төлке әйткән:

— И солтаным, сүземне әйтергә рөхсәт бирсәнә,— дигән.— Мин шуның өчен соңга калдым: синең авырганыңны ишеткәч, доктор эзләп төрле якларга чабып йөрдем. Әмма дәва тапкач килдем,— дигән.

Арыслан әйткән:

— Нинди дәва таптың соң? — дигән...

Бирем

Әкиятне дәвам итегез.

Иҗади эш

Әйдәгез, хәзер әкиятне үзебез уйлап чыгарыйк. Әкиятне «Төш» дип атыйк. Без хәзер әкиятләрдә тылсым, ягъни адәм ышанмаслык вакыйга һәм сюжеттагы каршылык булырга тиешлеген беләбез. Башта адәм ышанмаслык вакыйга уйлап табыйк.

Борын-борын заманда бер кеше төш күргән. Төше үзенә бик ошаган: ике җилкәсенә ике сандугач кунып сайраган. Шатлыгын кемгә әйтергә инде дип, өеннән чыгып киткән. Бара бу кеше юлдан, бара, моңа бер көтүче очрый.

— Бик матур төш күрдем бүген, ике җилкәмә ике сандугач кунып сайрады,— дигән теге кеше...

Күрәсез, моңа кадәр һич тә искитәрлек вакыйга булмады. Кеше кешегә төшен сөйләми тормый инде. Шуңа күрә безгә нинди дә булса әкәмәт уйлап чыгарырга кирәк. Әһә, менә ул:

— Сат төшеңне,— ди кетүче.

— Сатмыйм. Үземә дә бик кадерле. Минем үз гомеремдә андый төш күргәнем юк иде,— ди әлеге кеше.

Уңайлык өчен, әйдәгез, төш күрүчегә бирәр исем бирик. Кызыграк исемне үзегез уйлап табыгыз. Дөньяда булмаган исем дә әкият язу шартына туры килә бит. Бу кешеләр озак сатулашалар. Сатулашулары турында да үзегез языгыз. Алай да әлеге кеше төшен сатмый. Әллә сатамы?Сатмаса, ул тагын юл буйлап китә. Бара, бара, бер балыкчыны очрата... Аның белән дә сатулаша. Балыкчы да төшне сатып алмакчы була. Төшне аңарга да сатмый. Ә көннәрдән бер көнне сандугачлы төш турында патшага әйтәләр. Билгеле инде, патша төшне алдашып-йолдашып та, талап та, хәйләләп тә ала ала. Ничек ала?Анысын да уйлап табыгыз.

Әкиятнең беренче өлеше шундыйрак булырга тиеш. Һәрхәлдә, сез язып бетергәч, беренче өлеш туа.

Ә икенче өлеш нинди булырга мөмкин? Нинди? Йә?

Кем ничек уйлап тапса, шулай языгыз.

Ябалак

(Әкият)

Ябалак бер Чыпчык тотты, ди. Чыпчык Ябалактан сорады, ди:

— Үлгәнче синең исемеңне белеп калыймчы, син кем буласың?— дип әйтте, ди.

Ябалак, авызын зур ачып:

— Ябалак! — дип кычкырган иде, ди, Чыпчык чыкты да ычкынды, ди.

— Аһ,— дип әйтте, ди, Ябалак,— авызымны ачмыйча, «ябәләк» дип кенә әйтәсе калган, ул чагында ычкына алмаган булыр иде.

Биремнәр һәм сораулар

1. Бу әкияттә каршылык бармы?Булса, аны каршылыклы якларга аерыгыз.

2. Әчтәлеген тагын да кыскарак итеп, әйтик, бер генә җөмләгә калдырып әйтегез.

3. Бу кечкенә генә әкият ябалак турында түгел бит инде? Кеше турында дияр идегез, ул да тулы җавап түгел. Борынгылар бу әкиятне ни өчен уйлап чыгарганнар?

Акыллы килен

(*Әкият*)

Бер картның булган икән, ди, өч килене. Карт киленнәрен сынамакчы булган. Олы килененнән:

— Йә килен, әйтерсең микән син миңа, дөньяда нәрсәнең тавышы иң еракка ишетелә?!— дип сораган.

— Минемчә, әткәй, кыңгырау тавышы еракка ишетелсә кирәк,— дип җавап биргән өлкән килене.

— Яхшы, килен, бик күркәм җавап бирдең,— дигән карт. Аннары икенче киленне чакырган:

— Йә килен, әйтерсең микән син миңа, бу дөньяда нәрсәнең тавышы еракка ишетелә?— дигән.

Бу килене уйлап-уйлап торган да әйткән:

— Минемчә, әткәй, аккош тавышы еракка ишетелә булса кирәк,— дигән.

— Яхшы, рәхмәт, киленем,— дигән карт. Инде карт өченче — кече киленне чакырткан. Аңа да шул ук сорауны биргән: — Дөньяда нәрсәнең тавышы еракка ишетелә?— дигән.

Бу килене әйткән:

— Минемчә, әткәй, дөньяда ризык тавышы бик еракка ишетелә,— дигән.

— Ничек ул алай?

Килене әйткән:

— Бер кешене чын күңелдән кунак итсәң, ул кеше, ун мең чакрымнар еракка киткәч тә, сине исенә төшереп сөйләр, беркайчан да онытмас,— дигән.

Картка моның җавабы бик ошаган.

Биремнәр һәм сораулар

1. Әкиятне каршы якларга болай бүлеп була: бер якта кече килен, ә икенче якта башка киленнәр, дибез. Ни өчен ике киленне бер өлешкә керттек, ә икенче өлештә кече килен генә калды?
2. Бик кыска итеп, әкиятнең нәрсә турында булуын әйтеп бирегез.
3. Карт тавыш турында сорады, ә кече килен ипи турында әйтте. Ни өчен шулай итте?

Габдулла Тукай

Күгәрчен

Бер урманда агач астында яшьрен,
Качып утра иде мискин Күгәрчен.

Якыннан шул вакытта узды Лачын,
Җәеп, селкеп канат атлы колачын.

Әченнән сөйләде шунда Күгәрчен:
«Бу Лачын нинди көчле кош, күрәмсең?

Көче күп, тырнагы үткен, явыз ул,
Зәгыйфьләрне ашар, канлы авыз ул.

Вәләкин мин ризамын язмышымнан,
Ходай кыйлган мине көчсез кошыннан:

Зәгыйфь, корбан булу артык, Ходаем,
Булудан андый көчле һәм дә залим!»

Биремнәр һәм сораулар

1. Чагыштыручы якларын аерып, әсәрне икегә бүлегез. Ни өчен шулай бүлүегезне аңлатыгыз.
2. Шигырьдә ничә чагыштыру бар? Ничә каршылык бар?
3. Бу әсәр нәрсә турында? Үз сүзләрегез белән әйтегез.

Габдулла Тукай

Таз

(*Бер авыл малае авызыннан*)

Мәдрәсәдә бар иде бер Таз малай,—
Бик шаян, шуклык белән мөмтаз[1] малай.

Бик тирән — башындагы каткан бүрек,
Бер дә салмый, булмый һич башын күреп.

Кайсы чакта бүркен алып ташлыйлар:
«Әй, кояш чыкты! Кояш чыкты!»— диләр.

Ул заман без барчамыз бик кечкенә,
Зурымызга яшь булыр унөч кенә.

Башчыбыз Таз, берзаман без уйнадык;
Һичберәү күрмәс әле дип уйладык.

---

[1]*Мөмтаз* — аерылып тора торган.

Аһ, бәла! безне казый күргән, имеш,
Уйнаганны ул карап торган, имеш.

Кәйфемезне бик тиз үк кыскартты ул,—
Безне шул чактук хөкемгә тартты ул.

Куркышып, казыйга тезләндек хәзер,
Төрле юл котлырга эзләндек хәзер.

«Казый абзый! Безне син кызган»,— димез;
«Һәр усаллык башы шул Таздан»,— димез.

«И кизү! Бар, тиз китер, ул кайсы Таз?
Мин башын кашыймчы ул Тазның бераз».

Килде Таз. Без тик торабыз куркышып, —
Барчамыз бертөрле хәсрәткә төшеп.

Кушты казый: «Ят! Сузыл! И Таз пәри!
Тал чыбыктан сез котылмассыз әли!»—

Дип, казый безне дә куймый шелтәли;
Шул вакытта Тазга талны селтәде.

Бер-ике сукты казый, — бу нинди эш?
Бер дә чаж-чож итмидер суккан тавыш.

Нәрсәдер бар монда — бер алдау эше,
Ишетеләдер каты нәрсә тавышы.

Нәрсә бар? Таз аркасында нәрсә бар?
Камзулын Тазның күтәреп баксалар:

Хәйлә иткән монда да ул Таз-явыз,—
Белмәгә мөмкин рәсемгә баксагыз.

Казый абзый куйды шаркылдап көлеп,
Гайрәте сүнде, кызык эшне күреп.

Безне гафитте[1] сугалмый калды ул,
Тал чыбыкка яткыралмый калды шул!

Биремнәр һәм сораулар

1. Шигырьдә Габдулла Тукай Тазны яманлыймы, мактыймы?
2. Шагыйрь шәкертләрне яманлыймы, мактыймы?
3. Казый ни өчен Тазны гафу итә?

---

[1] *Гафитте* — гафу итте.

4. Шигырьдә Габдулла Тукай чагыштырам дими, чагыштырыгыз дими. Алай да анда чагыштыру бар, һәм нәкъ менә шул чагыштыру каршылык тудыра да инде. Шул каршылыкны табыгыз.
5. Каршылык табылгач, шәкертләргә дә, Тазга да бәя бирү җиңел. Хәзер башта аларга биргән бәягезнең дөреслеген тикшерегез.

МӘГЪНӘ

Мәгънә дип әйбернең безгә кирәк ягын әйтәләр. Беренче дәрестә таякларны үзара чагыштырганда:

— Бу таякларның кайсы яхшырак?— дип сорау биргән идек.

— Ул таяктан нәрсә ясыйсың бит! Орчык ясар өчен таякның кыскасы яхшырак, чаңгы таягы өчен — озыны,— дигән җавап дөрес дип табылган иде. Таякның безгә кирәк ягы аның мәгънәсе була. Ә таяк үзе — таяк, әйбер булып калуында дәвам итә.

Күрәсез, әйбернең мәгънәсе аны икегә бүлә. Мәсәлән, таякны хәзер таяк дип тә, орчык, чыбыркы сабы дип тә әйтергә мөмкин.

Мәгънәнең әйберне икегә бүлүе шулай ук әсәрләрдә каршылык тудыру алымы буларак файдаланыла.

Әдәби әсәрләрдә без адым саен нәрсәнендер мәгънәсен табарга тиеш булабыз. Гадәттә, мәгънә әсәрдә әйтелми. Ул өлешләрнең бәйләнеше аша табыла. Ләкин өлешләрне без йә чагыштыруларны, йә каршылыкларны, йә сыйфат дәрәҗәләрен бүлеп табабыз. Димәк, мәгънә табуда бәя бирү чараларының без белгәннәре барысы да катнаша дигән сүз.

Мәгънәсе табылырга тиешле урын — әдәби әсәрнең иң мөһим урыны. Шуның өчен андый урынны язучы йә кабатларга тиеш була, йә әсәренең исеменә чыгара, яисә мөстәкыйль бер вакыйга итеп язып куя. Гадәттә, андый вакыйга әдәби әсәрнең башына языла. Шулай булгач, әсәрне укыганда ук, мәгънәсен табу өчен, әсәрнең исеменә, кабатлауларга һәм әсәр башындагы мөстәкыйль вакыйгага игътибар итәбез. Андый урыннарны эзли башлыйбыз.

«Акыллы килен» экиятендә еракка ишетелә торган тавышның мәгънәсе — кешегә ясаган игелек. Кече килен тавышка мәгънә биреп отты.

Шәүкәт Галиев

Надан

Укып карыйм уңнан, сулдан,
Укып карыйм яңадан;
Кайсы яктан карасаң да,
Н а д а н барыбер н а д а н.

Зариф Бәшири

Яхшылык

Яхшылык — яңа савып куйган күбекле сөт эле;
Каймагы өскә чыгар тиз, сабырлан, көт әле.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьләрнең кайсысында каршылык бар, кайсысында юк? Табыгыз.
2. «Надан» шигырендә сүз нәрсә турында бара?
3. Бу дүртьюллыкта нәрсә үз-үзе белән каршылыкка килә?
4. «Надан» сүзе надан кешегә кайсы ягы белән охшаган?
5. Бу кыска шигырьдә «надан» сүзе үзенә үзе каршылыкка килә. Ягъни ике мәгънәгә аерыла. Ләкин бу каршы яклар шул ук вакытта бергә дә кушылалар. «Надан» сүзенең ике мәгънәсен нәрсә куша?
6. «Яхшылык» шигырендә сөт яхшылыкның кайсы ягын ача?

Дәрдемәнд

Богдай

Бер игенче, сигез яшендәге углы Хөсәенне янына алып, игеннәрнең ни хәлдә икәнен күрер өчен басуга китте. Юлда бер игенлеккә очрадылар, богдайларның барысы да башларын җиргә карап игәннәр, арада берничәсе генә, башларын югары күтәреп, теп-текә торалар иде. Хөсәен бу хәлне искәрде. Әтисенә әйтте:

— Әти! Карачы бу богдайларны: мискиннәр! Ничек муеннары бөгелгән... Машалла, әнә тегеләре! Нинди теп-текә, егет сыман торалар!

Атасы атны туктатты. Арбадан төшеп, богдайларның ике төрлесеннән дә өзеп алды. Бөртекләрен чыгару өчен башакларын учлары эчендә угалады. Шуннан Хөсәенгә әйтте:

— Кара, углым! Боларның эчендә никадәр күп богдай бар! Менә шуның өчен дә боларның башлары иелгән... Инде шул

текә торганнарына кара — эчләрендә бер әйбер дә юк! Болары бер тиен дә тормый. Моннан гыйбрәт ал, улым: текә башлы булу гакылсызлыктан килә.

Биремнәр

1. Хикәяне каршы якларга бүлегез.
2. Каршы якларның уртак, ягъни охшаш яклары бармы? Табыгыз.
3. Моңа кадәр без таякның, төлкенең, торнаның мәгънәсен таптык. Бу хикәядә дә бодайның мәгънәсе бар. Ләкин шуның өстенә бөтен бер вакыйга да башка мәгънә ала. Шул мәгънәләрне табып сөйләгез.

ӘЙТЕМНӘР

Әйтемнәрне халык иҗат иткән. Алар барысы да кыска, матур, хикмәтлеләр. Үзегез уйлап карагыз, өч-дүрт кешенең бер кашыктан ашавы әйбәтме, начармы? Ләкин дуслар турында: «Алар бер кашыктан ашыйлар»,— дип әйтсәң, бик яхшы була, чөнки дусларны мактаган буласың. «Алар арасына кыл да сыймый»,— дисәң дә мактыйсың. Шулай әйтү дөрес була. Ә бит дусларның бер-берсенә сыланып йөрмәгәнен бик яхшы белеп торасың. Әйбәт дус турында: «Көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың андый дусны»,— диләр. Ә бит көндез шәм яндырып эзләүнең мәгънәсезлеген һәркем белә. Берәү кирле-мырлы сөйли башласа, аның турында: «Тилебәрән орлыгы ашаган»,— диләр. Ә ул кеше тилебәрән орлыгын үз гомерендә күрмәгән дә булырга мөмкин.

Мисалга китерелгән әйтемнәр барысы да чагыштыруда катнаштылар. Нәрсә белән нәрсәне чагыштырдылар соң алар? Әйтемнәрнең үзләрендә дуслар дигән сүз дә, танышым дигән сүз дә юк бит?

Әйтемнәр кешенең көндәлек тормышында очрый торган вакыйгаларга бәя бирәләр. Димәк, әгәр дә мин ике дус танышым турында сөйлим икән, «Әмәк белән Шәмәк» кебек дим. Ягъни бик дуслар, дим. Шуңа күрә әйтемнәрнең эчтәлеге чын вакыйга белән янәшә куелганда гына ачыла.

Шул ук мисалларны без болай да әйтә алыр идек: «Алар шулкадәр якыннар: араларына кыл да сыймас кебек. Ул бүген кирле-мырлы сөйли, әйтерсең лә тилебәрән орлыгы ашаган». Калган мисалларны үзегез үзгәртеп карагыз.

Ә хәзер әйтем катнашкан вакыйга белән танышыйк һәм мондый сорауларга җавап бирергә тырышыйк:

Акыл өләшкәндә, мич башында ятып калган, ди әйтем. Ялкау кешегә шулай диләр. Бу кыска гына әйтемдә кешенең ялкаулыгы турында да, укырга иренеп надан калуы турында да әйтелә. Бу әйтем дә сөйләшкәндә бераүгә бәя бирә. Кемгә дә булса төбәп әйтмәсәк, «акыл өләшкәндә, мич башында ятып калган» әйтеме мәгънәсен югалта.

Сораулар

1. Әйтем ни өчен кирәк?
2. Ул үзенең эчтәлеген ничек ача?
3. «Араларына кыл да сыймый» әйтеме белән «әт белән мәче кебек яшиләр» әйтеме арасында нинди аерма бар?

Мирсәй Әмир

Агыйдел

(Өзек)

— Аркылы чыгабызмы?

— Чыгабыз.

Яр шактый ерак иде. Колач сала-сала беләкләр арыгач, сырт өстенә әйләндек. Аяк белән генә йөзеп кулларны, кул белән генә йөзеп аякларны ял иттерәбез. Шулай мәшәкатьсез генә йөзә-йөзә, икенче ярга шактый якынлашкан идек инде.

— Әйдә, тагын колач салабыз,— диде Гаяз, кинәт кенә талларга күмелгән ярга таба йөзе белән әйләнде. Ләкин шундый ук тизлек белән йөзеп китә алмады, кинәт тукталып, бөтенләй хәрәкәтсез хәлдә калды:

— Тукта!— дип пышылдады ул миңа.— Кара, кем бу? Нинди сын бу?

Көтелмәгәндә күз алдына килеп баскан бу гаҗәп күренешкә мин дә телсез калдым. Каршыбызда, акыл ирешә алмаслык сер булып, кыз басып тора иде.

Сораулар һәм бирем

1. Көтелмәгән хәл Гаязга ничек тәэсир итә?
2. Шул ук вакыйга Ильяска ничек тәэсир итә?
3. Кайсысына күбрәк тәэсир итә?
4. Гаяз белән Ильяс хисләрен бер сүз белән әйтегез.
5. «Телсез калдым» әйтеме нәрсәгә бәя бирә?
6. Бу әйтем үз эчтәлегеннән Ильяс хисенә нәрсә өсти?

Җаваплар табылгач, түбәндәге **нәтиҗәләргә** киләбез:

1. Вакыйгаларга бәя бирү өчен кеше хәтерендә махсус сурәтләр саклана. Сурәтләрнең берише — әйтемнәр. «Телсез калдым», «котым ботыма җитте», «бер кашыктан ашыйлар», «башым күккә тиде», «тилебәрән орлыгы ашаган» кебек **нинди дә булса сыйфатка чагыштырып бәя бирү өчен иҗат ителгән сүзтезмәләргә «әйтем» диләр.**

2. Әйтем тормыш вакыйгасының бер генә ягын — сыйфатын аерып ала һәм аның дәрәҗәсен күрсәтә.

3. Әйтем әйтүче, әйтемнән файдаланып, үзенең хисен белдерә.

4. Әйтемнәрне күп белүче кеше — бай кеше.

Мөстәкыйль эш өчен мисаллар

Галимҗан Ибраһимов

Безнең көннәр

(Өзек)

Габдрахманның йөзе-күзе ачылып китте.

— Әйтмә, иптәш! Минем тормыш ал да гөл кебек. Бары да майланган кебек, фатирдан да бик уңдым...

— Яшь кәләшнең кәефе яхшымы? Нәфисә исәнме?

— Әйтмә генә: ал да гөл кебек, пар күгәрченнәр кебек гөрләшеп торабыз. Тик ул сиңа бик үпкәли. Элекке танышлар әллә кая юк булды? Давыт абый да безне ташлады, ди... Син нигә бер дә кереп чыкмыйсың?..

— Әйтә күрмә, туганкай. Үземә дә бик уңайсыз. Эш баштан ашкан, бер минут вакыт табар хәл юк.

(Шул ук әсәрдән өзек)

Башкорт тилереп китте:

— Куй, куй! Ул ни эштәгәнең. Билет алмаек... Әйттем ги, аксаны янда калдыраек дип,— ди.

Мин дә күп вакыт арыш икмәгенә зар калган күп егетләрнең беремен. Биш-ун тәңкә кесәдә калса, минем дә эчне тишмәячәк.

— Ярый,— дим,— алмасак алмыйк!

Поезд кузгалды...

— Ваши билеты?..— дип кычкырды берәү.

Кинәт әйләнсәм, ни күрим: ике кондуктор, бер күз карашы белән ашарга торгандай ачулы йөзле контроль безне ике яктан кысып алганнар. Иптәшем боларны күрүгә агарынды, теле бәйләнде; бер сүз дә дәшә алмый, ирексез артына таба чигенә бара, чигенә бара...

Контроль бик ачуланып безгә:

— Молчать!— дип кычкырды да... киләсе стансада штраф түләргә әмер бирде.

Без баскан җиребездә катып калдык.

— Менә мә!— дим,— түләп рәхәтләнеп барасы урында ике кабат тунадылар, өстәвенә яңадан билетлар да алдырдылар.

Биремнәр

1. Мисаллардагы әйтемнәрне табыгыз. Алар нәрсәгә бәя бирәләр һәм үзләреннән вакыйгага нәрсә өстиләр — шул хакта сөйләгез.

Мөстәкыйль эш язганда файдалану өчен әйтемнәр

Җиде төн уртасы. Күзгә төртсәң күренми. Кисеп әйтә. Кулдан килә. Таш яра. Ут борчасы. Борчак чәчә. Ачык авыз. Кот ботка җитте. Авыз иту. Йөрәк ярыла язды. Ике күзе дүрт булды. Күз өстендә каш кебек. Чүп өстенә чүмәлә. Агылый белән тагылый. Син күр дә мин күр. Күз ачып йомганчы.

2. Түбәндәге вакыйганы, әйтемнәр катнаштырып, кабат языгыз. Кем күпме әйтем файдалана ала? Әлбәттә, әйтемнәрне үзеннән дә өсти ала.

Урманда

Мин лагерьда Рөстәм белән дуслаштым. Безне дуслар дип йөртә башладылар. Рөстәм бер генә минут та тик тора алмый. Йә агачтан уенчыклар ясый, йә укый, йә урманга чыгып чаба. Ә ул эшли белә. Бүген дә менә иртәнге ашны аннан-моннан гына ашадык та урманга чыгып чаптык. Ул алдан бара, мин арттан. Урман аланында кеше күп. Ата-аналар балаларын күрергә килгәннәр. Без куе наратлыкка кереп киттек. Анда бик караңгы иде. Мин курка башладым. Ул да булмады, бер ят тавыш ишетелде. Ботак сынган якка борылып карадым. Агачлар арасыннан коточкыч куркыныч баш күренде. Рөстәм дә курыкты. Без бу урыннан шунда ук юк булдык. Кайткач, күргәннәрне вожатый апага сөйләдек. Пошы булгандыр ул, монда пошилар күп, диде апа.

МӘКАЛЬЛӘР

Мәкальләрне дә халык иҗат иткән. Мәкальләр дә кыскалар һәм хикмәтлеләр. **Мәкаль вакыйганың үзенә бәя бирә.** Нинди дә булса вакыйганың дөреслеген яки ялганлыгын, кеше гамәленең файдалы яки зыянлы булуын раслый. Күрәсез, мәкаль әйтемнән нык аерыла икән. Мәкальне сыйфатлар да, сыйфатның дәрәҗәләре дә бөтенләй кызыксындырмый икән. Мәкальләр хәтердә кешенең ни эшләгәнен чамалап торалар. Кеше ялгыш юлга тайпылдымы яки нәрсә эшләргә белми аптырап калдымы, бу вакыйга янына шунда ук мәкаль сикереп төшә: «Мин — зирәк бабаларыңның күп мәртәбәләр сыналган тормыш тәҗрибәсе. Мин шулар авызы белән сөйлим. Мине үзеңне аптыраткан вакыйгаң белән чагыштыр һәм шуннан соң дөрес нәтиҗәгә кил»,— ди. Кешеләр шулай итәләр дә. Шуңа күрә мәкаль күп белүчегә зирәк кеше, диләр.

«Ни чәчсәң, шуны урырсың» мәкалендә, үзегез күрәсез, бернинди яңалык юк. Арыш чәчсәң, арыш үсәчәген кем белми. Ләкин мәкальгә чагыштырып бәя бирү өчен менә шундый бәхәссез дөреслек кирәк тә инде. Мәкаль үзендәге бәхәссез дөреслек белән тормыш вакыйгасындагы дөреслекне чагыштыра. Һәр мәкаль бихисап күп вакыйгаларга чагыштыру булып килә һәм шул вакыйганың эчтәлеге белән баеый. Ләкин өзлексез бернәрсәне тукый: ни чәчсәң, шуны урырсың, ди. Башкаларны рәнҗетсәң, шунда ук мәкаль сикереп төшә дә: шуны ук урырсың да, ди. Дәресеңне тыңлап утырмасаң, шуны ук урырсың, ди. Яшьтән кешене хөрмәт итәргә гадәтләнмәсәң, шуны ук урырсың, ди. Ничек шуннан соң уйга калмыйсың?

Мәхмүт Галәү

Болганчык еллар

(*Өзек*)

Иләк тә минеке,
чиләк тә минеке.

Аңлашылсын өчен өзекнең алдагы өлеше белән танышыйк. Ике туган — Вафа белән Сафа арасында ызгыш чыга. Вафа энесе Сафаның ярлы кызына өйләнүенә риза түгел. Ызгышның бер сәбәбе шул. Сабан туена бүләккә дип Сафа бүләк җыючыларга кыйм-

мәтле чапан биреп җибәрә. Абыйсының моңа да ачуы чыга. Бүләк җыючы чапанның искерәк икәнлеген күрә. «Ярый, бушлай биргән атның тешен карап тормыйлар!»— дип сөйләнә-сөйләнә, чапанны алып иптәшенә бирде, дип яза автор.

Вафа Сабан туенда үзенең җиңелеп калуын һаман оныта алмый әле. Шуңа күрә ул дәшми-тынмый гына чәй эчеп утырды. Патый исә авыз эченнән генә мыгырданып сөйләнүен белде.

— Әни, абый, тыңлагыз әле, сөйләшәсе сүз бар,— диде кинәт Сафа. — Ике сарык башы бер казанга сыймый, диләр. Без сарык булмасак та, бер йортта сыеша алмый башладык. Эт белән мәче шикелле яшибез. Бүленешәсе иде.

Патый эшләр болайга китәр дип көтмәгән иде, күрәсең.

— Тавык керсә, чүп чыгар, килен керсә, сүз чыгар, дип белми әйтмәгәннәрдер шул,— дип куйды.

— Килен гаепле түгел, әни, үзеңнең озын телең гаепле,— диде Сафа.

Сораулар һәм биремнәр

1. Мисалдагы әйтемнәрне һәм мәкальләрне табыгыз. Аларның кайсы әйтем, кайсы мәкаль — аерыгыз.
2. Мәкаль ярдәмендә бирелгән бәяләрне аңлатыгыз.
3. «Тавык керсә, чүп чыгар, килен керсә, сүз чыгар» мәкалендә ничә чагыштыру бар? Бу мәкальне әйтүче Патый — телчән, юньсез карчык. Мәкальдән файдаланып әйтегез, ул биргән бәядә дөреслек бармы?

Мөстәкыйль эш өчен мисал

Мәкаль һәм әйтемнәрне баганалап аерып языгыз.

Инә белән кое казый. Эт чаба дип, бет чаба. Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый. Уч төбендә генә йөртә. Ашыккан — ашка пешкән. Койрыгы пешкән мәчедәй йөри. Әкрен барган тиз җитә. Сай йөзә. Усаллык җиңмәс, тугрылык җиңәр. Бер кашык су белән йотарлык. Ерак куйсаң, якыннан алырсың, якын куйсаң, ерактан алырсың. Йомырка тавыкны өйрәтми. Җиде төн уртасы. Кечкенә булса да төш кенә. Җаны теләгән — елан ите ашаган. Йөрәк ярылу. Атын урлаткач, абзарын бикләткән. Ат яхшысы тездән билгеле, егет яхшысы сүздән билгеле. Егет җилле, җиләне кыскарак.

Сорауларга җавап биргәннән соң, мондый **нәтиҗәләргә** киләбез:

1. Мәкаль дә, әйтем кебек, тормыш вакыйгасын чагыштыру чарасы.

2. Мәкаль тормыштагы нинди дә булса мәсьәләне чишә. Ни эшләргә? Кем гаепле? Кайсы әйбәтрәк? кебек сорауларга җавап бирә.

Гомуми нәтиҗә. *Чагыштырып бәя бирү — сәнгатьчә фикер йөртүнең төп ысулы. Аның төрләре күп.*

КАТЛАУЛЫ КАРШЫЛЫК

Аю белән бабай

(*Халык әкияте*)

Борын заманда бер карт яшәгән, ди. Көннәрдән бер көнне, шалкан чәчеп торганда, карт янына Аю килеп чыга, ди.

— Нишлисең?— ди Аю.

— Шалкан чәчәм,— ди карт.

— Әйдә, уртакка чәчик,— ди Аю. Карт риза була.

Бергәләп шалкан чәчәргә тотыналар, ди, болар. Карт агач төбен казып тора. Аю каерып алып тора. Шулай итеп, тиз генә җирне әрчеп, шалканны чәчеп тә куялар, ди.

Шалкан җитешкәч, Аюга әйтә карт:

— Ничек бүләбез?Син төбен аласыңмы, сабагынмы?— ди.

— Мин сабагын алам,— ди Аю.

Ярар, Аюга шалканның яфракларын кисеп бирә дә, бу үзе, унбиш ат йөгенә төяп, шалканны алып кайтып китә.

Берзаманны, шалканны төяп базарга китеп барганда, Аю очрый моңа.

— Кая барасың?— ди Аю.

— Базарга шалкан сатарга барам,— ди дә Аюга ике шалкан ыргыта.

Аю шалканны ашап карагач әйтә:

— Ай-һай, бабай, мине алдагансың бит син, ди. Икенче уртакка әшли калсам, төбен алам инде,— ди.

Икенче ел килеп җитә. Карт кырга барган икән, әлеге Аю тагын моның янына килеп җитә.

— Бабай, нишлисең?— ди Аю.

— Бодай чәчәм,— ди карт.

— Әйдә, уртакка эшлик,— ди Аю. Карт бу юлы да риза була.

Шуннан тотыналар болар бодай чәчәргә. Карт чәчеп тора, Аю койрыгы белән себереп кенә тора.

Бодай өлгерә, урып алыр вакыт та килеп җитә. Аю җәй буена бодай кырын саклап яткан була. Карт бөтен гаиләсе белән урак урырга китә. Шулвакытны Аю да моның янына килә.

— Син нишлисең, Аю дус, астын аласыңмы, сабагынмы? — дип сорый карт.

— Мин быел астын алам инде,— ди Аю.

— Ярый,— ди карт,— син астын алсаң, мин сабагын алырмын,— ди.

Карт, бодайны урып, сугып, тегермәндә он ясап, күмәчен дә ашап карый.

Бервакытны, он төяп базарга барганда, Аю очрый моңа. Карт:

— Мә, сиңа бергә иккән игеннең күмәче,— дип, ярты күмәч тоттырып китә.

Күмәчне ашап карагач, Аюның тагын да ачуы килә.

— Киләсе елны кай ягын сайларга белермен,— ди Аю.

Биремнәр

1. Әсәрдән өч каршылык табыгыз.
2. Шулар арасыннан әсәрне икегә бүлүчесен табыгыз. Әсәрнең өлешләрен күрсәтегез.
3. Каршылыклы вакыйгалардан чыгып, Аюга һәм картка бәя бирегез.
4. Әкиятне Габдулла Тукайның «Күгәрчен» шигыре белән чагыштырыгыз. Ике әсәрдәге каршылыкларның уртак ягын табыгыз.

Әсәрдәге каршылыклар үзенчәлеген өйрәнгәч, түбәндәге **нәтиҗәләргә** киләбез:

1. Әкиятләрдә көчле җиңелә, көчсез һәрвакыт җиңә икән.
2. Әсәрләрдә каршылык бер үк эчтәлектәге ике өлешне бер-берсенә каршы куеп та ясала ала.

Төшеңне сөйлисеңме?

(*Әкият*)

Борын заманда бер ярлы гына карчык яшәгән. Моның бер малае була. Егет унбиш яшькә җиткәч, карчык малаен бер итекчегә өйрәтергә бирә. Элек бит сигез сәгать кенә эшләмәгәннәр, көннәр буе эшләгәннәр.

Шул вакытларда патша әйтә вәзиренә:

— Әйдә, ди, шәһәрне бер әйләнеп чыгыйк әле, нәрсә бар икән,— ди.

Йөри-йөри, болар кичкә калалар. Беркайда ут юк. Йөри торгач, бер өйдә ут күрәләр. Керәләр. Малай эшли-эшли йокыга киткән икән. Итекче аны уята.

— Их, тагын бераз гына йоклатмадың, шундый матур төш күрә идем, ахырына кадәр күреп бетермәдем,— ди.

— Сөйлә төшеңне,— ди итекче.

— Юк, сөйләргә ярамый,— ди егет. Патшаны да, вәзирне дә тыңламый, төшен сөйләми бу. Патша, өенә кайткач, сараена егетне чакырта. «Минем нәрсәгә кирәгем бар икән патшага?»— ди егет. Бара, керә патша йортына. Патша әйтә:

— Кичә күргән төшеңне сөйлә,— ди.

— Юк, сөйли торган төш түгел ул, мин аны беркемгә дә сөйләмим,— ди егет.

Патша төрлечә әйтеп карый: мал бирәм, йорт-җир бирәм, ди, астырам, кистерәм, үтерәм, ди. Ләкин егет һаман сүзендә тора: сөйләмим, ди.

— Ярар, алай булса, бирегез үзенә биш камчы, аннан соң чыгарып ябыгыз,— ди патша.

Егетне кыйнап чыгарып ябалар.

Иртәгесен тагын сорый патша. Тагын сөйләми. Биш камчы бирәләр дә тагын чыгарып ябалар. Икенче көнне, төшен сөйләмәгән өчен, егетне тагын кыйнап кертеп ябалар. Патша кызы шуны белә дә, марля, йод алып, егет янына кереп дәвалый. Тәмле әйберләр алып килә. Кыз һәр көнне егет янына кереп чыга. Ә патша һәр көнне егетне суктыра.

Көннәрнең берендә патшага икенче патшадан: «Кызыңны бир, кызыңны бирмәсәң, җибәргән табышмакларга җаваплар әйт яки сугыш ачам»,— дигән хәбәр килә.

Ул патшага өч алма җибәргән. Өчесе дә бертөсле. Шуларның кайсысы быелгы, кайсысы былтыргы, кайсысы өченче елгы икәнлеген белергә кирәк.

Бу патша вәзирен чакырта, бөтен карт-корыны чакырта. Барысыннан да сорый, һич белүче юк. Бу хәбәрне патшаның кызы ишетә дә егеткә килеп әйтә:

— Мин синең белүеңә ышанам, син болай гына әйтмә, кызыңны бирсәң әйтәм диген,— ди.

Ярар, белүче юк бит инде. Егетне чакыралар.

— Сөйлисеңме төшеңне? — дип сорый патша.

— Юк, сөйләмим,— ди егет.

— Ярар, сөйләмәсәң сөйләмә, алайса, менә шушы алмаларның кайсысы быелгы, кайсысы былтыргы, кайсысы өченче елгы икәнен аерып бир,— ди.

— Мин болай гына җавап бирмим, кызыңны миңа бирсәң әйтәм,— ди.

Патша көлеп җибәрә, ә вәзире:

— Син «риза» дип әйт, соңыннан күз күрер,— ди.

— Ярар, дөрес җавап бирсәң бирермен,— ди патша.

— Китерегез бер савыт су,— ди бу. Егет алмаларны суга сала. Алманың өчесе өч урында тора: берсе суның төбенә төшә, икенчесе — суның уртасында, өченчесе суның өстендә генә кала.

— Менә, ди, су төбенә төшкәне быелгы алма, ди, уртадагысы — былтыргысы, су өстендә торганы — өченче елгы алма, монысы кипкән инде,— ди.

Теге патшалыктан килгән кешедән: «Дөресме?» — дип сорыйлар. «Дөрес»,— ди. Шул гына кирәк бит инде. Патша егеттән тагын сорый: «Төшеңне сөйлисеңме?» — ди.

— Юк, сөйләмим,— ди егет.

Тагын камчы белән суктыралар да чыгарып ябалар моны.

Хәзер теге илче кеше патшага бер агач алып килә. Агачның ике башы да бертигез, бер юанлыкта. Шул агачның кайсы очы төп, кайсы очы баш икәнен белергә кирәк.

Тагын егетне чакыртып сорыйлар. Егет әйтә:

— Мин болай гына әйтмим, кызыңны бирсәң генә әйтәм,— ди.

Патша бу юлы да ризалашкан була.

— Китерегез бер савыт су,— ди бу.

Егет агачларны суга сала. Агачның бер башы су төбенә батып тора, икенче башы су өстенә калыккан.

— Менә бу башы — төп, бусы — баш,— ди.

— Дөрес,— ди килгән кеше.

Өченче тапкырында илче өч ат китерә. Өчесе дә бер буйда, бер төстә, бер зурлыкта. Шуларның кайсы карт, кайсы яшь икәнлеген белергә кирәк.

Патша әйтә:

— Китерегез әле теге егетне,— ди.

Китерәләр.

— Шушы атларның кайсысы карт, кайсысы яшь икәнлеген беләсеңме? — ди.

— Беләм. Кызың белән икебезгә никах укытсаң әйтәм,— ди.

Нишләсен патша?Риза була инде. Укыта никахны. Аннан соң егет әйтә:

— Китерегез бер савыт сөт, бер бәйләм печән, бер тубал солы,— ди.

Китерәләр сораган әйберләрне. Өчесен өч урынга куялар. Атларны җибәрәләр. Атларның берсе килә сөткә, икенчесе — печәнгә, өченчесе — солыга.

— Менә сөткә тыгылганы бер яшьлек, чөнки ул әле яшь, сөт тәмен генә белә, артык берни белми,— ди.

Атның икенчесе печәнгә тыгыла.

— Монысы инде сөт тәмен оныткан, печән тәмен генә белә, ди.— Ә солы ашарга тешләре үтми әле,— ди.

Өченче ат солыга тыгыла.

— Аның тешләре каткан, солыны да ашый ала, монысы иң карты,— ди.

Илчедән сорыйлар, дөресме, диләр. «Дөрес»,— ди илче.

Шул гына кирәк тә. Хәзер инде патша кызын бирсә дә бирә, бирмәсә дә бирә: бөтен сорауларга җавапны шул егет тапты бит.

Патша шулчакны егеттән сорый:

— Инде төшеңне сөйлисеңме?— ди.

— Хәзер сөйләсәм дә була,— ди егет.— Мин төшемдә синең кызыңа өйләнгәнемне күрдем, патша кияве булып туйга бардым, төшем рас килде менә, әйдә, туй итик,— ди.

Сорау һәм биремнәр

1. Әкиятне тәмамлагыз: туй вакыйгасы белән тәмамласагыз аңлатыгыз, ни өчен шулай уйлыйсыз?
2. Әкияттә бер-берсенә охшаган вакыйгалар күп. Охшаганнарын бергә җыегыз, бөтенесенә бер исем бирегез.
3. Әкиятне җыеп торучы каршылыкны табыгыз.

4. Әкият ничек мавыктыра? Сезне аеруча нәрсә кызыксындырды?
5. Патшага егет төшенең эчтәлеген белү бик әһәмиятлеме? Ни өчен ул шулкадәр тырыша-тырыша төш сөйләттермәкче була?
6. Ә егет төшен нигә сөйләми? Аңа сөйләмәү шулкадәр әһәмиятлеме?

Нәтиҗәләр:

1. Охшаш вакыйгаларны җыеп, бер өлешкә санау — анализ ясауның беренче адымы.
2. Каршылыкның бер төре — кешеләр арасындагы бәхәс, көрәш.
3. Укучыны мавыктыру өчен, автор билгесезлек уйлап таба.

КАРШЫЛЫКНЫҢ БАШКА ТӨРЕНӘ МИСАЛЛАР

Иген

(*Мәзәк*)

Ике карт сөйләшеп утыра.

— Хәзерге игеннең рәте юк. Без бала вакытта арыш вәт арыш иде, ичмасам,— ди берсе.

— Шулай шул, эченә керсәң, башың күренми торган иде. Хәзергесе билдән генә,— дип, аның сүзен хуплый икенчесе.

Сарык

(*Мәзәк*)

Ишегалдында ике әби зарланып утыралар.

— Хәзерге сарыклар да әллә нинди. Без яшь чакта көтүдән кычкырып кайта торганнар иде. Ә хәзерге сарыклар авызларын ачкан булалар — тавышлары чыкмый,— диләр икән.

Шәүкәт Галиев

Һәркем әйтә дөресен

Таң белән уяндылар,
Кармакларын салдылар,
Балыкка кузгалдылар.
— Кояш чыкты! — ди Хәлим.
— Чыгып килә,— ди Сәлим.
— Күренми...— ди Мөсәлим.
Һәркем әйтә дөресен,
Күрелгән кадәресен.

Тиздән берни күрмиләр,
Калкавычны күзлиләр,
Бата-калка калкавыч,
Калкавыч ул — алдавыч,
Ашауны оныттырды,
Вакытны оныттырды,
Һаман балык тоттырды...

Мәсәлим бер караса —
Кояш баеган ласа!
— Баеп бара,— ди Сәлим,
— Баемаган,— ди Хәлим.
Һәркем әйтә дөресен,
Күренгән кадәресен.

Ардылар да талдылар,
Кайттылар да аудылар.
— Берүземә,— ди мәче,—
Бар балыкны салдылар!
Һәркем әйтә дөресен,
Чын булган кадәресен.

Алдагы эшне җиңеләйтү өчен, «Иген» мәзәгенә анализ ясыйк. Мәзәкнең төзелеше бик гади. Анда берләштерерлек охшаш вакыйгалар юк. Турыдан-туры әсәрне өлешләргә бүлү эшенә керешәбез. Һәрвакыттагыча башта чагыштырулар эзлибез. Мәзәктә ике чагыштыру бар: 1. Арыш миннән биек. 2. Арыш миннән тәбәнәк. Ләкин анда шулай ук ике өлеш була алырлык каршылык та бар: хәзерге начар иген элеккеге яхшы игенгә каршы куела. Шулай булгач, мәзәкне каршылыкның ике ягы дип тә карый алабыз. Мондый очракта бүлүнең ике нигезе бар, диләр. Бүлүгә нигез итеп чагыштыруны алдым, бүлүгә нигез итеп каршылыкны алдым, диләр. Бу очракта безне нигезләрнең икесе дә канәгатьләндерә. Бер эш бетте. Хәзер икенчесенә керешәбез: өлешләр арасындагы бәйләнешне эзлибез. Әлегә бәйләнешләрнең өч төрен әйтеп торыйк: 1. Өлешләр бер-берсен баетып киләләр. 2. Өлешләр бер-берсенә каршылыкта торалар. 3. Өлешләрнең уртак яклары бар. Өчесен дә тикшереп карыйк. Бу мәзәктә өлешләр бер-берсен баетып килмиләр, киресенчә, бер-берсенә каршылыкта торалар. Өлешләрнең уртак якларын эзлисе калды. Бераз уйласак абайлыйбыз: бабайлар бер үк озынлыктагы арышны бер-берсенә каршы куялар. Алар шул ук озынлыкны үзләренең малай чактагы буйлары һәм олы кеше буе белән үлчиләр икән. Икенче төрле әйткәндә, өлешләрнең эчтәлекләре бер үк, картлар аларга төрле бәя генә бирәләр икән. Тагын да кыскарак итеп әйтергә өйрәник: бабайлар ике урындагы бер үк төрле эчтәлекне үзара каршылыкка китерәләр.

Шуның белән анализ ясауның бер өлеше бетте.

Өлешләр арасындагы бәйләнешне тапканнан соң, әсәрдәге вакыйгага үз карашыбызны булдыра алабыз. Анализның чираттагы алымы шуннан гыйбарәт. Вакыйга ясаучы бабайларга бәя бирик. Алар бит иске белән яңаны каршы куеп кына калмыйлар, яңаны сүгәләр дә. Дөресрәге, яңаны, бүгенге көнне сүгәр өчен, аны үткән заманга каршы куялар. Ләкин бер үк буйдагы арышка ике төрле бәя биреп ялгышалар. Бәя шундый: бабайлар ялгыша. Хәтерне эшкә җиксәк, бәяне киңәйтә дә алабыз. Ә бит андый кешеләрне күргәнебез бар, аларның сүзләрен ишеткәнебез бар.

Ике бабай сүзен кайбер кешеләр сүзе дип киңәйтеп, **гомумиләштерү** ясадык. Ягъни мәзәк авторының әйтәсе килгән сүзен белергә тырыштык.

Мәзәкне укыгач көлеп куйган идек. Бабайларның гапгади нәрсәдә дә ялгышып, фикерләрен җитди рәвештә исбат итүе кызык иде. Тыңлаучыны көлдерә алуы — мәзәкнең уңышлы булуы. Ә менә кешеләрнең берәр кимчелеге ачылса — мәзәк эчтәлегенең әһәмиятлелеге, дибез.

Без мәзәктәге картлардан усалланмыйча гына көлдек. Авторның хисе дә шундый дип фараз итә алабыз. Ул да безнең кебек яратып, бабайларны үз итеп көлә. Ә безне кисәтә: кешеләрнең ничек ялгышуын белеп торыгыз, кимчелекләрне гафу итә белегез, ди.

Биремнәр

1. Калган ике әсәргә анализны үзегез ясагыз.
2. Түбәндәге әсәрләргә дә анализ ясагыз. Алардагы каршылыкның ничек ясалышын (төрен) табыгыз.
3. Бу мәзәкне ике өлешкә бүлегез. Өлешләргә исем бирегез.

Бау

(Мәзәк)

Бер агай, биш ел утырып, төрмәдән өенә кайта икән. Юлда танышы очраган.

— Ни өчен утырттылар?— дип сораган танышы.

— Юк өчен. Биш ел элек юлда иске сүс бау тапкан идем. Бауны алып, өйгә кайттым. Шуның өчен төрмәгә яптылар,— дигән агай.

— Бер иске бау өчен төрмәгә япмыйлар инде, алдыйсың,— ди, агай сүзенә ышанмаган танышы.

— Анысы шулай, япмыйлар. Ләкин ул бауның икенче башына кәҗә бәйләнгән булган шул,— дип җавап биргән агай.

Борынга салкын тию сәбәпле

(Мәзәк)

Казый бер карактан:

— Моңа кадәр төрмәдә утырганың бар идеме? — дип сорый.

— Утырып чыктым,— ди карак.

— Ни өчен утырдың?

— Борынга салкын тигән өчен,— ди карак.

— Юкны сөйләмә, борынга салкын тигән өчен төрмәгә япмыйлар,— ди казый.

— Билләһи, алдамыйм,— дип ант итә карак.— Чынлап менә, борынга салкын тию аркасында утырдым. Эш болай булды. Бер өйгә ишеген ватып кердем. Сандык йозагын ватып казына гына башлаган идем — төчкереп җибәрдем. Тавышка хуҗалар уянды. Тоттылар. Аннан соң хөкем иттеләр.

Озын таяк

(Мәзәк)

Бер кеше үзенең матур гына таягын, озынрак дип, югары башыннан кисеп ташлый. Аны күреп торучы икенче берәү:

— Әй дус! Таягыңның иң матур бизәкле җирен кистең. Түбән башыннан кисәргә кирәк иде,— дигәч, таяк хуҗасы:

— Юк, таякның түбән башы түгел, югары башы озын иде,— дигән.

Сөйләгәннәрдән чыгып, түбәндәге **нәтиҗәләргә** киләбез:

1. Әдәби әсәргә анализ ясар өчен:

а) Аны мөмкин кадәр аз өлешләргә бүләргә кирәк. Бүләр алдыннан, охшаш вакыйгаларны бергә җыеп саныйбыз.

ә) Катнашучыларга карата үзебезнең карашны (бәяне) булдырабыз.

2. Каршылык әсәрне ике өлешкә бүлү өчен нигез була ала.
3. Каршылыклар күптөрле була, аны эзләгәндә буталып калмаска кирәк.

Бирем

Бу әсәргә анализны өйдә ясагыз.

Муса Җәлил

Су төбендә

«Улым инде су төбендә,
Хәбәрен алдым бүген.
Еламыйча нихәл итим,
Бигрәк үкенечле үлем!»

Хатны кысып күкрәгенә,
Үкси бичара ана.
Хатның горур юлларына
Кайнар яшьләре тама.

Хатны язган Балтиктагы
Бер авылдаш егете.
Озын түгел, кыска гына,—
Блокнотның бер бите.

Бәлки, походка киткәндә
Язгандыр ашыгып кына;
Миноносецның туплары
Янына басып кына.

Су төбендә булса да ул,
Җирдәгедән тере ул.
Туган суының хуҗасы,
Су төбе батыры ул!

Балтик хатларын таратып,
Самолет үтте бая.
Куй, елама, газиз ана,
Хатыңны укыйк, кая?

«Су төбендә...»
Тукта, тукта!..
Ник юкка борчыласың?
Елау түгел, шатланырга
Тиеш әле монда син!..

Улың синең су төбендә,
Су асты көймәсендә.
Дошманны якын китерми
Безнең чик тирәсенә.

Батырларның йөрәгендә
Урын бармы куркуга!..
Су төбендә үлем түгел,
Улың үлемне куа.

Безнең корал җир астында,
Җир өстендә, һавада,
Су астында, су өстендә,
Кая гына карама!.. —

Чик янына дошманнарның
Атлатмый аягын да;
Куй, елама, газиз ана;
Еларга кая монда?!

СЫЙФАТ ДӘРӘҖӘСЕ ТӨРЛӘРЕ

Иң элек эчтәлекләрендә хис дәрәҗәсе булган **халык җырлары** хакында сөйләшик.

Татарлар — моңлы халык. Татар элек-электән җыр ярат-кан. Шатлыктан да җырлаган, кайгыдан да җырлаган. Шат-лыгыннан җырласа, шатлыгы белән уртаклашкан, кайгыдан җырласа, кайгы-хәсрәтен үзе басмакчы булган. Кеше тормы-шында, кызганычка каршы, шатлыкка караганда хәсрәт күб-рәк була. Шатлык килә дә китә, тиз онытыла. Ә менә хәсрәт тиз генә онытылмый. Шуның өчен татар халык җырларын-да хәсрәт күп, сагыш күп. Габдулла Тукай халык җырлары турында бик матур сүзләр әйткән: «...халык җырлары — халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс, саф вә раушан көзгеседер»,— дигән. Җырларның эчтәлеге кеше күңелен чагылдыра, дигән, чөнки халык җырларының эчтә-леге кешенең хисләреннән гыйбарәт икәнлеген белгән. Күңел көзгесе «тутыкмас вә күгәрмәс» дигән, чөнки җырларга салынган хисне һәр җырчының үз хисе итеп кабул итүен, үз кайгысы, сагышы белән яңартуын белгән. «Саф һәм раушан» дигән, чөнки җырларның эчкерсез, ихлас хисен яраткан.

Җыр да кешеләргә әйтем, мәкаль кебек бәя бирә. Аерма шунда гына: җыр белән кешеләр үзләренә үзләре бәя бирә-ләр.

Кара болыт киләдер,
Янгыр микән, кар микән?
Минем кебек хәсрәт күргән
Бу дөньяда бар микән?

Дүрт юл белән чикләнгән халык җырларына **дүртьюллык** диләр. Мисалдагы дүртьюллыкка анализ ясыйк.

Аны өлешләргә таркату өчен гадәттәгечә нигез эзлик. Кабат укып чыккач күреп алабыз: баштагы болыт килү ту-рындагы вакыйга соңгы ике юлдагы хәсрәт вакыйгасына чагыштыру булып килә. Шуның өчен чагыштыруның ике ягын дүртьюллыкның ике өлеше итеп алабыз. Төп өлештә җырчы үзенең хәсрәтен башка кешеләр хәсрәте белән ча-гыштыра. Үзен дөньядагы иң хәсрәтле кеше, ди. Хәсрәт-нең, шатлыкның зурлыгын, азлыгын **дәрәҗә** дип әйтергә сүз куешкан идек. Шуңа күрә җырчы үз хәсрәтенә бәя бирә, аның дәрәҗәсен күрсәтә, дия алабыз.

Хәсрәт болыт белән чагыштырыла. Ә болытның өч сыйфаты бар. Ул кара. Ә нәтиҗәсе икәү булырга мөмкин. Яңгыр булып чылатып китүе, кар булып туңдыруы мөмкин. Бу сыйфатларның барын да кешенең хәсрәтенә кушабыз. Шулай итеп, җырчының киләчәге өчен ничек шомлануын, борчылуын беләбез.

Түбәндәге дүртьюллыкларга анализны үзегез ясагыз.

Тәрәзә төбем гөл генә,
Исемлесе бер генә;
Сагынам сине, сагынам,
Исләремдә син генә.

Шыбрай гына шыбрай яңгыр ява,
Үлән яфраклары ярпая[1];
Бу ла дөньялар хәсрәтендин
Карчыгадай башым картая.

Безнең урам уртасында
Түгәрәк кенә күлләр бар;
Сезгә генә мәгълүм түгел,
Бик сагынган көннәр бар.

Бу елда да бодай бигрәк уңган,—
Кыйблаларга таба егылган;
Бу хәсрәттән түккән күз яшьләрем
Күләгәле җирдә күл булган.

Биремнәр һәм сорау

1. Өлешләрнең аеруча әһәмиятлесен табыгыз.
2. Дүртьюллыклардагы төп өлешләрнең аермасын табыгыз.
3. Чагыштыручы юллар төп өлешләргә ни өстиләр?

Җырлар, кеше хисенә бәя биргәндә, бу хиснең дәрәҗәсен тасвирлый, дидек. Алдагы мисаллардан күренгәнчә, дәрәҗә ягыннан караганда хис зур да, кечкенә дә, вакытлыча да, даими дә; хиснең башы да, ахыры да була. Ләкин хиснең эчтәлеге турында сөйләмәдек. Безнең мисаллардагы җырлар хәсрәт турында иде. Ә бит хәсрәт, сагыш сәбәпсез булмый. Татар халкы сәбәп җырларын да иҗат иткән. Җырларда

[1] *Ярпая* (диал.) — шапырыну, мактану.

сагышның төп сәбәбе аерылу икәнлеге күренә. Ата-ана балаларыннан аерыла, туган туганнан, егетләр яраткан кызларыннан, ирләр хатыннарыннан, хатыннар ирләреннән аерылалар. Кеше, чит илләргә китсә, туган-үскән якларыннан, дусларыннан аерыла. Картайса — яшьлегеннән аерыла. Кешеләр элекке заманда да аерылышканнар, хәзер дә төрле сәбәпләр белән аерылырга мәҗбүр булалар. Шул сәбәпле элеккеге җырларны без хәзер дә үз җырларыбыз итеп җырлыйбыз. Кеше хәсрәте һәм шатлыгы һәрвакыт бертөрле була.

Аерылу турындагы дүртьюллыклар

Алма бакча, челтәр капка...
Ачыла ике якка;
Аккош балалары кебек,
Икебез ике якта.

Ишегалдым яшел чирәм,
Былбыл баласы кача;
Бик сагынсам, айга карыйм,
Айны да болыт баса.

Ай янында якты йолдыз,
Минем йолдызым гына;
Таң алдыннан ул да сүнә,
Калам ялгызым гына.

Алмалар өзәсезме,
Җепләргә тезәсезме;
Өзелгән алмалар кебек
Аерылдык, сизәсезме?

Сандугачлар, басып сайрап,
Сындырган гөлләремне;
Сынган гөлләргә охшатам
Аерылган көннәремне.

Ике аккош очып килә,
Берсе төште суларга;
Берсе төште дә югалды,
Без охшадык шуларга.

Биремнәр һәм сорау

1. Анализ ясагыз. Дүртьюллыкларны икешәр өлешкә бүлегез. Өлешләр арасындагы бәйләнешне табыгыз.
2. Беренче өлештән икенчесенә нинди эчтәлек өстәлә?
3. Аерылу төрләрен әйтегез.

Кешеләр җырны хәсрәтен җиңеләйтү өчен җырлый, дидек. Хиснең дәрәҗәсен, эчтәлеген (сәбәбен) әйткәннән соң, җырчы **юану** дүртьюллыкларына күчә.

Юану турындагы җырлар

Биек таудан чәчәк җыйдым,
Җыймадым сарыларын;
Үзең тапсаң, миңа да бир
Сабырлык даруларын.

Бәгырькәем, айга кара,
Мин дә айга карармын;
Күз нурларың айга төшсә,
Шуннан эзләп табармын.

Тау буенда, тау астында
Салкын чишмә түгәрәк;
Очып барып кайтыр идем,
Әгәр булсам күбәләк.

Кайсы кибеттән алсаң да,
Кулъяулыгы ал була;
Сезнең яктан искән җилләр
Йөрәгемә ял була.

Бирем

Дүртьюллыкларга анализ ясагыз.

Нәтиҗәләр:

1. Татар халык җырлары бер-берсенә эчтәлекләре белән тыгыз бәйләнгән өч төрле дүртьюллыктан (хис дәрәҗәсе, хис эчтәлеге (сәбәбе), юану) төзелә.
2. Хиснең өч сыйфаты бар: дәрәҗәсе, эчтәлеге, юану.

Мөстәкыйль эш

1. Дүртәр юлдан торган бу җырларның кайсы хис дәрәҗәсе, кайсы сәбәбе, кайсы юану турында булуын табарга.
2. Шуларның һәрберсеннән берәр дүртьюллык алып, тулы бер җыр төзергә.

Ак ука белән кара ука
Күгәрченгә тозакка;
Башларым китте еракка,
Китмәсә иде озакка.

Сандугачлар саф җирдә,
Аккош йөзә пакь җирдә;
Сөйләр сердәшең булмагач,
Бик ямансу ят җирдә.

Сандугачның, мескенкәйнең,
Канаты каерылган;
Бер без генә түгел инде
Иленнән аерылган.

Атка атлансаң, сикереп атлан,
Бөдрә чәчең селкенсен;
Кайгырма баш, түгелмә яшь,
Без күрәсен кем күрсен?

Иртә торсам исем китә,
Су өсте җем-җем итә;
Туган-үскән илне ташлап,
Бәхетсез егет китә.

Биек тауның башларында
Йөри арыслан киек;
Су сипмәгән гөлләр кебек
Йөрибез янып-көеп.

Безнең авыл — зур авыл,
Урамнары тар авыл;
Бәлки, рәхәт көннәр булыр,
Хәзергесе бик авыр.

МӘЗӘКЧӘЛӘР

Алмагач төбендә ике дус ята икән.

— Алма пеш, авызыма төш,— дигән дусларның берсе.

— Ничек иренмичә әйтәсең аны,— дигән икенчесе.

***

Авыру бабалары мич башыннан олы оныгына дәшә:

— Улым, су гына алып килеп бир әле,— ди.

— Тик ятасың бит, үзең эч,— ди олы оныгы.

— Шул ялкаудан су сорап торасың. Үзең тор да эч, бабай, бер уңайдан миңа да бирерсең,— дигән кече оныгы.

Ике ялганчы

Бер авылда ике ялганчы — тегүче белән итекче яшәгән. Көннәрнең берендә яшьләр тегүче янына кергәннәр дә, кайсы сәкегә, кайберләре идәнгә утырып: «Әкият сөйлә әле, әкият сөйлә»,— дип ялына башлаганнар.

— Мин әкият сөйли белмим. Бик ялынгач, үзем күргән-белгәнне сөйләрмен,— ди икән тегүче һәм күргән-белгәнен сөйләп киткән.— Мин бу тирә кешесе түгел, ерактан килгән кеше. Безнең якларда таулар күп. Алар башка як таулары тикле генә түгел, алар бик биек булалар. Менә безнең авыл тавыклары, шул тау башына менеп, күктән йолдызлар чүпләп, шул йолдызлар белән туенып торалар иде,— дип тәмамлаган сүзен тегүче.

Яшьләр моның сөйләгәнен тыңлап-тыңлап торалар да шиккә төшәләр. Ялганламый микән бу тегүче, диләр. Итекчедән сорамакчы булалар. «Ул да дөньяны күп күргән кеше, дөресен әйтер»,— дип киңәшәләр. Итекчегә баралар.

— Тегүче карт шулай-шулай дип сөйләде, дөрес микән бу эш? — дип сорыйлар.

— Әйе, булса булгандыр. Мин анысын белмим,— дип башлаган сүзен итекче.— Мин күп йөрдем, күп күрдем. Анысы дөрес. Тавыкларның күктән йолдыз чүпләгәннәрен күргәнем юк-югын. Тик менә безнең авылның әтәчләре айны, тартып төшереп, урам буенча өстерәп йөртә торганнар иде. Менә минем шуны күргәнем бар.

Бирем

Мәзәкчәләрнең уртак ягын табыгыз. Нинди сыйфат дәрәҗәсе ничек бәяләнә? Шул хакта сөйләгез.

Бари Рәхмәт

Алтын безнең җир

Бакча безнең ил,
Алтын безнең җир,
Җиргә тезләнеп,
Чәчәк өздем мин.

Менә шул чакта
Җирне кочаклап
Үбәсем килде, —
Сыймый кочакка.

Йөрәккә сыйды,
Туйганчы сөйдем:
«Йөрәгемдә кал
Мәңгегә!»— дидем.

Сорау

Нинди хиснең дәрәҗәсе ничек сурәтләнә?

Нәҗип Думави

Бака илә Үгез

Бик калын муенлы зур Үгезне
Күрде дә күлдәге бер Бака
Шаккатып аңарга салды күзен,
Кычкырды: ба-ка-ка, ба-ка-ка.

Шулвакыт иптәше килеп җитеп:
«Ни булды, дускаем, ни бар?»— дип,
Аның да Үгезгә исе китеп
Тайчанды, йә басып сытар дип.

Баягы Бакамы? Мин сиңа әйтим,
Куркынып тайчану кайда ул!
Бакырдап кабарды, күтәрелде,
Белмимен, ниндәен уйда ул?

Кабарып беткәчтен иптәшенә:
«Күрәмсең син мине, туган? — ди. —
Мин хәзер Үгездән ким түгел бит!
Яхшылап карале, туган», — ди.

Ба-как-как диеп тә иптәше дә
Елмайды, сөйләмә юкны дип.
Әле син Үгезнең колагыдай
Булырга сора, дуст, күпме дип.

Тагын да башлады кабарырга
Көчләнеп-көчләнеп ул кәнче,
Кабарды, кабарды, тәмам илә
Куәте, сулышы беткәнче.

— Йә инде, әйт хәзер, әллә узып
Киттемме азрак Үгездән?
Дөрестен сөйлә син, туган, үзең,
Калышмыйм түгелме Үгездән?

— Маташма, туганым, бер дә юкка,
Үгездә тояк та синнән зур.
Охшыйсың син үзең хәзер тупка,
Сукмасын балалар, булма хур.

Ишеткәч бу сүзне, тагын кәнче
Көчләнеп кабара башлады;
Вәләкин күз ачып күз йомганчы
Бу юлы Бакамыз шартлады.

Бирем

Кәнчелек сыйфатына бәя бирегез: а) кәнчелек көнләшүченең үзенә генә зыян китерәме? ә) кәнчелек һәрвакыт зыянлымы?

Мисалга китерелгән әсәрләрне өйрәнгәннән соң, түбәндәге **нәтиҗәләргә** киләбез:
1. Әдәби әсәр теләсә нинди сыйфатны (хисне, гадәтне, матурлыкны, караңгылыкны, көчне...) теләсә нинди дәрәҗәгә менгерә һәм төшерә.

2. Дәрәҗәгә төшерү яки менгерү — һәрвакыт чагыштыру нәтиҗәсе. Бәя.
3. Хиснең дәрәҗәсе, әсәрне өлешләргә бүлгәндә, өлешләрнең берсе була ала. Калган ике өлеше хиснең сәбәбе һәм юану була.

КАБАТЛАУ АЛЫМЫН ӨЙРӘНҮ

Габдулла Тукай

Бәйрәм бүген

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу?— Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен, бәйрәм бүген!

Арттыра, күрдем, кояш гадәттәгедән балкуын;
Ул киенгәндер, дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Хис итеп һәр җирдә дә бертөрле хуш ис аңкуын:
Ислемай сөрткән икән дөнья! — Дидем: бәйрәм бүген!

Бер теләнчене кочаклашкан күреп бер бай белән:
Күңле нечкәргән! — Дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын;
Сөйләшәләр үзара: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен;
Ансы да сөйли тагын: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Сораулар һәм биремнәр

1. Габдулла Тукай «Бәйрәм бүген» сүзләрен юл саен диярлек яза. Нигә шулай итә?
2. Шигырьне икегә бүлегез. Бер өлеш дип кабатлауны исәпләсәк, икенче өлешне ничек җыябыз? Төрле вакыйгалардан җыелган бу өлешкә нинди исем биреп була?
3. Кабатлау — хис тудыручы чара. «Бәйрәм бүген» сүзләрен кабатлау хис уятамы? Автор хисе турында нәрсә әйтә аласыз?

Гадел Кутуй

Сагыну

(*Нәсер*)

Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим,— барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнең энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин Карпат тауларына мендем, Финляндия күлләре янында ял иттем. Ләкин Эльбрус шикелле мәһабәт, Казбек шикелле гүзәл тауларны, үз илемдәге Аккош күледәй сихри күлләрне очратмадым.

Синдәгедәй илаһи матурлык, синдәгедәй шагыйранә мәһабәтлек бер җирдә дә юк, туган ил!

Мин чит авыллар һәм чит шәһәрләр аша узам. Җиңү мине Берлинга алып бара. Чит ил балалары миңа бәйләм-бәйләм чәчәкләр сузалар, чит ил картлары миңа хәмер тәкъдим итәләр, чит ил кызлары миңа җимешләр сузып елмаялар һәм ялваралар:

— Син безне үлемнән коткардың, инде кил, чибәр егет, кунак бул, бездә кал!— диләр.

Әмма мин елмая алмыйм, чөнки хәмерләре исертми, елмаюлары җылытмый. Мин юлымны дәвам итәм. Мин газиз илемне, аның ямьле бәйрәмнәрен, аның талган аякларны да биетә торган хәмерләрен, йөрәккә җылы өргән нечкә билләрен сагынам, гөнаһсыз балаларын күргәндәй булам.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!..

Сине сагынган саен, миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп, мин ачык аңладым: совет кешесе өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.

Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине, изге туган ил!

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәрдән ике төрле кабатлау табыгыз.
2. Бер үк сүзләрне кабатлауның нигә кирәге бар?
3. Нәсердә кабатлаудан тыш тагын нинди бәя бирү чаралары бар?
4. «Бәйрәм бүген» шигырен бүлгән кебек, әсәрне икегә бүлегез. Өлешләрнең икесенә дә исем бирегез.
5. Сагыну хисе бар икән, димәк, бу хиснең сәбәбе дә, юану да булырга тиеш. Шул өлешләрен табыгыз.

Ике әсәрне өйрәнгәннән соң, түбәндәге **нәтиҗәләргә** киләбез:

1. Автор әсәрендәге иң мөһим өлешен кабатлый икән.
2. Кабатлау әсәрнең иң мөһим өлеше булганга, башка вакыйгалар кабатлауның мәгънәсен, эчтәлеген ачып, аңа буйсынып килергә тиеш булалар.

ТАБЫШМАКЛАР

Табышмак — халык авыз иҗаты әсәре. Борынгы кешеләр аны кеше зиһененең дәрәҗәсенә бәя бирү өчен уйлап чыгарганнар. Табышмакның җавабын табу — ул билгесез күренешнең безгә кирәк ягын, ягъни мәгънәсен табу дигән сүз. Җавап, шулай итеп, табышмакның мәгънәсе була.

1. Килеп керде бер кеше, маңгаенда бер күзе. (*Энә.*)

Сораулар һәм биремнәр

1. Һәр табышмакта ике төрле кызыксыну бар. Беренчесе — табышмак табучының кызыксынуы. Аның җавап табасы һәм үзен зирәк итәсе килә. Икенче кызыксыну кемдә? Ул ни өчен кызыксына?
2. Табышмакта катнашучылар санын әйтегез.

3. Ни өчен энә кеше дип аталган?
4. «Күз» сүзе ни өчен табышмакта үзәк урынны алып тора?
5. Табышмакны икегә бүлегез.

2. Үзе һәр өйдә бар, үзе бер генә. (*Казан.*)

Биремнәр

1. Каршылык тудыручы сүзне табыгыз. Ни өчен аның каршылык тудыра алуын әйтегез.
2. Әсәрне икегә бүлегез. Ике өлеш арасындагы бәйләнешне табыгыз.

3. Ул минем әтиемнең улы, үзе миңа туган түгел. (*Үзе.*)

Биремнәр

1. Җавап ни өчен шундый, аңлатыгыз.
2. Әсәрне икегә бүлегез һәм араларын бәйләп торучы мөнәсәбәтне табыгыз.

4. Асты тишек, өсте тишек, уртасында ут та су. (*Самавыр.*)

Бирем

Табышмакка үзегез анализ ясагыз. Мәгънә ничек яшерелгән, аңлатыгыз.

ТАБЫШМАКНЫҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

Табышмак ничек ясала? Икенче төрле итеп сорау бирсәк: нинди өлешләрдән тора?

Беренче мисалга әйләнеп кайтыйк. Аның нигезендә каршылык ята: табышмакта бер күзле кеше килеп керде, диелә. Ә бит бер күзле кеше булмый.

Без бу табышмакның җавабын беләбез. Сүз кеше турында түгел, энә турында бара икән. Ә нигә табышмак энәне кешегә алмаштырды?

Кешенең дә, энәнең дә күзләре, икенче төрле әйткәндә, уртак яклары бар икән. Менә шушы уртак яклары бер-берсенә башка яклары белән бөтенләй охшамаган кеше белән энәне кушарга сәбәп булган. Димәк, безнең табышмакта кеше сыйфатлары белән энә сыйфатлары кушылган.

Биремнәр

Кеше белән энәнең күзе барлыгын белдек. Тагын нәрсәнең күзе бар? Шуны табыгыз һәм табышмакны үзегез төзегез. Онытмагыз: табышмакта каршылык, ягъни мәгънәсезлек булырга тиеш.

Дүртенче мисалдагы табышмакта ике әйбер кушылмаган. Анда самавырның бер-берсенә каршы килгән яклары гына аерылып алынган. Су белән ут каршылыкта тора, табышмак аларны аерып ала, су белән тишек каршылыкта тора, табышмак бу сыйфатларны да аерып ала.

Ләкин самавырны кеше сыйфатлары белән дә кушып була. Мәсәлән, *Бохарадан килгән кунак ут ашый да су эчә,* дисәк, кешедә булмаган сыйфатларны да әйттек, ут салуны *ашый* дидек, чөнки самавырның да авызы һәм борыны бар.

Нәтиҗә:

Табышмак йә ике бер-берсенә бер генә ягы белән охшаган нәрсәне кушып ясала, йә бер нәрсәне каршы якларга бүлеп ясала. Кыскартып әйтик: йә куша, йә бүлә.

Бирем

Түбәндәге табышмакларның ничек ясалуын сөйләгез.

1. Муены бар — башы юк,
   Колагы бар — кашы юк;
   Борыны бар — авызы юк,
   Аягы бар — кулы юк. (*Самавыр.*)
2. Акчасыз керәсең, хәзинә алып чыгасың. (*Мәктәп.*)
3. Ач булса — ята, тук булса — торып утыра. (*Капчык.*)
4. Ак кием кигән, башы түшәмгә тигән. (*Мич.*)
5. Кышын җылы, җәен салкын. (*Баз.*)
6. Җаны да юк, тыны да юк, үзе күлмәк кия. (*Мендәр.*)
7. Ишектән керер, түргә менеп утырыр. (*Җил.*)
8. Суга керсә — мең, судан чыкса — бер. (*Ат койрыгы.*)
9. Имәннән озын, үләннән кыска. (*Юл.*)
10. Бер чокырда мең чокыр. (*Уймак.*)
11. Кәҗә судан ничек чыга? (*Юешләнеп.*)
12. Нәрсә өстән аска таба үсә? (*Сакал.*)

МЕТАФОРА

Метафораны аңлау өчен, мисалга мөрәҗәгать итик.

Фәннур Сафин

Очты-китте яшелең

Җәй — яшел кош.

Әхсән Баянов

Бу дөньяда ни гаҗәп:
Җәйгә кердек җәяүләп!
Дуслар бергә җыелдык,
Елгада су коендык.

Күңелле соң,
 әй рәхәт
Җәй иленә
сәяхәт!

Яшел җәйдән тиз генә
Күзгә җиттек без менә.
— Яшел җәй, качтың кая?
Урманнарым саргая.

— Кояш тулы җәемне
Әйт, күз, кая яшердең?
— Сандугач канатында
Очты-китте яшелең!..

Шигырьне укый башлыйбыз: шунда ук сәер җөмләләргә тап булабыз. «Очты-китте яшелең», ди, әйтерсең лә яшел — кош ул. Яшел оча ала димени! Эпиграфында тагын: «Җәй — яшел кош»,— ди. Җәй — җәй, кош — кош инде ул. Алар бервакытта да бер-берсен алыштырып килә алмыйлар.

Алай да тагын бер кат укыйк әле.

Җәй белән яшел кош арасында сызык тора. Сызык — җөмләдә тигезлек билгесе ул. Шагыйрь җәйне кош белән тиңләштерә, чагыштыра. Икесе дә бер, ди. Әгәр кош белән җәй бер икән, димәк, кош сыйфатлары җәйгә күчә дигән сүз. Җәй дә кош кебек матур, ул да кош кебек бик тиз үтеп китә. Өстәвенә әле ул, әкияттәге кебек, яшел дә.

Шул рәвешчә, җәй эчтәлегенә яшел кош яңа эчтәлек өстәде. Үз сыйфатын кушып куйды.

Фәннур Сафин ике матурлыкның бергә кушылуын тагын да дәвам итә. Җәйнең яшелен сандугач канатында очыра. Кош сайравы белән җәйгә тагын бер матурлык өстәлде.

Шагыйрь аның белән генә дә канәгать булмый, ул ике әйберне янәшә куя да өстәмә эчтәлек тудыра. Җәйне тота да ил ди, ә ил булгач, аңа җәяүләп тә барып була. Ә нигә җәяүләп? «Җәяүләп» сүзе дә үз урынында утырмый түгелме соң? Җәй көне җәяүләп йөриләр, ә җәйгә җәяүләп барып булмый лабаса!

Тагын уйлап карыйк. Җәй үзе гүзәл бер ил икән, аның яшеллеген кошлар иңнәренә салып йөриләр икән, нигә шундый илгә җәяүләп барып булмасын! «Җәяүләп» дигән сүз хәтта җәяүләп булса да Җәй иленә барабыз, чөнки җәйне күтәп ала алмыйбыз, дип әйтеп салмасынмы. Уйлап карагач, билгеле. Бу сүз шулкадәр күп эчтәлеккә ничек ия булды? Бәйләнешкә кереп баеды. Ул җәй белән, ә җәй үзе яз, кыш белән, матурлык белән бәйләнешкә кергән. Җәй хәзер шуларның барысы өчен дә үзендә җаваплылык сизә, һәрберсенә үзенең сүзен әйтәсе килә.

Моңа кадәр без «ике әйбер янәшә килә, ике әйбер кушыла» дип әйтеп килдек. Әдәбият белемендә аларны — кушылып яңа мәгънә ясаучы әйберләрне, күренешләрне — **образлар** диләр.

Образлар янәшә килеп үзара бәйләнешкә керәләр дә өр-яңа эчтәлек тудыралар, ягъни бер-берсенең эчтәлеген баеталар икән. Менә шундый эчтәлекләр кушылуына **метафора** диләр.

Моңа кадәр без образларның бүленүен, ягъни үз-үзләренә яки башка образлар белән каршылыкка килүен әдәби алым дигән идек. Хәзер менә кушылып әдәби образ тудыра торган яңа алым барлыгын белдек.

Шигырь, хикәя, повесть, пьеса, хәтта романнар язганда да әдипләр шушы ике алымнан бик нык файдаланалар.

Фатих Әмирханның «Нәҗип» исемле хикәясе белән танышыйк һәм аңа анализны метафоралар ярдәмендә ясыйк. Без бит метафораның ике өлештән торуын беләбез. Димәк, хикәяне дә метафоралар һәм төп вакыйга дип ике өлешкә бүлә алабыз.

Бу хикәядә метафора үзе бербөтен вакыйга — уен вакыйгасы. Димәк, Нәҗипкә бәяне дә уен метафорасындагы сыйфатлардан чыгып бирәбез.

Фатих Әмирхан

Нәҗип

I

Минем абыемны бөтен күрше-тирә мактап сөйлидер иде:

— Булдыклы бала, матур бала, акыллы бала...— диләр иде. Башка кешеләрнең аны болай сөюләре, мактаулары мине бик көнләштермәсә дә, Мәрфуга апаның аны миннән артык сөюе мине борчый һәм кәефсезләндерә иде.

«Мәрфуга апа» дип, без үзебезнең күрше Габдерахман абзыйның олы кызын йөртә идек... инде җиткән кыз булса да, безнең 14—15 яшьлек апабыз янына сөйләшеп утырырга

гына түгел, курчак уйнашырга да кирә иде. Абый да, мин дә аны бик сөя идек.

Көннәрдән бер көнне без абый белән уйнарга тотынып, иске тарантасыбыз — пролетка урынына, аның югары күтәреп бәйләгән тәртәләре — ат урынына, абый бай урынына булды, мин кучер булдым. Абый: «Киттек!»— дип кычкыргач, мин, тарантасның кучер аягы басар өчен куелган җирләренә аягым белән тибеп, ат барган тавыш чыгарырга тотындым. Ат кузгалды, без киттек, имеш.

Берничә минутлар шулай итеп баргач, абый миңа:

— Атны чаптырарак төш!— диде. Мин дә аякларымны бөтен көчләре белән тыпырчындыра башладым. Очабыз гына, имеш.

Бу арада апа, тәрәзәне ачып:

— Гомәр, кер әле монда. Безгә курай уйнарсың!— дип кычкырды.

Мин абыйның җавап биргәнен көтмичә, аның өчен үзем җавап бирергә ашыктым:

— Уйныйбыз әле без. Курай, курай, имеш, тапканнар бер курай. Кермибез без, йөдәтмәгез безне! Шулай бит, абый? Анда кызлар арасында ир малайларга...

Апа янында бүген кызлар вә алар арасында Мәрфуга апа да барлыгын без белә идек. Минем абыйны чакырып та, үземне чакырмый калдыруларына ачуым килгән иде. Абыйны кертмәс өчен, мин, аякларымны тагын да ныграк тыпырчындырып, атның бик шәп һәм бик дәртле барганлыгын күрсәтергә тырыштым.

Абый апага: «Кермим»,— дип үзе җавап бирмәсә дә, минем җавабыма каршы килмәде. Әмма апа, минем ачуымны тагын да китерә төшәр өчен дигән шикелле итеп:

— Сине дәшмибез дә без, синең кирәгең юк. Гомәрне дәшәм бит мин. Гомәр, кер, акыллым!— дип кычкырды.

Ачуымнан минем бөтен кәефем бозылып өлгергән иде инде. Әле ярый абый, тарантастан төшеп, апалар янына кереп китмәде. Булмаса, Ходай белә, миңа еларга да чират җиткән булыр иде.

Апа тәрәзәдән китте. Мин дә бераз тынычландым, тәртәләргә чыбыркы белән бер-ике сыдырдым:

— На-а-а, ник ялкауландың, хайван! Шулай итеп, менә инде уеныбыз яңадан әүвәлге дәртле хәленә кайта дип торганда гына тәрәзәдән тагын:

— Гомәр!— дигән тавыш ишетелде. Бу юлы инде апа тавышы түгел, Мәрфуга апаның матур тавышы иде.

— Гомәр, кер әле, нәнәм, безгә курай уйна!

Мәрфуга апаның матур тавышы миңа бу юлы шундый ямьсез, шундый начар булып ишетелде ки, мин эчемнән генә аны да үчекләдем:

— Вә-вә-вә, Г-г-г-омәр, вә-вә-вә...

Минем атны бик чаптыруыма да карамыйча, абый тарантастан төшеп китте һәм минем: «Ат чабып барганда төшмиләр инде аны!»— дигән сүземә дә җавап бирмичә, өйгә кереп китте. Бу эшнең барысы мине шулкадәр хурландырды ки, минем күзләремә яшь тә килеп өлгерде.

«Кешене мыскыл итәләр, кешене җәберлиләр, аны дәшәләр, мине дәшмиләр дә. Мине һәр кеше җәберли генә... Менә барысы да Кыямәт көнендә җәһәннәм утында янарлар әле...»— ди-ди уйланып, мин шактый вакытлар кучер урынында утырып тордым; күз яшьләре инде акрын-акрын гына йөземне чылата башлады.

«Сабый баланы елаткан өчен җәһәннәм утында янарлар әле...»— дип тагын-тагын уйландым. Бу «үзләре» дә дигән кешеләрем кемнәр булгандыр — анысын Хода белә. Биш-ун минут шулай утырганнан соң, мин күз яшьләремне сөрттем дә ачу алу кайгысына төштем. Әмма кемнән ачу алырга?Ападанмы? Мәрфугаападанмы? Әллә барысыннан дамы?

«Җае ничек туры килсә, шулай эшләрмен!»— дип уйлап, кызлар җыелып утыра торган апа бүлмәсенә чаптым. Мин барып кергәндә, абый курай уйнап утыра; Мәрфуга апа да, теге кунак кызлар да бик ихлас белән тыңлап утыралар иде. Барып кергәч тә, мин ачы чырылдык тавыш белән абыйның курай уйнап утыруын үчекләргәябыштым. Берәр минутка бүлмәдәгеләр аптырашып калган шикелле булып тордылар да, аннан соң апа, минем авызны кулы белән каплап:

— Шаярма, тукта, булмаса, хәзер чыгып әнигә әйтәм! — дияргә тотынды.

Мәрфуга апа, зур күзләренә гаҗәпләнү кыяфәте чыгарып:

— Әбәү, нәнәм, бу ни эшең бу? Син бер дә болай түгел идең бит. Менә бу кунак кызлары үзеңне акылсыз малай икән бу дип китәрләр,— диде.

Мин Мәрфуга апаның бу сүзләреннән соң дәрәҗәдә кәефсезләндем; кунак кызларының үземә туп-туры карап торуларыннан хурландым да ачудан һаман әле уйнап утыра торган

абыйның авызыннан кураен тартып алдым. Бу эш, минем үземчә, бер батырлык, бер егетлек шикелле булып, кунак кызларының, хосусән Мәрфуга апаның исен китәрер һәм аларга мине бер батыр егет итеп күрсәтер шикелле тоела иде. Ләкин эшнең ахыры алай булып чыкмады — абый кураен минем кулдан тартып алды да үземне этеп җибәрде, Мәрфуга апа һәм кунак кызлары миңа:

— Әбәү, акылсыз! — диештеләр.

Апа, минем абый белән сугышырга торганымны күреп, ике кулымнан тотып, бүлмәсеннән чыгарып җибәрде дә ишеген бикләп алды. Мин, күзләремнән ага торган яшьләр белән тотлыга-тотлыга:

— Ачмасагыз, ишегегезне ватам!— ди-ди кычкырып бүлмә ишеген ватарга тотындым. Тавышка килгән әнине күргәч, мин инде елап ук җибәрдем.

II

Ул көн кич йокларга яткач, мин үземнең шул эшләрем хакында бик озак уйландым. Бер караганда, апалар, Мәрфуга апалар, әниләр, абыйлар, хәтта теге кунак кызлары да мине җәбер иткән кебек тоелалар; икенче караганда, мин үзем болай сугыша башлап, начар эшләгәнмен шикелле тоела иде. Бер уйлаганда, тегеләргә ачуым кабара иде; икенче төрле уйлаганда, алардан оялган сымак була идем. Башкалары тагын бер хәл иде, Мәрфуга апа алдында мин үземне оятлы итеп сизә идем.

Ул мине, акылсыз малай икән бу, дип уйлагандыр инде. Мәрфуга апа мине, кызлар хәтле дә куәте юк икән аның, дип уйлагандыр инде. Әнигә әйткәндә мин елап ук җибәрдем. Мәрфуга апа аны ишеткәндер дә, бигрәк елак малай икән бу, кыз балалар шикелле икән, дип уйлагандыр...

Икенче көн иртә белән минем башым үземне Мәрфуга апага ничек итеп батыр, һөнәрле, елак түгел итеп күрсәтүне уйлау белән мәшгуль булды. Уйлый-уйлый торгач, бер юл табылган шикелле булды. Мин Мәрфуга апаның һәр көнне безгә керә торган вакытын белә идем. Шул вакытны саклап торып, үзебезнең өй түбәсенә мендем дә, аның иң очланып килгән җиренә барып, кулларым белән морҗага ябышып, басып тора башладым. Менә бервакыт капкадан Мәрфуга апа күренде... Мәрфуга апа килә дә килә, мин аның үземне күрүен көтәм дә көтәм; әмма ул... үч иткән шикелле, күрми дә күрми. Ахыр, мин чыдамадым:

— Мәрфуга апа!— дип кычкырып җибәрдем.

Ул як-ягына каранды; мин яңадан кычкырдым. Шуннан соң ул мине күрде, ләкин:

— Исәнме, Нәҗип! — дигән сүздән башка бернәрсә дә әйтмәде. Минем шушындый биек һәм куркыныч җирдә басып торуыма бер дә исе китмәгән шикелле генә итеп йөри иде.

— Мәрфуга апа! Мин монда әллә кайчаннан, бик озактан бирле басып торам бит!— дип кычкырдым.

Ул тагын бер кат миңа күтәрелеп карады да:

— Аягың ычкынып, егылып китсәң булыр эш. Төш, нәнәм, аннан. Өй түбәсендә каргалар гына йөриләр. Зур егетләр анда менмиләр; әнә абыең, зур булгач, анда бер дә менми!— диде.

Бу сүз минем бөтен кәефемне бозды... Мәрфуга апа бу сүзне әйткәнче мине борып чеметеп алган булса, җиңелрәк булыр иде. Кәефсез генә, азапланып кына, йөземне чытып кына мин түбәдән төштем дә бакчага барып утырдым. Үз-үземне бик җәберләнгән кеше шикелле итеп тоя башладым. Мәрфуга апага һәм үзем билгеләп җиткерә алмый торган әллә кемнәргә ачуым килде. Ачуым килде, әмма...

Ничек тә булса, Мәрфуга апага үземнең батыр икәнемне, һөнәрле икәнемне күрсәтү уеннан мин кайта алмадым. Моның өчен мин аның өенә кайтырга чыкканын саклап тордым да, аның өй ишегеннән чыкканы күренгәч тә, җәһәт кенә, батыр гына койма өстенә менеп киттем; һәм аның өстенә куелган бер кул яссылыгы гына такта өстендә арлы-бирле йөрергә тотындым. Мин йөрим дә йөрим; әмма ул алдына караган да, мине күрмичә, әллә нәрсә уйланып килә. Инде ул коймага якыная дигәндә, мин тамак кырып бактым; файдасы булмады... пароход тавышы белән кычкыртып җибәрдем. Мәрфуга апа йөзен күтәреп миңа карады. Мин моны күргәч тә, бер аягымны коймадан күтәреп, бер генә аягым белән аның өстендә калдым: тар гына урында да мин бер аягым өстендә генә дә басып тора алам, имеш! Мәрфуга апаның минем бу һөнәремә дә бик исе киткәнлеге күренмәде. Бары ул:

— Нәҗип акыллым, төш аннан, төш! Шундый җирдән егылып, берәр җиреңне имгәтмәсәң ярар иде син. Зур егетләр койма өстенә менеп йөрмиләр инде. Койма өстендә мәчеләр генә йөриләр. Әнә абыең, акыллы булгач, бер дә андый җиргә менми! — диде.

Бу сүз мине тагын үтерде дә салды. «Мәрфуга апа минем үземне күрсәтергә йөргәнемне сизде. Мине бер дә батыр дип тә, егет дип тә уйламады. Бер аяк белән генә басып торганымны рәтләп күрмәсә дә, юри генә күрдем диган булды...» — дип уйланып-уйланып, минем Мәрфуга апага ачуым килде. Ләкин ачуым басыла төшкәч, болай дип уйлавымның дөрес түгел икәнен үзем дә яхшы аңладым.

Ләкин ачуым — ачу, бу соңгы уемны ничек булса да какшатып, Мәрфугаападан үч алмый калырга ярамый.

Ул көн көне буе гына түгел, хәтта кич буе да әле минем күңелемдә ачу сакланды; ләкин икенче көн инде ачу онытылган, бары җиңелчә бер үпкәләү генә калган иде.

Ул көн иртә җилле, давыллы булды... Күк йөзе зәңгәрсу, кара, куе вә калын болыт кисәкләре белән тулган; дөнья шул болытлардан аңкыган салкынчалык белән капланган иде. Менә бервакыт давыл бераз акрынлаган шикелле итте. Бераздан тагын куәтләнде, тагын бераз акрынлады, тагын куәтләнде дә тагын бераз тынды. Бу вакытта бер куе болыт нәкъ безнең өскә килеп җиткән иде. Дөнья җимерелгән шикелле итеп күк күкрәде, берәр мәртәбә яшен уты күренеп китте. Күк күкрәве тагын да куәтләнде дә, чалтыратып суккан яшен тавышы бөтен дөньяны яңгыратты. Тагын күк гөрелдәде, тагын яшен чалтырады да, чиләкләп койган шикелле итеп, яңгыр яварга тотынды... Эре тамчылар белән дөньяны дер селкетеп яуган бу яңгыр ярты сәгать эчендә безнең бөтен ишегалдын суга батырды. Ярты сәгатьтән соң яңгыр инде басыла башлады: тамчылар сирәгәйделәр, тигезләнеп исә башлаган җил болытны куды, аның астында капланып торган кояш, үзенең нурлы йөзен безгә таба юнәлдереп, юеш җирне җылыта, гөрләп ага торган яңгыр суын бриллиант тамчылары шикелле итеп ялтырата башлады. Дөнья яктылык һәм шатлыкка коенды.

Мин, балакларымны сызганып, суда, былчыракта йөрергә чыгып киттем... Шактый вакытлар бу кәефле эш белән маташканнан соң, мин кызыл балчыктан төрле нәрсәләр әвәләргә тотындым: күмәч булды, башлы шикәр булды, ат булды. Хәер, бу соңгы нәрсәмне ат диеп тә, мөгезле сыер дип тә, хәтта сарык дип тә уйларга мөмкин иде. Шуңа күрә, караган кешегә танырга уңай булсын дип, мин бу «хайван»ның аркасына шырпы белән «ат» дип язып куйдым. Бу нәрсәләрнең бик килешле чыгуы мине үсендереп җибәргәч: «Тукта, Мәрфуга апа сурәтен ясыйм. Үзенә күрсәтеп, исен китәрермен», — дип

уйлап, адәм гәүдәсе әвәләргә тотындым. Монысы булды. Гәүдәгә аяклар кирәк. Шактый азаплана торгач, алар да бертөрле ясалдылар. Дөрес, бу аяклар бик нәфис түгелләр; алар аяктан да бигрәк кәкре башлы бүкәннәргә охшыйрак төшәләр иде. Ләкин нишләмәк кирәк? Яхшырак, нәфисрәк итеп эшли башласаң, кызыл балчык чыдамый, әле бер җире кителеп төшә, әле икенче җире сынып китә. Кулларны ясау, аякларны ясауга караганда да, мәшәкатьлерәк булды. Шулай да, азаплана торгач, алар да ясалып тәмам булдылар. Дөрес, куллар бармаксыз һәм берсе-берсеннән озынрак булып чыктылар. Ләкин аннан гына әллә никадәр зарар килми бит. Болар тәмам булгач, шар кыяфәтле итеп баш ясадым да шырпы белән авыз сыздым. Бик азапланып, тукмакка охшашлы борын ясап куйдым, күзләр урынына... ике ялтыравыклы пыяла утыртып куйдым да алар өстеннән каш сыздым. Күз урынына утыртып куйган ялтыравыклы пыялаларымның түгәрәгрәк булып, зураеп, ялтырап торулары минем үземә бик килешле шикелле тоелды. Дөрес, бу ялтыравыклы пыялаларның берсе Мәрфуга апаның күзе шикелле зәңгәр булса да, икенчесе кып-кызыл булып, аның күзенә охшамый торган булып тора иде. Ләкин нишләмәк кирәк? Хәзинәмдә бары шулкадәр генә иде шул. Колакларны шырпы белән сызып, мунчаладан чәч тә куйгач, «Мәрфуга апа» ясалып тәмам да булды. Караган кеше танымый тормасын өчен, моның аркасына да «Мәрфуга апа» дип язып куйдым...

Менә бервакыт Мәрфуга апаның капкадан кергәне күренде...

— Мәрфуга апа, кил әле монда. Синең үзеңә генә бернәрсә күрсәтәм!— дидем. Ул минем яныма килгәч, киптерергә куйган «Мәрфуга апа»мны аның алдына китереп куйдым. Мәрфуга апа аңа күзен генә төшереп алды да:

— Ник, җаным, болай былчыранасың?— дип сорады.

— Бу син бит, Мәрфуга апа. Әнә аның күзе нинди зур, үзе зәңгәр. Мин аның икенче күзенә дә иртәгә зәңгәр пыяла табып куярмын...

Мәрфуга апа сурәткә якынрак килеп карады һәм көлеп җибәрде:

— Әбәү, җаным, бу бик ямьсез бит! Мин шулай ук ямьсезмени соң?— диде.

Мин уңайсызланып кына моның ямьсез түгел икәнлеген сөйләргә керештем.

— Менә аның чәче дә синеке шикелле сары; корсагы да синеке шикелле тигез!— дидем. Ул, минем исемне җибәреп:

— Мин бик үпкәлим инде, Нәҗип, сиңа, мине шундый ямьсез итеп ясагансың. Кирәкмәс, акыллым, андый нәрсәләр ясама, былчыранып йөрмә. Менә абыең, акыллы булгач, бер дә былчыранып йөрми...— диде дә үзе китеп тә барды.

Хурлануымнан, ачулануымнан елыйсыларым килде.

— Әйе, абый ясаган булса, барыгыз да матур дияр идегез әле.

Ишегалдына чыккач, сурәтне җиргә салып таптап изеп бетердем.

— Менә сиңа Мәрфуга апа, менә сиңа Мәрфуга апа...

Сурәтне таптагач, елыйсы килүем бөтенләй бетеп, ачуым бераз басылса да, бу вакыйгадан соң бик озак вакытлар мин Мәрфуга апаны дус күрә алмыйча йөрдем.

III

Бу елның кышында мин үзем укый торган хосусый мөгаллимнән рәсем төшерү дәресләре дә ала башладым. Мин, башка дәресләремне тырышып укыган шикелле, рәсем дәресләрен дә тырышып өйрәнә идем. Яз башында инде мин, шактый авыр ясала торган чәчәкләрне дә күчереп, яхшы ук матур итеп ясый ала торган булдым.

Язгы көннәрнең берсе иде. Мин, дәресләремне укып бетереп, уйнар өчен ишегалдына чыккан идем. Без абый белән кар суында көймә йөртергә тотындык. Ак карның саф суы уйнаклап ага, безнең көймә итеп йөртә торган, ике башын очландырып, уртасына кәгазь әләм әләр өчен чыра кадап ясалган тактабыз, бозларга бәрелә-бәрелә, су аккан уңайга бара иде. Бервакыт өй ишегеннән апа күренде. Ул:

— Нәҗип, монда кер әле, акыллым!— дип кычкырды.

— Тукта әле, мин уйныйм әле, апа!— дидем мин. Апа кереп китте. Бераздан соң аның урынына ишек төбенә Мәрфуга апа чыкты да:

— Нәҗип, бер генә минутка өйгә кереп чык әле, җаным!— диде.

Мин кергәндә, алар өйдә минем рәсемнәр төшерә торган альбомымны актарып утыралар иде. Мин аларның янына да барып җитмәдем, Мәрфуга апа:

— Нәҗип, менә шушы зур итеп төшергән чәчәгеңне син миңа кечерәйтеп төшереп бирмәссең микән? — дип, миңа альбомымдагы бер зур чәчәкне күрсәтте.

Мәрфуга апаның матур елмаеп әйткән сүзенә каршы «ярамый» дия алмадым, икенче бер кәгазьгә зур чәчәкне кечерәйтеп төшерә башладым. Мәрфуга апа минем төшергәнемне карап тора, кайсыбер сызыклар бигрәк матур чыгып куйса, ул зур күзләре белән миңа көлемсерәп иркәләгән шикелле итеп карап ала иде.

— Мәрфуга апа, бу чәчәк ни өчен кирәк булды сиңа?

— Калфак тирәгенә. Инде ясалып бетте бит ул. Бик рәхмәт сиңа!.. Кечкенә генә куллары белән нинди матур чәчәкләр төшерә белә бит,— диде ул.

Бу вакытта Мәрфуга апаның күзләре зур вә матур иделәр, тешләре ап-ак вә тигез иделәр, көлүе, елмаюы — һәммәсе дә бик килешле вә бик матур булып чыга иде.

— Мин сиңа, Мәрфуга апа, кирәк булса, моннан да матур чәчәкләр эзләп табып, кечерәйтеп төшереп куярмын!— дидем дә мин, кәефемнән бераз кызарынып, йөгереп, уйнарга чыгып киттем һәм: «Менә, Аллага шөкер, мин дә бөтенләй һөнәрсез малай түгел инде!»— дип уйладым.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хикәянең сюжетын кыскартып сөйләгез.

2. «Уен», «Үч алу» дип исемнәр бирә-бирә, хикәяне вакыйгаларга бүлеп чыгыгыз.

3. Охшаш вакыйгаларны берләштерегез. Мәсәлән, ике уенны «Уеннар» дип бер генә вакыйгага калдырыгыз.

4. Хикәядәге төп каршылыкны табыгыз.

5. Фатих Әмирхан үз хикәясендә көннең төрлегә үзгәрүен кабатлый. Ни өчен шулай итә?

6. Югарыдагы биш сорауга җавап табылгач, хикәянең эчтәлеген сөйләргә мөмкин. Бу хикәя нәрсә турында? Фатих Әмирхан үз әсәрендә нәрсә әйтергә теләгән?

Хикәягә анализ ясагач күренә: «Нәҗип» бик кызыклы, катлаулы һәм гыйбрәтле әсәр. Нәҗип мисалында укучылар үзләренең эшләгән эшләренә, хисләренә дөрес бәя бирергә, хаталарын күрергә һәм төзәтергә өйрәнәләр. Өстәвенә без шактый катлаулы әсәргә анализ ясарга өйрәндек.

Истә калдырыйк:

Әдәби әсәрдә авторның шулай булсын иде (яки булмасын иде) дип теләгән теләгенә әсәрнең **идеясе** диләр. **Идея** — автор теләге ул. Һәр әсәрнең идеясе бар. Аны әсәргә анализ ясап кына табып була.

Мөдәррис Әгъләмов

Тургай

Мөгаен, язгы басуның
Йөрәгедер тургай.
Башка берәр моң бар микән
Тургай моңнарыдай?

Туктап калган баш очында
Кечкенә бер уймак,
Шул уймакта күпме кодрәт,
Баксаң әгәр уйлап.

Язгы ләйсән урынына
Түгә моңны, түгә...
Офык иңләп
Сибелә моң
Туган җирләремә.

Ә соң, кеше, синең йөрәк
Кечкенәме, зурмы?
Сыйдырган бит бу дөньяның
Үзе кадәр моңын.

Уйлап баксаң уйландыра
Уймак кадәр тургай.
Башка берәр моң бар микән
Тургай моңнарыдай?

Биремнәр

1. Шигырьдә тургай белән кеше йөрәге турында сөйләнә. Шуңа күрә әсәрне «Тургай турында», «Кеше йөрәге турында» дип ике өлешкә бүләбез дә. Тургайның барлык сыйфатларын санап чыгыгыз.
2. Кеше йөрәгенең барлык сыйфатларын санап чыгыгыз.
3. Тургай кеше йөрәге белән чагыштырыла. Аларның уртак якларын һәм аермасын әйтегез.
4. Өченче биремгә җавапта кеше йөрәгенә бәя бар. Шуны таба аласызмы?
5. Дүртенче сорауга җавап таба алмасагыз, шигырьдәге каршылыкларны табыгыз. Йөрәккә бәяне каршылык аша да табарга мөмкин.
6. Ә хәзер барлык сорауларны кабат укып чыгыгыз. Сораулар әсәргә анализ тәртибен күрсәтәләр. Дәфтәрләрегезгә кыска итеп шул тәртипне язып куегыз.

Равил Фәйзуллин

Таң

Таң ата дип ишеткән бар
Әбидән дә, бабайдан да,
Ә үземнең таң атканны
Күргәнем юк беркайчан да.

Бүген менә шуңа күрә
Уяндым да караңгыдан:
— Таң ничек ата соң?— диеп,
Тәрәзәдән карап торам.

Башта үзем куркып куйдым —
Караңгыда күрә алмам.
Хәзер тышта якты инде,
Таң атканын күрми калмам.

Мөстәкыйль эш

Уйлап карагыз әле, бу шигырьнең мәгънәсе нәрсә булырга мөмкин? Шигырьнең эчтәлеген өлешләргә бүлеп кенә табып була. Өлешләргә бүлегез. Өлешнең берсе *таң*. Икенчесен табыгыз. Икенче өлеш беренчесенә каршылыкта торырга тиеш.

ХИС

(Әдәби әсәр эчтәлеге)

Хиская тагын «тойгы» яисә «кичереш» диләр. Бу сүзләрнең эчтәлекләре бер. Тормыштагы вакыйгаларны кеше иң башта күңеле белән кабул итә. Бакчасыннан көзен бәрәңге күп чыкса шатлана. Хезмәтем бушка булмаган, ди. Кышка бәрәңге үземә дә, малларга да җитә, ди. Муллыкны кеше шатлык хисе белән кабул итә. Баласы начар укыса, ана борчыла. Киләчәктә моңа ышаныч аз, ди. Үзе дә бәхетле булмас, ди. Хис — дөнья вакыйгаларына күңел белән бәя бирү ул.

Без җырларның эчтәлеге хис икәнлеген беләбез. Хисләрнең өч сыйфатын хәтергә төшерик. Әдәби әсәр кеше хисен һәрвакыт бераз арттырып күрсәтергә омтыла. Бу омтылышны без хиснең дәрәҗәсе дияргә килештек. Хис туу өчен сәбәп кирәк. Хис тудыручы сәбәп хиснең эчтәлеге була, дидек. Кеше күңеленә тәэсир итәрлек сәбәпләр чиксез күп. Шуңа

күрә хисләрнең дә төрләре чиксез күп. Кеше бик еш кайгыра да, шатлана да, ярата да, нәфрәтләнә дә, горурлана да, кимсенә дә, соклана да, көнләшә дә, ачулана да... Кеше авыр хисләреннән тизрәк котылырга тырыша. Юану әзли. Юану да — хиснең бер сыйфаты.

Матур әдәбият кеше хисенең яңарагын, көчлерәген эзли. Укучы автор кичергән хисләрне үзе дә кичерергә тиеш була. Шулай итеп, укучы матур әдәбият аша яңа, тирән хисләр белән баеый. Матур хисләрне хәтерендә саклый. Хискә бай кеше кешелекле кеше була.

Хисләрнең иң әһәмиятлесе, иң киң таралганы — ярату хисе. Ләкин ярату хисенең дә әллә никадәр төре бар. Аеруча әһәмияткә ия булган әчтәлекклеләре бар. Әнигә, әтигә мәхәббәт хисе яки ата-ананың баласына мәхәббәт хисе иң даими, иң кадерле, иң көчле хис исәпләнә.

ӘНИЛӘРГӘ, ӘТИЛӘРГӘ МӘХӘББӘТ ХИСЕ

Зәкия Туфайлова

«Әни» сүзе

«Әни» диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз!
Һич ярамый
«Әни» сүзен таптарга.

Биремнәр һәм сорау

1. Шигырь исеменең мәгънәсен табыгыз.
2. Шигырьне ике өлешкә бүлегез.
3. *«Әни» сүзен таптарга* сүзләренең мәгънәсен әйтегез.
4. Бала ни өчен «Әни» сүзен яңа карга яза?

Сабир Габделмән

Бер сукыр баланың моң-зары

Мин ишетәм, кояш якты, көн якты, дип,
Суларның агышлары бик яхшы, дип;
Күк йөзенең йолдызлары уйнап йөри,
Җир йөзенең мәхлуклары тик ятмый, дип.

Мин ишетәм, киң сәхрәдә гөл үсә, дип,
Болытлар тау-таудай булып күчә, дип;
Адәм угылы башын селкеп хәйран кала
Бакчадагы тамашаларны күрсә, дип.

Мин ишетәм, карлар эри, боз китә, дип,
Су буенда күп кешеләр сәер итә, дип;
Балалар мәктәпләрдә укып-укып,
Гыйлем алып чыгалар, дип, булып әдип.

Галәмгә карау безгә була, дип, ямь,
Үзем төсле балалардан мин ишетәм.
Мин боларның, һичберсен дә теләмимен,
Бер мәртәбә әнкәемне күрсәм икән!

Сораулар

1. Әсәр икегә бүленә. Нинди алым белән бүләсез?
2. Бу шигырьдә нинди хис турында әйтелә?
3. Шигырьдә бала хисе турында язылa. Ә менә сукыр бала бәхетсезлеген сездә хис тудыра алырлык сәбәп дип фараз итсәк, сезнең бу балага карата хисегез нинди?

Илдар Юзеев

Бөркет турында җыр

Хәбәр булып
Килде болыт,
Кояш нурын каплады.
Давыл узды,
Оя тузды, —
Бөркет дустын тапмады.

Очты бөркет,
Төште бөркет,
Йөрәгендә ярасы.
Яшь аралаш
Елмая ул:
Югарыда — баласы.

Ә баласы —
Күз карасы —
Сизмәде дә яшенне.
Ике канат,
Канап-канап,
Зур давылдан яшерде.

Ә баласы —
Күз карасы —
Сизмәде дә яшенне.
Ике канат,
Канап-канап,
Зур давылдан яшерде.

Сораулар һәм бирем

1. Шигырьдә чагыштыру бармы? Каршылык бармы?
2. Шигырьнең мәгънәсен аңлатыгыз.
3. Бөркетнең баласына мөнәсәбәте нинди? Ә баласыныкы?
4. Авторның бөркеткә бәясе нинди?

Абдулла Алиш

Көтмә инде, көтмә

(Әнигә багышлыйм)

Әнә үрдәк бәбкәләре белән,
Ә син ялгыз үзең барасың,
Син көнләшеп аның бәхетеннән
Моңсу гына озатып каласың.

Кая китте синең балаларың,
Арслан күк батыр улларың?
Өмет белән һаман күзәтәсең
Кайтырлар дип, киткән юлларын.

Былтыр койган алма кakларын син
Чикләвекләр җыеп китереп,
«Аларга!» дип, һаман саклыйсыңмы,
Сагыш белән көтеп, тилмереп.

Язлар килер, чәчәк исе бөркеп,
Сыерчыклар кире кайтырлар,
Яңарырлар шунда йөрәгеңдәге
Бертуктаусыз янган кайгылар.

Төшләреңдә һаман алар белән
Көндезләрен укып хатларын,
Теткәләнгән кәгазь битләренең
Һәрбер сүзен инде ятладың.

Өчесенең берсе кайтмасмы дип,
Син көтәрсең һаман аларны,
Ишек каккан саен, кочакларга
Хәзерләнеп сөйгән балаңны.

Көтмә инде, көтмә, изге карчык,
Җир куенында ята улларың,
Чәчәкләргә биреп илгә булган
Мәхәббәтле керсез уйларын.

Биремнәр һәм сорау

1. Шигырьнең эчтәлеге — хис. Шулай булгач, әсәрне ничек таркатабыз?

2. Шигырьдәге кайгы дәрәҗәсен белгерткән урыннарны бергә җыегыз.

3. Юану урыннарын бергә җыегыз.

4. Өлешләрне бәйләүче урынны табыгыз.

Сак-Сок

(Бәет)

Без өйгә кайтмаганда, эзләп тә тапмаганда,
Ачулана иде әнкәй, күңеле тартмаганда.

Беркөнне уйнап йөрдек, кич белән өйгә кердек.
Төн буе каргады әнкәй, иртә үзебезне кош күрдек.

Җидегә чыккан чакта ишектән йортка чыктык,
Кош булу хәсрәтеннән бигрәк күп кайгы йоттык.

Кайтканда әткәй күреп елыйдыр, аһлар орып,
Китәбез урманнарга авылда бераз торып.

Әнкәй дә елый-елый күзләре күрмәс булды,
Безгә дә өйгә кайту бер файда бирмәс булды.

Караңгы урман эче, күк күкрәп, яшен яшьни,
Давыл чыгып, урман гөрли, кар-яңгыр ява башлый.

Җил-давыл күтәрелгәч аерылдык ике якка,
Каргышның сөременнән әйләндек Сакка-Сокка.

Кычкырып кара-каршы, кавышабыз дигән чакта,
Яктылык беленәдер шул кояш чыккан чакта.

Ата-ана догасын төшми дип уйламагыз,
Нәфескә ирек биреп, уен да уйнамагыз.

Бәет кошка әйләнгән малайларның берсе авызыннан сөйләнә. Шигырьдә үзе турында сөйләүчегә **лирик герой** диләр. Лирик герое булган әсәрләргә **лирик шигырь** диләр. «Сак-Сок» бәете — лирик әсәр. Бәетләр дә — җырның бер төре. Анализны җырларга ясаган кебек ясыйбыз.

Биремнәр

1. Әсәрне өлешләргә бүлү өчен нигез табыгыз.
2. Хис дәрәҗәсен күрсәткән урыннарны бергә җыегыз. Кем хисләренең дәрәҗәсе икәнлеген әйтегез.
3. Хиснең сәбәпләрен күрсәткән урыннарны бергә җыегыз.
4. Бәетнең идеясен әйтегез.

Әмирхан Еники

Матурлык

(Бер карт әдип авызыннан)

Күптән, бик күптән булган вакыйга, әмма бүгенгедәй күз алдымда: без, өч шәкерт, бер атка утырып, өяз мәдрәсәсеннән авылыбызга кайтырга чыктык. Дөресрәге, Гыйлемдар белән икәү бер авылга — Чуаркүлгә кайтабыз, ә Бәдретдинне юл өстендәге Ишле авылында калдырып китәргә тиешбез.

Ә Бәдретдин — безнең очраклы юлдашыбыз. Дөрес, без мәдрәсәгә бер вакытта җыелабыз, бер вакытта таралабыз, ләкин моңарчы аның белән бергә кайтырга туры килгәне юк иде әле. Бәдретдин кешегә бер дә йөк булырга яратмый иде. Укулар беткәч тә, ул базарга килгән авылдашларының берсенә ияреп китә дә бара яки ялгыз үзе генә утыз чакрымдагы авылына җәяүләп сыптыра торган иде. Бу юлы инде без аны, үзебез сорап дигәндәй, бергәләп кайтырга күндердек.

Бәдретдин безнең мәдрәсәдә иң ярлы шәкерт иде.

Табигате белән үк ул, ничек дим, шундый тигез, сабыр холыклы бер егет иде. Ялагайлана да белмәс, масая да белмәс, яхшы белән яхшы, ә яман белән алыш-биреше юк... Тагын шунысы кызык: никадәр генә ярлы булмасын, ул берәүдән дә бернәрсә дә сорарга яратмый иде. Гадәттә, шәкертләр аңардан гел анысын-монысын сорап торалар, чөнки аның үз кулы белән ясаган каеш тупсалы, әрҗә сыман сандыгында мәдрәсә тормышы өчен кирәк бөтен нәрсәсе: энәсе дә, җебе дә, уймагы да, безе дә, пәкесе дә, эскәге дә, көзгесе дә, төрле каләмнәре дә, кәгазь-дәфтәрләре дә, хәтта җилем белән балавызы да саклана торган иде. Дөрес, ул калын-калын дәрес китапларына бик мохтаҗ иде. Ләкин булган кадәресен бик пөхтә тышлап, битләре керләнмәсен өчен, көмеш кәгазьдән тоткыч ясап, кадерләп кенә саклый иде.

Ярый, сүз озынга китте, без бит әле өчәүләшеп читән тарантаста хозур гына авылыбызга кайтып барабыз... Табигатьнең иң саф, иң садә, иң ямьле чагы!..

...Юл буе безне тургайлар сайравы озатып барды. Гүя менә төпсез нурлы күктән өстебезгә сихри бер моң тибрәнепчыңлап, өзлексез явып торды. Ә беләсезме, тургай сайравының сихере нәрсәдә? Иң элек, сынаганыгыз бардыр, тургай сайраганда, җир өстенә җиңелчә генә уйчан-моңсу бер тынлык җәелә. Әйтерсең барлык табигать, барлык җан иясе, тәмам

мөкиббән китеп, бары аны гына тыңлый, аны тыңлап сөенечле, сагышлы, ләззәтле бер рәхәткә чума... Икенче сихере шунда ки, тургай сайраганда дөнья, ничектер, искиткеч җәелеп, киңәеп, яктырып киткәндәй була. Әнә шул югарыда кеч-кенә кошчык талпынган күкнең үзе шикелле үк, җир йөзе дә иксез-чиксез булып, гаҗәеп тын, нурлы булып тоела башлый.

Белмим, бу вакытта бүтән кошлар сайрый торгандырмы,— игътибар иткәнем юк, әмма бер кошның тавышы, бөтен җир өсте тургайлар сайравыннан өзлексез чыңлап торса да, безне сискәндереп, колагыбызга килеп керә. Бу — кәккүк! Табигать тарафыннан кешеләрнең исләренә ниндидер бик мөһим бернәрсәне төшерер өчен яратылган күзгә күренмәс сәер кош!.. Юлдан шактый читтә торган күксел урман янын-нан узганда, без аның да тынып калырга мәҗбүр иткән кисәтүле тавышын ишеттек.

Шулай кәефләнеп, күңелле генә кайта торгач, без, ниһаять, кызыл ярлы тауларга каршы тигез үзәнлектә сузылып утырган Ишле авылына да якынлаштык. Юлга чыккач та Бәдретдин безне, Ишледә туктап, чәй эчеп чыгарга чакырган иде. Без, билгеле, кыстатып тормадык, шәриктәшеңә кереп, чәй эчеп, күңел ачып чыгу — шәкертләр өчен табигый бер низам инде ул...

Без фәкыйрь кешеләргә керәсебезне белеп килә идек. Әмма бу кадәр ярлы хуҗалыкны күрербез дип һич тә көтмәгән идек. Шыр кырда утырган бәләкәй генә ялгыз өй үзе искереп-тузып, яртылаш җиргә кереп беткән. Салам түбәсе черен, каралып, тирескә әйләнә башлаган. Ишегалдын кыр үләне басып киткән. Анда чикерткәләр тыз-быз сикерешәләр. Димәк, бернинди аяклы мал да юк...

Өйдән кечерәк буйлы, ак чырайлы, җирән сакаллы, арык-өшән генә бер абзый чыкты. Ул, тарантас янына килеп, бары: «Улым!» — дип кенә Бәдретдин белән күреште, аннары безгә дә шулай сүзсез генә ике кулын сузды һәм шунда ук ат башына барып, аны тугара башлады.

Бәдретдин сандыгын күтәреп өйгә ашыкты. Өй ишегендә бер хатын күренде, ләкин ул ни өчендер тиз генә кире борылды. Бу – Бәдретдиннең әнисе булгандыр инде, тик менә аның ишектән чыгар-чыкмас кире чигенүе безне бераз гаҗәпләндерде...

Өйгә кергәч тә, безнең иң элек күргән кешебез сәке түрендә, стенага терәлеп, текә генә утырган бер бабай булды.

Без бабайга күрешер өчен кулларыбызны суздык. Бабай селкенмәде. Бәдретдин ашыгып әйтеп куйды:

— Бабай, шәкертләр синең белән күрешергә телиләр.

— Ә, шулаймыни, бәрәкалла! — диде бабай, аз гына җанланып һәм безгә кипкән, зур каты кулларын сузды. Күзләре ачык булса да, ул дөм сукыр иде...

Бу өйдә сүз бик аз сөйләнә булса кирәк,— ничектер бик тиз без шуны сизгәндәй булдык. Бабай тып-тын утыра. Бәдретдин әрле-бирле йөренә. Әтисе башта мич буендагы бүкәндә безгә бераз шаккатып утырды да, аннары, торып, сәке кырыена чәй урыны әзерли башлады.

Бераздан чаршау эченнән әкрен генә «Булды, улым!» дигән сүз ишетелде. Бәдретдин, кереп, самавырны алып чыкты. Бу самавырның да борын һәм колак төпләре кургашын белән ямалып беткән иде.

Бәдретдин безгә сәкегә менеп утырырга кушты. Без, менеп, аякларны бөкләп утырдык. Шуннан соң алдыбызга өчаяк белән йомырка тәбәсе килде. Без әле ашка сузылмыйча хуҗаларның утырганын көтә идек. Ләкин бабай да урыныннан кузгалмады, абзый кеше дә бүкәненнән тормады. Шул чагында Бәдретдин, йомшак кына, чаршау эченә дәште:

— Әнкәй, чәй ясарга үзең чык инде...

Чаршау эче бераз тынып торды, аннары киндер күлмәк өстеннән шундый ук киндер алъяпкыч буган, оек-чабаталы хатын, ситсы яулыгының читләрен битенә тартып башын иеп кенә чыкты да самавыр артынарак килеп утырды.

Аңа күтәрелеп карагач та, минем йөрәк әллә нишләп китте. Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды: бичара хатынның бөтен битенкүзен кайчандыр кичергән рәхимсез чәчәк зәхмәте тәмам бозып бетергән иде. Өстенә карап, моны сурәтләп торуы авыр, ничектер тел бармый, ләкин шулай да сул күзенең бөтенләй кысылып, ә уң күзенең иләмсез зураеп калуын әйтмичә булдыра алмыйм, чөнки шушы яшь пәрдәсе аша караган кашсыз-керфексез күзендә бичараның бөтен эчке җаны чагылырга гына тора кебек иде. Әйтерсең бу һич йомылмас яшьлемоңсу күз — аның шәрәләнеп калган бердәнбер күңел көзгесе!

Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә, күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдретдин бу бәхетсез әнисен чакырып алырга һәм безгә

күрсәтергә җөрьәт итте икән? Без бит, гадәттә, кешене куркытырлык ямьсез яки гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз. Хәтта әниебезне дә, әгәр ул менә шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек. Бәдретдин бу кыен хәлне бөтенләй күрми, аңламый микәнни? Әллә күрсә, аңласа да, бик тирән яшерә беләме?

Ә җиңги шул арада чынаякларга чәй ясап, йөзен самавыр артына яшерә төшеп, безгә сузды. Без, башларны күтәрмичә генә, сүзсез генә чәебезне эчәргә тотындык. Бәдретдин, безне кыстап:

— Ягез әле, шәрикләр, ни бары белән ашап кына эчегез, ашап кына!— диде, һәм аның тавышында мин көткән уңайсызлану яки оялу ник кенә бер ишетелсә иде!

Йомырка тәбәсен капкалап, икешәр чынаяк чәй эчкәч, без чәшкеләребезне капладык. Бәдретдин, сыеның ярлылыгыннан булса кирәк, үзалдына, сиздермәскә тырышып кына, бер сулап куйды. Аннары кисәк кенә аягүрә басты да:

— Булмаса, мин сезгә үземнең китапларымны күрсәтим әле,— диде һәм тәрәзә башына ясаган кечкенә шүрлектән бер өем китапларын алып безгә бирде. Без күбрәк, вакыт үтсен өченгә, бу китапларның кайсы укылган, кайсысы укылмаган, кызыкмы-түгелме, шул турыда сөйләшкәләп, карап чыктык.

— Минем бит әле сезгә, шәрикләр, тагын бер күрсәтәсе нәрсәм бар,— диде Бәдретдин һәм, яңадан торып, шүрлектән кечкенә генә скрипка алды. Бу — кулдан гына ясалган, буялмаган, хөрти генә бер скрипка иде. Без гаҗәпләнеп сорадык:

— Кайдан бу синдә?

— Үзем мәтәштергән булдым инде,— диде Бәдретдин һәм скрипканың тоңык кына тавыш чыгарган кылларын көйләргә тотынды. Аның кубыз уйнавын, мандолина чирткәләвен без белә идек. Әмма скрипка!..

— Әй Бәдри, нигә моңарчы яшердең?— дидек без.— Мәдрәсәдә, Сәгыйть скрипкасын алып, үзеңнән уйнаткан булыр идек бит!

— Оста барда кулың тый!— диде Бәдретдин, тыйнак кына елмаеп. Ул айлар буе кул тими яткан скрипкасын шактый озак азапланып көйләде. Шулчакта мин аның әнисенә күтәрелеп карадым: ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек тирән мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән

сихерләнеп, эреп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы,— гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге сихри караштa, бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас ниндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде: ул тапкан бит баланы! Ул имезгән бит аңа күкрәк сөтен! Ул — шушы сөлек кебек егетнең әнисе бит! Шәкерт әнисе, гыйлем иясе булачак кешенең әнисе... Ихтыярсыздан йөрәгем үкси башлап, мин тизрәк башымны түбән идем.

Скрипканың тавышы бик зәгыйфь иде, чеби тавышыдай көчсез-нечкә иде, ләкин бу минутта безнең күңелләргә ул да бик ягымлы, бик тансык иде. Бу ярлы өйнең һавасында ук ниндидер бер авыр сагышлы моң — мәңгелек моң йөзә кебек иде. Текә генә катып утырган ап-ак бабай ни уйлый, бүкәне өстеннән бер генә дә кузгалмаган абзый кеше ни кичерә, — моны белүе һич мөмкин түгел иде. Тик шушы моң эчендә, томан аша караган тулы ай төсле, Бәдретдиннең әнисе үзенең сүзсез шатлыгы белән яктырып утыра. Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана алар арасында?

Бер-ике көй уйнагач, Бәдретдин, ниһаять, әнисенә дәште:

— Әнкәй, сиңа нәрсә уйныйм?

Әнисе, бер генә мәлгә балаларча кызарып, шул ук вакытта куанычыннан тагы да балкыбрак китте, ләкин кайтарып сүз әйтә алмады.

— Әнкәй, син шушы көйне ярата идең бит!— диде Бәдретдин һәм «Салкын чишмә» көен уйный башлады. Аның сүзләре, сүзләреннән дә бигрәк, шулкадәр гади, табигый, җылы-якын итеп дәшүе минем соңгы шикләнүемне дә челпәрәмә китерде. Әнисе өчен уңайсызлану дигән нәрсәнең әсәре дә юк икән Бәдретдиндә!.. Кайда ул уңайсызлану! Берәүне дә күрмичә, бары әнисенә, әнисенең әнә шул башта безне чирканырга мәҗбүр иткән шадра, чалыш, акайган күзле йөзенә генә карап, ул скрипкасын уйнады. Аның бу аз гына моңсу уйчанлык, яшерен генә кызгану белән өртелгән җитди-җылы карашында әнисен өзелеп ярату гына түгел, аны беткәнче аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора кебек иде. Белмим, болай карый алыр өчен күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрьясы ятарга тиештер инде?! Әллә бу шулай бик ямьсез

ана белән бик матур бала яки, киресенчә, бик матур ана белән бик ямьсез бала арасында гына буламы икән?Соңгысы, ихтимал, еш очрый торгандыр, әмма беренчесен ишеткән дә, күргән дә юк иде.

Шулай да безгә кузгалырга вакыт иде инде.

Бәдретдин һәм әтисе безне озатып, киртә буенда янәшә басып калдылар. Юк, алай гына түгел, алар белән бергә безнең артта авыл читендәге иң фәкыйрь йорт, бу йортның безгә билгесез ниндидер тирән сере — бәхетсезлегеме, фаҗигасеме, әллә без аңлаудан гаҗиз бөек бер өмете-бәхетеме торып калды.

Кояш баюга таба борылган иде инде. Ә шулай да тургайлар, көн яктысыннан туя белмәгәндәй, тагын да биеккәрәк менеп, тагын да сузыбрак, ярсыбрак бертөзлексез сайрыйлар да сайрыйлар. Дөнья киң, киң, киң, әләләләләүү! Җире-күге тын, буш, моңсу... бик моңсу миңа! Берни эшли алмыйм үзем белән: самавыр артыннан гына улына карап утырган ана күз алдыма килә дә эчемнән тагын үкси башлыйм... Кемгәдер йодрык селкеп кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!

Әсәрдә ике бер-берсенә бәйләнмәгән вакыйга бар. Аларның берсе — табигать күренеше. Җир өстендә тургай сайравы, күке тавышы. Бу вакыйга авторга әһәмиятле, күрәсең, хикәя ахырында ул аны тагын бер мәртәбә кабатлый. Кабатлануны бер вакыйга дип исәплибез дә табигать күренешен әсәрнең бер өлеше итеп алабыз. Башка вакыйгалар Бәдретдин белән аның әнисе арасындагы мөнәсәбәтне ачыклап киләләр. Бәдретдин өендәге вакыйга, шулай итеп, әсәрнең икенче өлеше була.

Хикәяне икегә бүлдек: анализның беренче адымын ясадык. Икенче адымны, укучылар, үзегез ясагыз.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ике өлеш арасында нинди бәйләнеш бар? Табигать күренешләренең мәгънәсе нәрсәдән гыйбарәт?Тургай вакыйгасын автор ни өчен ике мәртәбә кабатлый?

Әсәрне, башка алымнан файдаланып та, икегә бүлергә мөмкин. Хикәядә күренеп торган каршылык бар: ямьсезлек — матурлык каршылыгы. Бу очракта да анализның икенче адымын үзегез ясагыз.

2. Әсәрдәге вакыйгаларны ике өлешкә аерыгыз: бер өлешен ямьсезлек ягына, икенче өлешен матурлык ягына җыегыз. Һәр ике якка исем бирегез. Ике өлеш арасындагы бәйләнешне табыгыз.
3. Лирик геройның хисе турында сөйләгез. Хисенең дәрәҗәсен, сәбәбен күрсәткән урыннарны табыгыз.
4. Лирик герой кем ул? Сез аны ничек итеп күз алдына китерәсез? Ул сезгә охшыймы, юкмы? Ни өчен охшый, охшамаса, ни өчен охшамый? Шул темага язма эш — иншa язып килегез. Иншаның исемен «Шәкерт» дип тә, «Әдип хәтере» дип тә куярга мөмкин.

Равил Фәйзуллин

Минем әти

Философ булмаган әти.
Ә минем кирәкне белеп,
Өйләнгән минем әти.

Галим дә булмаган әти.
Ә миңа җылы кирәккәч,
Утын яруның рәтенә
Өйрәнгән минем әти.

Җырчы да булмаган әти.
Ә миңа бишек силәсен
Зыңлап торганын ясарга
Өйрәнгән минем әти.

Рәссам да булмаган әти.
Ә миңа салават күперен
Чыкта да күрә белергә
Өйрәтте минем әти.

Шагыйрь дә булмаган әти.
Ә мине көйгә кертергә
Бер-ике йомры сүзне
Өйрәнгән минем әти!

Герой да булмаган әти.
Ә сугышта алган җөен
Хәтта миңа күрсәтмәскә
Өйрәнгән минем әти!

Син Алла да түгел, әти,
Фәрештә дә түгел, әти,
Син бары әти, әти.

Биремнәр

1. Шигырьгә анализ ясагыз. Анализ нәтиҗәсендә әти кешенең улын ничек яратуын белегез.
2. Улының әтисенә булган хисе турында сөйләгез.

Муса Җәлил

Мәхкүм

Хөкем булды бүген, аны үлем
Җәзасына хөкем иттеләр.
Ул еламый, соңгы күз яшьләре
Күптән инде агып киттеләр...

Төрмә тып-тын; моңсу караш белән
Күктән карый тулган ай гына.
Ә ул, мескен, балам — йөрәк парәм —
Ятим үсә диеп кайгыра.

Биремнәр

Әсәргә анализ ясагыз. Шигырьне Илдар Юзеевнең «Бөркет турында җыр» шигыре белән чагыштырыгыз. Уртак якларын табыгыз.

Илсөяр Иксанова

Әни

«Кичә төндә,— дидең, — ай тотылды,
И җәлләдем айны, бәгырем».
Әни, әни, түп-түгәрәк чакта
Белсәк икән айның кадерен.

Бик сагынсам сине, күккә карыйм,
Син үзең дә ай күк, и әни!
Бүген айның бер кырые китек —
Күңелемә булды әллә ни.

Бүген синең бер шатлыгың кимдер:
Уйларыңда миндер, мөгаен...
Сарлан күкләренә барып чыксаң,
Әниемне күрче, и аем!

Хәбәрләрем җиткер, кайтыр, диген,
Тиздән кайтыр, диген, савыгып...
Әни, әни, синең сагышларың
Баш очымда тора, ай булып.

Биремнәр

1. Шигырьнең ике образны янәшә куеп төзелүе күренеп тора. Метафора һәм төп образ яки вакыйга дип икегә бүлегез.
2. Метафора өстәгән эчтәлек аша лирик геройның әнисенә мәхәббәте турында сөйләгез.
3. Әни кешенең үз хисләре турында сөйләгез.

Клара Булатова

Ана шатлыгы

Ник көенәм дигәндә,
Ник борчылам дигәндә —
Чирләп-нитеп китмәгәе:
Улым йөри идәндә.

Берни дә белми әле,
Өстенә киМи әле.
Үрмәли генә әле,
Бик нәни генә әле.

Ник сөенәм дигәндә,
Нигә көләм дигәндә —
Өйләремне ямьләндереп,
Улым уйный идәндә!

Бирем

Бу шигырь нинди алым белән төзелгән? Өлешләрне табыгыз, өйрәнегез һәм шигырьнең эчтәлеген сөйләгез.

ДУСЛЫК ХИСЕ

Һади Такташ

Мокамай[1]

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...
Алар мәңге минем хыялымда
Шаулый-шаулый яфрак ярырлар,
Карт имәннәр, калмый минем арттан,
Кая барсам, озатып барырлар...
Бер җирдә юк андый ак каеннар,
Бер җирдә юк андый урманнар,
Бер җирдә юк камыш сабаклары —
Андагыдай шаулый торганнар...

---

[1] Мокамай — кушамат. Дөресе — Мөхәммәтҗан. Ул Сыркыды авылының Бәкер исемле иң ярлы бер кешенең баласы иде. Соңгы елларда авылда, арба тәгәрмәче урлауда гаепләнеп, җыенда кыйналган һәм, идән астына ябылып, шунда үзен үзе суеп үтергән *(Һ. Такташ искәрмәсе).*

Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...
Беребез сары чәчле, беребез кара:
Сары чәчлесе ул мин идем;
Кара чәчле, коңгырт кара күзле,
Кәкре аяклы дустым, җанкисәгем,
Ул, Мокамай бәгърем, син идең...
Ак каенга асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга таба юл алдым;
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым...
Ә син менәлмәдең,
Калдың,
Югалдың...

Әкияттәге ике бала кебек —
Икебез дә кара борынлы,
Зурлар кебек, кулны артка куеп
Йөри идек таптап болынны...
Һәрбер нәрсә безгә яңа иде,
Һәрнәрсәгә исебез китә иде,
Бернәрсә дә бездән качмый иде,
Бар нәрсәгә кулыбыз җитә иде...
Күпме кыен күрдек шуның өчен,
Күпме тал чыбыгы ашадык;
Әкияттәге ике бала кебек,
Күпме «җәфа чигеп» яшәдек...
Кем уйлаган шушы шаярулар
Синдә кәсеп булып калыр дип,
Уйнап башланган эш тормышыңны
Һәлакәткә алып барыр дип...
Хат язсам да хәзер соңга калдым,
Укымассың минем хатымны,
Ләкин минем бурычым, Мөхәммәтҗан,
Йолу синең яман атыңны!
Син гомереңне усал исем белән,
Канлы пычак белән чикләдең...
Әллә ничек булды синең гомер,
Син, Мокамай, әллә нишләдең!..

Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...
Ак каенга асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым;
Менгән саен җирнең матурлыгын,
Яктылыгын күбрәк күралдым...
Ә син менәлмәдең...
Калдың, югалдың...

Үткәннәрем авыр әкият минем,—
Ул әкиятне әгәр сөйләгәндә
Чагылып китсә синең күләгәң,
Юк, юк,
Мин ант итәм: һичбер вакытта да
Сине карак итеп сөйләмәм...
Син яшәргә хаклы кеше идең,
Син яшәргә җирдә теләдең,
Тик син ачлык тырнагыннан,
Түбәнлектән
Чыгу юлын гына белмәдең...
Ә бит
Бергә чабаталар үреп йөргән чакта,
Син остарак миннән үрәйдең,
Минем матур итеп үрәлмәүне
Булдыксызлыгымнан күрәйдең...
Ник соң болай булды әле,
Ничек һәлакәтең күрмәдең,
Ник, Мокамай, соң син тормышыңны
Чабатаңдай матур үрмәдең!!

Син гомереңне усал исем белән,
Канлы пычак белән чикләдең;
Әллә ничек булды синең гомер,
Син, Мокамай, әллә нишләдең!..
Ә бит безнең гомер матур урманнарда
Май аедай матур башланды;
Әкияттәге ике бала кебек,
Икебез ике якка ташланды...

Синең тормыш авыр әкият булды,
Ул әкиятнең соңгы битләрен
Син зур исем, мәңге онытылмаслык
Эшләр белән бизәп китмәдең...
Син адаштың,
Ләкин син яхшы идең,
Синең яхшы иде күңелең,
Тик белмәдең тормыш баткагыннан
Ялгыз чыгу мөмкин түгелен...
Син белмәдең,
Кешеләр җирдә тормыш баткагыннан
Чыгу юлын бергә эзлиләр;
Ялгыз калып, ачтан үлмәс өчен
Күмәк тормыш җирдә төзиләр...
Үткәнемне әкият итеп сөйләгәндә
Чагылып китсә синең күләгәң,
Юк, Мокамай, һичбер вакытта да
Сине усал итеп сөйләмәм...
Син ярлы идең, ләкин эш сөя идең,
Синең яхшы иде күңелең,—
Син белмәдең сыйнфый бөлгенлектән
Алай чыгу мөмкин түгелен...

Биремнәр

1. Әсәрдәге чагыштыруларны, каршылыкларны, кабатлауларны, мөстәкыйль вакыйгаларны табыгыз. Бу алымнарның кайсысы әсәрне икегә бүлү өчен нигез була ала?
2. Әсәрне икегә бүлегез, һәр өлешкә исем бирегез.
3. «Шаулый» сүзенең мәгънәсен табыгыз.
4. Дуслык, тугрылык хисе белән бәйләнешле башка хисләр турында сөйләгез.

Күренекле татар шагыйре Хәсән Туфан белән Һади Такташ бик дус булганнар. Такташ 1931 елда тиф авыруыннан кинәт үлә. Тиздән Хәсән Туфан да туган-үскән җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр була. Бер дә юкка гаепләп, аны сөргенгә алып китәләр. Хәсән Туфан гомере буе якын дустын сагынып, юксынып яши. Дустына багышлап, ул күп шигырьләр яза. «Ә үткәнгә хатлар бармыйлар» шигыре — шундый әсәрләрнең берсе.

Хәсән Туфан

Ә үткәнгә хатлар бармыйлар

Күтәренке шундый
Безнең күңел,
Шундый тирән безнең куаныч:
Бер-беребезне гүя өч көн түгел;
Ә утыз ел күрми торганбыз!

Сөйләшүләр безнең, киңәшүләр
Шундый матур гөрләп куйгалый:
Утыра монда өстәл тирәсендә
Ике Хәсән гүя, дүрт Һади...

Беребезнең сүзе бетәр-бетмәс
Икенчебез баса,
Сүз башлап,
Гөрләп тора бүлмә, әйтерсең лә
Тугыз Туфан анда, ун Такташ!..
Юксынырмын,
Әгәр еллар миңа
Агач йөрәк биреп китмәсә;
Юксынырмын,
Әгәр кешегә хас
Сыйфатларым корып бетмәсә!
Юк, бетмиләр сагыну-саргаюлар,
Алар бездә арта баралар.
Чагылышы булып шуның менә
Йөрәгемнән яшьләр тамалар.

Биремнәр

1. Авторның сагыну дәрәҗәсен сөйләгез. Сагыну дәрәҗәсе сурәтләнгән урыннарны табыгыз.
2. «Йөрәгемнән яшьләр тамалар»,— ди автор. Ни өчен шулай ди? Хәсрәтенең сәбәбен әйтеп карагыз.
3. Шигырьне икегә бүлик. Беренче өлештә автор хәтерендә калган вакыйганы сөйли. Аңа *хәтер* дип исем бирик. Шигырьнең икенче өлешен табыгыз.

Шәүкәт Галиев

Рәхмәтләр хакында

Җиргә төшкәч
Бияләе,
Гафур алып
Биргән иде,
Динә аңа:
— Рәхмәт,— диде.
Малайның да
Җылы сүзгә
Кәеф килде.
Елмайды да:
— Рәхмәтеңә
Рәхмәт! — диде.
Кыз җавапсыз
Калсын диме?
Җавап бирде:
— Рәхмәтемә
Рәхмәт өчен
Рәхмәт инде!
Малай аңа
Башын иде:
— Рәхмәтемә
Рәхмәт өчен
Рәхмәтеңә
Рәхмәт,— диде.
Динә көлде.
Бик күңелле,
Рәхәт иде.
...Җиргә төшкән
Бияләйгә
Рәхмәт инде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьдә кабатлану күп. Ике төрле кабатлануны ике өлешкә җыегыз. Икесенә дә исем бирегез.
2. Җиргә төшкән бияләй вакыйгасы башта һәм ахырда кабатлана. Мәгънә табуны өйрәнгән дәресне исегезгә төшерегез. Мондый очракта икенче мәртәбә кабатланган өлешнең мәгънәсе үзгәрә, дидек. Димәк, «Җиргә төшкән бияләйгә рәхмәт инде» кабатлануында яңа мәгънә бар. Шул мәгънәне табыгыз.
3. Бияләйгә рәхмәтне кем әйтә? Ни өчен?
4. Гафур белән Динә бияләй аркасында танышалар. Динәнең бияләе төшмәгән булса, бәлки, танышмаган да булырлар иде. Әйдәгез, бергәләп уйлап карыйк, бу танышуның дәвамы дуслык була аламы? Була алса, ни өчен, була алмаса да ни өчен икәнлеген аңлатырга кирәк.

Алтын балдак

(Татар халык әкияте)

Карт белән карчыкның бер генә малайлары бар. Болар үзләре бик бай түгел икән. Берзаман карт үлеп китә. Болар бай булмаса да, карттан өч йөз тәңкә акча калган икән. Торабара малай үсә. Малайны карчык базарга чыгармакчы була. «Йорт кирәге алып кайт»,— дип, бер йөз тәңкә акча бирә.

Нәрсә алырга икәнен белми бу яшь малай. Йөри торгач, моңа туры килә бер песи баласы сатучы кеше.

— Йорт кирәгенә ярыймы бу, абый?— дип сорый малай.

— Йорт песисез тормый, йортта иң кирәк әйбер бу,— ди сатучы.— Кыйммәт тә түгел, йөз тәңкә генә.

Песине алып кайта бу. Әнисе, песи баласын күргәч:

— Әй улым, акчаны юкка әрәм итәсең, безгә нәрсәгә ул,— ди.

Икенче атна җиткәч, малайга тагын йөз тәңкә акча бирә:

— Юк-бар нәрсәгә акчаны әрәм итмә, йорт кирәген алып кайт,— ди.

Йөри бу базарда, алырга һичнәрсә таба алмый. Моңар туры килә бер эт баласы. Малай сатучыдан сорый:

— Абый, йорт кирәгенә ярыймы бу?— ди. Теге әйтә:

— Йорт өчен иң кирәкле бу, йорт этсез тормый. Бәясе дә бер йөз тәңкә генә,— ди.

Сатып алып кайта эт баласын анасы янына. Анасы әйтә:

— Әй улым, улым, безгә эт нәрсәгә соң?— дип ачулана. Икенче базар килеп җитә. Карчык малаена соңгы йөз тәңкәсен бирә.

— Юк нәрсәгә әрәм итмә, йорт кирәген генә алып кайт,— ди.

Бу юлы малай йөз тәңкәгә елан алып кайта. Әнисенә күрсәтә:

— Менә мин елан алып кайттым,— ди,— абый йорт елансыз тормый дип әйтте,— ди. Анасы моңа ачулана.

— Без ярлы кешеләр,— ди,— хәзер хәер сорашып тамак туйдырырга калабыз, елан ул сөтсез тормый,— ди.

Болар көн үсәләр, төн үсәләр. Песи баласы песи булып җитте, эт баласы эт булып җитте. Елан баласы зур елан булды. Беркөнне елан телгә килде:

— Син, егет, мине тау тишегенә ояма илтеп җибәр,— ди. Егет еланны оясына илтеп куйды. Елан оясына кереп, кире әйләнеп чыкты.

— Син, егет, мине сатып алдың, тамагымны туйдырдың, бер сүз дә әйтмәдең, ояма китер дигәч китереп куйдың. Менә сиңа шуның өчен бүләк итеп алтын балдак бирәм, җиде төн уртасында шул алтын балдакны алып чыгып сызгырырсың,— ди.

— Син балдакны бер дә авызыңнан төшермә, югыйсә әүвәлгечә хәерче булырсың,— ди.

Җиде төн уртасы җиткәч, егет балдакны авызына кабып сызгыра. Моның янына биш егет килеп баса. Бу егетләр әйтә:

— Ни мохтаҗың бар?— ди. Егетнең бу юлы мохтаҗы булмый. Болай, сынау өчен генә сызгырткан икән. Икенче көнне егет әнисенә әйтә:

— Әни, патшага барып, кызын сора әле,— ди.

— Әй улым, нишләп патша кадәр патша кызын сиңа бирсен,— ди.

— Бирер, әни,— ди егет.

Анасы патша янына бара, кызын сорый.

— Без кушкан эшне эшли алсагыз, кызымны бирермен,— ди патша.— Эшебез шул: безнеке шикелле йортларыгыз булсын, ике йорт арасында юл булсын, юл буйларында алмагачлар үсеп торсын,— ди.

Әнисе бу сүзләрне малаена кайтып сөйләде. Төн булды. Егет алтын балдакны авызына кабып сызгырып җибәрде — биш егет килеп басты:

— Ни мохтаҗың бар, егет?— диләр.

— Патшаныкы шикелле йортлар булсын, патша белән ике арада юл салынган булсын, юл читләрендә алмагачлар үсеп торсын,— ди.

Таң атты, бу нәрсәләр һәммәсе дә булды. Ләкин патша әйтә:

— Яңадан бер эш кушам, анысын да үтәсәгез, кыз сезнеке. Эшем шул: безнең өй турында Идел булсын, Иделдә пароход йөрсен, аңа чуен күпер салынган булсын,— ди.

Җиде төн уртасында егет чыгып сызгырды, биш егеткә йомышын әйтте. Таң аткач, патшаның йокыдан торуына өй каршында Идел, Иделгә күпер салынган, пароходлар йөреп тора. Патша бу юлы кызын бирергә риза булды.

Зур туйлар ясап, егет патша кызын алды. Бергә тора башладылар. Беркөнне кыз егеткә әйтә:

— Сез әүвәл ярлы идегез, ничек баедыгыз?— ди.

— Минем балдак исән булсын,— дип мактана егет. Ә бит елан аңа әйтмәскә кушкан иде. Икенче көнне үк патша кызы алтын балдакны бу куйган җирдән алды да авызына кабып сызгырды. Әлеге биш егеткә әйтте:

— Егетнең бу юллары бетсен, йортлары бетсен, ул әүвәлге мунчасында калсын, ә мине фәлән патшага илтеп ташлагыз,— ди.

Йокысыннан торуга, егетнең мунчасы гына кала. Теге кыз икенче патша малаена киткән икән.

Бу хәлне күреп, патшаның ачуы килә. Егетне төрмәгә яптыра.

Эт белән мәче аптырашалар: «Кая безнең хуҗа?»— диләр. Песи әйтә:

— Безнең алтын балдак юк бит хәзер, аны патша кызы алды, ә үзе фәлән патша малаена китте. Безнең хуҗабыз төрмәдә ята, аны коткарырга кирәк,— ди. Эт белән мәче алтын балдакны эзләп чыгып китәләр.

Бара-бара, болар патша йортына да барып җиттеләр. Эт әйтте:

— Мин керә дә алмыйм, керсәм дә эш чыкмый, син, песи дус, ярдәм ит, кереп чык,— ди. Песи кереп китә. Патша кызы бүлмәсен дә тапты. Алтын балдакны кайда куйганын күзәтеп ята. Кыз балдакны авызына кабып ята икән. Патша кызы берзаман йокыга китте. Шунда бер тычкан йөри. Шул тычканны песи тотты. Ашамакчы булды, тычкан аңа:

— Син мине ашама, мин синең теләсә нинди гозереңне үтәрмен,— ди.

— Әнә шул патша кызының авызындагы балдакны ничек алабыз?— ди песи.

— Мине коткарсаң, алып бирермен,— ди тычкан. Тычкан менде дә патша кызының танавына койрыгын тыгып болгады. Болгаган иде, патша кызының төчкереп җибәрүе булды, алтын балдак атылып килеп тә чыкты. Песи алтын балдакны алып та капты, чыгып та чапты. Кайтканда эт әйтә:

— Миңа бир, Идел чыкканда, дулкын бәрер, син дулкын астында калырсың, балдакны югалтырсың,— ди.

— Үзем алган, хуҗага үзем алып кайтып бирәм,— дип карыша песи.

Менә болар Иделгә кереп киттеләр. Песи дулкын астында калды. Песи алтын балдакны төшереп җибәргән. Шунда елымчылар йөри. Болар ат белән бик зур елым сөйрәп чыгаралар. Бәхеткә каршы, алтын балдакны йоткан балык та эләгеп чыга. Алтын балдак әллә каян елтырап күренеп тора. Эт бу балыкны ала да чаба. Бер кавем җир киткәч, балыкны ярып карадылар — алтын балдак килеп чыкты. Хәзер эт балдакны песигә бирмәде, үзе алып кайтты.

Хуҗа, алтын балдак кайткач, бик сөенде. Җиде төн уртасы килеп җитте, сызгырып җибәрде, биш егет килеп басты.

— Мохтаҗым шул: мине төрмәдән чыгарыгыз, йортларым, юлларым элеккечә булсын, минем хатынны алып кайтыгыз,— дип боерды егет.

Йортлар әүвәлгечә була, патша кызын бу егетнең йокыдан торуына алып кайтып каршысына бастырдылар. Егет сигездән үргән камчы белән патша кызын бик нык пешерде:

— Ник болай иттең син! — дип. Патша кызы аяк астына егылып гозер итте:

— Алай булмас идем инде,— дип. Патша кызын шулай акылга китерде бу. Патша моның белән ризалашып, бу монда патша булып калды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Темалары охшаш вакыйгаларны бергә җыегыз. Аны әсәрнең бер өлеше дип исәпләгез дә гомуми исем бирегез.
2. Песи, эт, елан турында сөйләгез. Алар катнашкан вакыйгаларда охшашлык бармы? Алар ничек егетнең дусларына әвереләләр?
3. Малайның сатып алган дусларын тәрбияләп үстерүенә бер сүз белән бәя бирегез. Аннан соң патша кызына бәя бирегез.
4. Дуслык ничек башлана? Әкиятне Ш. Галиевнең «Рәхмәтләр хакында» шигыре белән чагыштырыгыз. Дуслык башлану сәбәпләренең уртак ягын табыгыз.

Турай батыр

(Татар халык әкияте)

Булган, ди, борын заманда бер хатын. Аның булган, ди, өч өе: берсе кешенеке, берсе күршенеке, берсе салмаган, бурасын да алмаган, шунлыктан ул алачыкта гына торган, ди. Алачыгы шәп икән: һава белән капланган, җилләр белән мүкләнгән. Ач иде, ди, ул, тук иде, ди, алачыкта гына торса да, кешегә чыгу гадәте юк иде, ди.

Шул хатынның булган, ди, Турай атлы бер улы. Чамасыз да гәүдәле, чамасыз да көчле булган, ди, ул егет. Тик бу егетнең бер кайгысы бар икән: буйга-сынга килсә дә, тескә-биткә чибәр булса да, аңа кызлар чыкмаган. Турай яучы җибәрсә, кулларын гына селкиләр иде, ди. Алачыкта торган кеше кайда килен төшерсен дә кайда бала үстерсен?

Йөргән-йөргән дә бу, анасына шундый сүз әйткән:

— Әни, китимче мин,— дигән.— Читкә чыгыйм, ил-көн күрим. Бәлки, кулга мал төшәр, бәлки, берәр кыз очрар, сиңа килен, миңа хатын чыгар.

Анасы әйткән:

— Ай улым, китүен китәрсең анысы, син бит минем бер генәм. Китеп югалсаң, синсез нишләрмен, сиңа ул-бу булса, хәлеңне ничек белермен?

Егет каз каурыен алган да матчага кыстырган:

— Син кайгырма, әни, мин югалмам. Әгәр миңа ул-бу була калса, шушы каурыйдан кан тамар.

Шулай чыгып китте, ди, бу егет. Бара, ди, бара, ди. Бара торгач, биек тау буена барып җитте, ди. Гөрелдәгән тавышка күтәрелеп караса, ике тау бер-берсе белән чәкешә. Якынрак килсә шаккатты: бу тауларны бер батыр шулай бер-берсенә бәреп чәкештереп утыра икән.

— Тауларны нигә болай чәкештерәсең?— дип сораган Турай батыр.

— Синең киләсеңне белдем дә, чакма чагып, ут чыгарып, ботка пешермәкче булдым,— дигән теге егет.

Бу батыр Тауказар атлы булган, ди.

Ярый, болар хәзер ике иптәш булдылар, икәүләп киттеләр, ди. Бара торгач, очраган, ди, боларга өченче батыр. Монысы ташны сыга да ыргыта, сыга да ыргыта, ди.

— Бу ташларны нигә сыгасың?— дип сорадылар.

— Сезнең киләчәгегезне белдем дә, ботка пешерермен дип, таштан май чыгарып маташам,— дигән теге егет.

Бу батыр Ташказар атлы булган.

Өчәүләп бара торгач барып җиттеләр, ди, болар бер карурманга. Шундый караңгы, шундый калын, ди, гомердә дә кеше аяк басмаган.

Бара торгач, күрәләр бер йорт. Эчендә бөтен кирәк-ярагы бар, хуҗалары гына юк.

Уйлашалар: монда туктап бераз ял итик, кош-корт аткалыйк, аннан соң күз күрер. Тауказар белән Турай чыгып китәләр ауга. Ташказар өйдә аш пешереп кала. Аш өлгерде дигәндә генә, берәү ишек кага.

Ташказар ишекне ачуга, батыраеп, ирәеп килеп керә бер кәрлә. Үзе бер карыш — сакалы биш карыш.

— Сәкегә күтәреп утырт,— ди.— Аш бир,— ди.— Миңа болай гына җитми, казаны белән китер!— ди. Ташказар:

— Юк, казаны белән бирә алмыйм, иптәшләремне туйдырасым бар,— дип әйтә генә башлый, теге аңа аяк тибеп кенә кычкыра:

— Әһә, әле син шулаймы! Китер тизрәк!

Шуннан соң Ташказар ашны казаны белән китереп куя. Үзе бер карыш — сакалы биш карыш, ашны ашап бетергәннән соң, Ташказарны үтереп китеп тә бара.

Турай батыр белән Тауказар бу хәлне күреп кайгырышалар, аптырыйлар. Икенче көнне Турай батыр ауга үзе генә чыгып китә.

Тауказар ашны өлгертеп кенә җиткергән иде, тагын ишек кагалар. Тагын теге кәрлә керә:

— Күтәреп утырт! Ашны казаны белән бир!— ди. Ашап бетергәч, Тауказарны үтереп, тагын чыгып югала.

Турай батыр кайтып бик аптырады, кайгырды. Кем эше булыр бу?

Ул көнне Турай батыр ауга чыкмады. Аш пешеп кенә өлгергән иде, тагын ишекне дөбердәтәләр:

— Ач ишекне!

Турай батыр әйтте:

— Килә белгәнсең икән, ача да бел!

Үзе бер карыш — сакалы биш карыш бу юлы ишекне үзе ачып керә.

— Сәкегә күтәреп утырт,— ди.

— Керә белгәнсең икән, менеп утыра белерсең.

Кәрлә бу юлы сәкегә дә үзе менеп утыра. Үзе сәке өстендә, сакалының очы ишек төбендә.

— Аш бир!

— Ашыйсың килсә, үзең пешереп аша,— ди Турай батыр.

Шулай гына дигән иде, үзе бер карыш — сакалы биш карышның сикереп төшүе була, болар дөнья куптарып сугыша башлыйлар. Турай батыр тегене сакалыннан урап алып китереп бәрә, кәрлә биш карыш тез тиңентен идәнгә иңә. Үзе бер карыш — сакалы биш карыш моны шундый тотып чөя, Турай батыр өйнең әрлекләрен, кыекларын җимереп, күккә очып китә. Көн сугыштылар болар, төн сугыштылар, шулай да өченче тәүлеккә киткәндә, кәрлә Турай батырны җиңде.

Турай батырның үлүе була, матчага кыстырган каурыйдан кан тама башлый. Турайның анасы моны күреп ала да, зар елап, юлга чыгып китә.

— Ай балам!— ди.— Ниләр булды сиңа, кайда син?

Кайда җәяү, кайда ат белән, кайда тауларны турыдан кичеп, кайда әйләнгеч юлларны турайтып бара торгач килеп тапты, ди, бу улын. Укыды, ди, өрде, ди, улының күкрәгенә җылы сулышын. Шулай итә торгач, Турай күзен ачты, ди.

Шуннан соң Турай батыр анасыннан иптәшләрен дә терелтүен үтенергә тотынган. Әмма анасы әйткән:

— Ай-һай, балам, булыр микән! Мин бит сине, балам булганга, үземнең йөрәк җылысын өреп кенә терелттем,— дигән.

Турай батыр анасыннан тагын ялына башлаган:

— Алар миңа туганнарым кебек якын, терелтсәнә, әни,— дигән.

Шуннан соң анасы озак уйлап торган да әйткән:

— Ярый, ана булган кеше баласы хакына кулыннан килгәнне кызганмас, тик син белеп тор, боларны терелтсәм, сулыйсы сулышларым кыскарыр, юньле кеше булсалар гына терелтәм,— дигән.

Тагын шулай, улын җылыткан шикелле, күкрәкләренә җылы сулышын өреп, Турайның иптәшләрен дә терелткән. Тик үзе шунда ук хәлсезләнеп ауган.

Өч егет Турайның әнисен бик тәрбияләгәннәр. Аны бик хөрмәтләп исән-сау авылына озатканнар да өч батыр тагын юлга чыгып киткәннәр.

Бераз баргач җиткәннәр болар бер коега. Турай батыр әйткән:

— Коега мин төшәм, вакыт җиткәч, сезгә белдерермен, тартып чыгарырсыз,— дигән.

Кое төбендә ерак та түгел шәһәр сыман нәрсә күренә. Шул яктан бик яман акырган тавыш ишетелә, ди. Шәһәр читендә яшәүче бер әбидән сораган:

— Әби, бу нинди яман аваз?— дигән.

— Диюләр патшасы, дөньяга патша кызлары урлап кайтырга чыкканда, батырлар белән сугышкан икән дә шунда бик каты яраланып кайткан, диләр. Сызлануына түзә алмыйча кычкыра торгандыр,— ди карчык.

— Ни булса булыр, әби, барыйм инде мин, юлын гына өйрәтсәнә! — ди.

— Менә шулай-шулай барасың,— ди карчык,— диюнең үзен, көчең җитсә, көч белән җиңәрсең, тик сакчыларын яхшылык белән генә җиңә алырсың. Бер йөк печән, бер түш ит, кием-салым, ашамлык-эчемлек алып бар.

Барып җитте, ди, Турай батыр беренче капкага. Тора, ди, капка төбендә эчләре кипкән, күзләрен кан баскан тау тикле бер үгез. Дию патшасы, тамаклары ачса усалрак булырлар дип, сакчыларын ач тота икән. Үгез үкереп моның өстенә ташланганда, инде изеп ташлый дип торганда, Турай батыр

ыргыткан аңа бер йөк печән. Үгез үкерә-үкерә печән ашый калган. Турай батыр эчке якка узган.

Икенче капкада ташланды, ди, моңа ажгырып торган бер көтү ач эт. Инде өзгәләп ташлыйлар дигәндә, Турай батыр ташлый боларга бер түш ит. Этләр ырылдашып ашый калды, Турай батыр тагын да эчкәрәк юл алды.

Өченче капкада тора, ди, сакта шәп-шәрә бер кеше. Кыйнала торгач, тәне җөйләнеп беткән, усаллыктан көеп, зәһәрләнеп беткән. Турай батыр моңа өстеннән салып чикмәнен кидерткән.

Сакчы моңа әйткән:

— Әй яхшы күңелле адәм баласы, гомеремдә беренче тапкыр тәнем җылыга иреште, колагым беренче тапкыр ягымлы сүз ишетте. Бар, туган, юлың ак булсын. Коткар адәм балаларын,— дигән.

Диюнең сараена барып җитәрәк, моның каршына бер бите ай, бер бите кояш төсле матур кыз йөгереп чыккан. Кәрлә дию урлап кайткан патша кызлары өчәү икән. Турай батыр, ашап-эчеп, мунча кереп, өч көн кунак булганнан соң, килеп басты, ди, диюнең каршысына:

— Йә, алыштанмы, салыштанмы?

Үзе бер карыш — сакалы биш карыш туптай атылып торды да җиңнәрен сызгана-сызгана әйтте, ди:

— Алыштан да булыр, салыштан да булыр. Әле минем белән көрәшәсе батыр тумаган,— дип, Турай батырның яңак төбенә берне кундырган икән, егет шунда ук идәнгә ауган.

— Безнең якта алай сукмыйлар, менә болай сугалар! — дигән Турай һәм диюнең сакалыннан урап алып, болгый-болгый шундый китереп бәргән, дию аяк астында көл булган. Шуннан соң Турай батыр, дию патшасының барлык алтын-көмешләрен, асылташларын җыеп, кызларны әлеге кое төбенә алып киткән. Теге ике кызга әйткән:

— Өстә минем ике иптәшем көтеп тора. Алар өйләнмәгән егетләр. Телисез икән, кайткач туй итәрсез. Ә син, Чибәркәй, әгәр мине ошатсаң, минем анама килен, миңа хатын булырсың.

Башта алтын-көмешне чыгардылар, ди. Аннан соң патша кызлары менеп киткән. Иң арттан, бауга утырып, Турай батыр үзе дә кузгалган. Инде чыгып җитәм дигәндә генә, бау өзелгән. Турай батыр кое төбенә төшеп киткән... Инде нишләргә? Алтын-көмеш тагын бер хәл, мал егетне түгел,

егет малны таба. Турай батырны иптәшләренең хыянәте бик рәнҗеткән. Аларның әшәкелеге йөрәгенә тоз сипкән.

Тагын әлеге карчыкка барган, ди, бу.

— Әби, минем юл уңмады бит әле. Дөньяга чыгарга бүтән берәр әмәл белмисеңме? Белсәң өйрәтсәнә! — дигән.

Әби бер сукмак күрсәткән:

— Менә шуннан китсәң, бара торгач, бер су булыр. Шул суның уртасында утрау булыр, анда бик юан, күп ботаклы карама үсеп утырыр. Шул карама төбендә ике кәҗә тәкәсе күрерсең. Шул тәкәләрнең агына ябышсаң, дөньяга алып чыгар.

Турай батыр, әбигә бик күп рәхмәтләр укып, әлеге сукмактан киткән. Көн киткән, төн киткән, өченче көнне бик зур су буена барып җиткән. Карый: су уртасында утрау, утрауда карама, карама төбендә үгез тикле ике кәҗә тәкәсе сөзешә. Берсе ак, берсе кара. Ничек кирәк алай утрауга кердe дә бу тиз генә ак тәкәнең аягына ябышты. Ул да түгел, кинәт җил чыккандай, очып киткәндәй булды, дөньялар яктырып китте. Әйбәтләбрәк караса, бу дөньяга килеп чыккан, имеш.

Турай батыр, исән-сау кайтуына бик куанып, өсләрен каккалый да тагын кузгалып китә. Бара-бара эзләр күрә. Ике ир кеше, өч хатын-кыз узган. Ул да түгел, ашарга туктаган урыннарында көлгә күмелгән төче күмәчләр дә бар. Шуннан чамалый инде бу: күмәчләрне теге чибәр кыз аңарга дип күмеп калдырган була бит инде.

Шул эзләргә басып кайта торгач, бер шәһәргә җитә бу. Шәһәрнең нәкъ уртасында ике йорт салып яталар.

— Бу йортларны патша салдырамы, әллә берәр баймы? — дип сорый Турай батыр. Моңар әйтәләр:

— Юк, бу йортларны дию патшасын җиңеп кайтучы ике батыр салдыра.

Турай батыр бу хәбәрне мыегына чорный да, өс-башын алыштырып, соранучы кыяфәтенә керә. Өйләренә барып керә. Тегеләр ашап-эчеп утыралар. Моңа да бер сынык икмәк сузганнар. Бу, икмәген ашый-ашый, тегеләрне күзәтә икән. Теге ике кыз түр башында ук утыра, ди, моның белән сүз куешкан кыз, башын иеп, бик күңелсез кыяфәттә идәндәге бүкәндә генә утыра, ди. Турай батыр ипиен ашап бетергәч, Ташказар әйтә:

— Йә, сиңа тиешлесен бирделәр бит инде, бар, юлыңда бул!

Турай батыр әйтте, ди, моңар:

— Тарсынма, мин китәрмен. Мондый тар күңелле кешеләр янында минем үз күңелем дә тарсына. Тик миңа бик азга гына ук-җәя биреп тормассызмы диебрәк керүем иде.

Тауказар, нишләмәкче була тагын бу хәерче дип, кызык өчен үз җәясен алырга куша. Турай батыр җәяне тартып караса, җәя чабата шикелле бөгелә дә килә.

Турай батыр Ташказар җәясен дә тартып карый, анысын да идәнгә ыргыта. Турай батыр, чөйдә үз җәясен күреп, шуны сорап алган да боларга мондый сорау биргән:

— Монда килгәндә, күл буенда биш аккош күрдем,— дигән.— Аларның икесе ата кош, өчесе ана кош. Киңәш бирегезче, шуларның аталарын атыйммы, әллә аналарынмы?

Кызлар һәммәсе дә ата кошларны атарга киңәш биргәннәр.

— Ана кошларның бала чыгарган чорлары булыр, аларга тимәскә кирәк иде,— диләр.

Тауказар белән Ташказар кызларга каршы төшкәннәр.

— Юк, юк, бетәсе булгач, барысы да бетсен. Нигә аталарын гына аерып алырга? Аларның ни гаебе бар?— диләр.

Бу сүзләрне ишеткәч, Турай батыр идән уртасына килеп баса да, җәясен тартып, угын батырларга төби.

— Гаепләре бар шул,— ди.— Аккош бервакытта да сыңар-сыңар йөрми ул. Бер ата кошны теге икесе, үлсен дип, ярты юлда чукып-чукып аерып калдыралар. Шулмы булды иптәшлек, шулмы булды егетлек?

Моны ишеткән батырлар коелып төшкәннәр. Аннан соң Турай батыр теге ике кыздан сораган:

— Бу ике аккош үләргә тиешме, әллә калырга тиешме?

Кызлар икесе бердән әйткәннәр:

— Үләргә тиешләр,— дигәннәр.

Шуннан соң Турай батыр әйтә:

— Алайса, мә, Ташказар, ал өлешеңне! Мә, Тауказар, сиңа да!..

Берәр көннән Турай батыр теге ике кызны салынып яткан ике йортка кертеп, аларга бик күп алтын-көмеш калдырып, сүз куешкан кызы белән анасы янына кайтып китә. Авылына кайтып җитү белән, туй итә башлыйлар.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әкият вакыйгаларыннан фәкать дуслар турында сөйләгәннәрен генә аерып алыгыз һәм шул вакыйгаларны гына сөйләгез.
2. Шул ук вакыйгаларны кыскартып, бик нык кыскартып, фәкать каршылыкка гына калдырып сөйләгез.

3. Дуслар турындагы вакыйгалар нәрсә турында дип сораганда, иң җиңеле: дуслар турында дип җавап бирү. Ләкин дуслар һәм дуслык турындагы әкиятләр дә, әсәрләр дә күп, аларның һәркайсы дуслыкның нинди дә булса бер сыйфатын күрсәтә. Безнең әкияттә дә шулай. Нәрсә турында дигән сорауга җавап бирегез.
4. Без инде әкиятләрнең каршылыкка корылуын беләбез. «Турай батыр» әкиятендәге каршылыкларны табыгыз.
5. Турай батыр диюне дә, элеккеге дусларын да юк итә. Ни өчен дошманына да, дусларына да бер үк җәзаны бирә?
6. Турайның әнисе турында сөйләгез. Ана эшләгән эшләрне бер сүз белән әйтеп карагыз.
7. Әкияттә төрле сыйфатларның чиктән тыш арттырылган урыннары күп. Шуларны табыгыз. Бу кадәр арттыру ни өчен кирәк?

Соңгы биремгә җавап биргәннән соң, мисалларны үзара чагыштырып, дәрәҗә арттыру, гомумән, әкият өчен хас алым икәнлеген күрәбез.

Нәтиҗә:

Сыйфат дәрәҗәсен чиктән тыш арттыруга **гипербола** диләр.

Иҗади эш

Дусларның иң күркәм сыйфатлары — тугрылык. Әйдәгез, дуслыкның шул сыйфаты турында хикәя языйк. Билгеле инде, башта күргән-белгәнне язасы килә. Илдар бәрәңге утыртышырга килде, аннары мин аларга барып ярдәм иттем. Бергәләп утын ярдык. Ул авырып киткәч, мин аның янына хастаханәгә бардым дип язудан да җиңеле юк. Ләкин хикәя күргән-белгәнне язуга гына канәгать була алмый. Уйларга куша: син бит **каршылык, метафора, кабатлау, арттыру алымнарын** беләсең, шулардан файдалан, ди.

Уйлый башлыйбыз. Без бит тугрылык турында язарга тиеш. Шуңа күрә тугрылык күренерлек берәр вакыйга уйлап табарга кирәк. Ә моның өчен гадәттән тыш вакыйга эзләргә тиеш булабыз. Мәсәлән, мин суга бата башлагач, иптәшем куркып тормады, су салкын булса да, мине кереп коткарды, дип язарга була. Хәзер тугрылык күбрәк ачылды, чөнки иптәшем суда салкын тидерергә мөмкин иде. Ни әйтсәң дә, үзен куркыныч астына куйды бит. Ләкин безне бу вакыйга да канәгатьләндерми. Баткан кешеләрне коткаручылар ту-

рында без әледән-әле ишетеп, укып торабыз. Тугрылыкны күрсәтү өчен безгә гадәттән тыш хәл кирәк. Каршылыкның бер ягында тугрылык булса, икенче ягында бәрәңге алып көч түгү, салкын суга кереп салкын тидерү кебек аз-маз югалтулар гына җитми. Димәк, безгә күп югалтулар уйлап табарга кирәк. Тугрылыкның икенче ягында кешенең иң кыйммәт нәрсәсе — гомере булырга тиеш. Тугрылыкмы — гомерме? Менә нинди каршылык ятарга тиеш безнең хикәя нигезендә.

Хәзер шундый каршылыкны эченә сыйдырган вакыйга уйлап табыйк.

Берәүне, әйтик, патша үлемгә хөкем иткән, ди. Ләкин җәза алдыннан ул әти-әнисен күрергә теләгән. Соңгы мәртәбә күреп, саубуллашып, бәхиллекләрен алыр идем, дигән.

— Өч көнгә җибәрегез, ант итеп әйтәм, кире әйләнеп кайтам, аннары башымны чабарсыз,— дигән.

Аңа, билгеле инде, берәү дә ышанмаган. Кем үләр өчен төрмәгә кире әйләнеп кайтсын, ди.

Җәзага тартылучы үзенең үлем алдыннан әти-әнисен күрергә теләвен төрмәгә килгән дустына сөйләгән. Дусты әйткән:

— Риза булсалар, мин синең урында калып торам, син кайтмасаң, мине җәзаларлар. Ләкин син сүзеңдә торырга тиеш,— дигән.

Патша риза булган. Дусларның тугрылыгын сыныйк әле, дигән. Ләкин тагын бер мәртәбә кисәткән, әгәр дә тоткын кире әйләнеп кайтмаса, вакыты җитү белән үк, аның урында калган дустының башын кистерәм, дигән. Өч көнлек вакыт биргән һәм, тоткынны җибәреп, аның урынына иптәшен ябарга кушкан.

Безгә менә шул сюжетны дәвам итәргә кирәк. Күренеп тора: ул ике юнәлештә булырга тиеш. Без өенә кайтып киткән тоткын һәм төрмәдә аның кайтуын көтеп калган дусты турында язарга тиешбез. Безнең вакыйгалар укучы өчен кызыклы булсын иде. Шуңа күрә без, гипербола алымыннан файдаланып, киеренкелекне арттырганнан-арттырырга тиешбез.

Хикәяләүне дәвам итегез: сюжетның ике сызыгы дусларны нинди эшләтә?

Башта хикәянең ахырын уйлап табабыз. Аннары гына язарга керешәбез. Языгыз. Аңа исем бирегез, персонажларның да исемнәре булырга тиештер. Йәгез әле, кайсыгыз киеренкелекне күбрәк уйлап чыгара ала?

ТУГАН ИЛГӘ МӘХӘББӘТ ХИСЕ

Хәсән Туфан

Аралагыз мине

Дөньяның мин күрдем суын, күлен,
Урманнарын, тавын, чүлләрен.
Тик күрмәдем, Идел, синең кебек
Сагындырган ягын күрмәдем.

Читләтмәде мине, кимсетмәде
Җир йөзенең һичбер имәне;
Тик берсе дә сезнең кебек итеп:
«Улым, бәгърем, бәбкәм»,— димәде.

Карагаен күрдем тайгаларның,
Усакларын күрдем Усаның;
Тик синең күк юксындырганны мин
Күрмәдем беркайда, усагым!

Ак каеннар азмы далаларда,
Япандагы олы юлларда...
Беркайда юк ләкин сезнең сыман
Сагындырган каен — беркайда!

Һәрбер гөле җирнең якын күрде,
Ят кеше син безгә, димәде;
Тик берсе дә сезнең кебек итеп:
«И абыкаем, бәгърем, браматым,
Җанкисәгем»,— дия белмәде...

Арыды бугай сезне сагынып йөрәк,
Арыды бугай газиз башкаем.
Яшел шәлең белән куләгәләп
Ял иттер бер, сеңлем ак каен.

Биремнәр

1. Шигырьне ике өлешкә бүлеп була. Бүлү өчен алымнарның берсен кулланырга кирәк. Шулай итегез: үзегез белгән алымнарның берсен кулланып, шигырьне икегә бүлегез.
2. Икегә бүлдегез, хәзер ул өлешләрне барлап чыгыгыз, анда берничә вакыйга бар. Шуларның уртак якларын табып, һәрберсенә исем бирегез.

3. Шигырьдә кабатлану бар. Ләкин аны табу җиңел түгел. Үзегез табып карагыз әле.
4. Бу шигырьдә бик матур метафора да бар. Анысын да табыгыз һәм ул өстәгән әчтәлек турында сөйләгез.
5. Туган илен сагыну дәрәҗәсенә карагагда, шигырь авторы Хәсән Туфан турында нәрсә әйтә аласыз?

Нәҗип Мадьяров

Кышкы әкият

Үткәннәрне искә алып,
Киләчәгемне уйлап,
Авылдан китеп барышым,
Карлы кыр юлы буйлап.

Каршыдан исә ачы җил,
Йөземә өрә-өрә.
Ул, ахры, китмәскә куша,
Кире борыл, ди гүя.

Юк, хәтерем калмый аның
Кисәтү ясавына.
Читкә китеп яшәдем ич,
Аңардан башка гына.

Кыш сулышы — и җилкәем,
Үпкәләвеңне оныт!
Туган як хисле җанымны
Салкының белән җылыт!

Сораулар һәм бирем

1. Шигырьдә безгә таныш нинди алымнар бар? Шуларны табыгыз.
2. «Салкының белән җылыт»,— ди шагыйрь. Салкын белән җылытып буламы? Шагыйрь җөмләсе белән нәрсә әйтергә тели?

Һади Такташ

Урман

(*Өзек*)

Урман.
Анда давыл симфониясе,
Анда үзенә башка тавышлар,
Анда кыргый кошлар,
Ач бүреләр җырлый,
Анда шаулый күлләр, камышлар...

Урман.
Бер агачтан күчеп бер агачка,
Азык эзләп очкан сандугач
Адашкандыр, бәлки,
Ул урманда,
Мескен,
Кайда кунар инде, төн булгач...

Минем көтү көтеп йөргән урман!
Сәлам сиңа сөйгән улыңнан!
Синең бөтен җирең минем хәтердә;
Сагынсам да сине,
Яратсам да сине,
Кайта алмыйм әле хәзергә.

Көтүләрдә хәзер кем кәҗәсе
Алдан чабып йөри торгандыр;
Мин партизан булып киткәч, яланында
Кемнәр көтү көтеп йөргәндер...

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьнең эчтәлеге җиңел табыла: шагыйрь шәһәрдә яши. Туган авылын сагына. Әмма кайтып күрә алмый. Шуңа күрә, бу әсәр нәрсә турында дип сорасак, «сагыну турында» дип җавап бирә алабыз. Күрергә теләп тә күрә алмау, — без инде беләбез, әсәрне икегә бүлүче каршылык. Ләкин безгә сагынуның сәбәбен дә белергә кирәк. Безне «туган авылын сагына» дигән җавап кына канәгатьләндерми. Әдип авылның нәрсәсен һәм ничек сагына?
2. Шагыйрь сандугач турында яза. Шул вакыйга әсәргә ни өсти?

Һади Такташ

* * *

— Пи-би-би-бип...—
Ди дә каз бәбкәсе,
Яхшатланып килгән, сөйләнә...
Каз бәбкәсе, белмим телеңне,
Шуңа бүлешә алмыйм сереңне...

Белсәм иде, мин дә тыңлап сине,
Аунап ятар идем чирәмдә.
Син дә, ашый-ашый, теләгәнчә
Сайрап йөрер идең тирәмдә...
Каз бәбкәсе, җаным, телең белмим,
Кем өйрәтте болай сөйләргә?
Гаҗәп матур сөйли беләсең...
Анаң уңган каздыр, күрәсең...

Их!
Авыл кырын тутырып бодай үсә,

Дулкынлатып аны җил исә.
Ташлап шагыйрьлеген җил иркенә,
Калыйм мәллә монда югыйсә...

Гайшә кызы килә казлар куып,
Артта кала аксак бәбкәсе,
Бөгелеп алган чакта бәбкәсен ул,
Чылтырап китә талир тәңкәсе...
Миңлениса чыккан, утын кисә,
Толымнарын селкеп җил исә,
Ташлап шагыйрьлеген җил иркенә,
Калыйм мәллә монда югыйсә?

Биремнәр

1. Шигырьнең каршылыгын табыгыз.
2. Шигырьдә авторның хисен һәм хисенең сәбәбен күрсәтегез.

Мирсәй Әмир

Агыйдел

(Өзек)

Ильяс дусты Гаяз белән туган авылына ялга кайта. Алар беренче төнне арбадагы печәндә йоклыйлар. Иртән уянгач, Ильяс хискә бирелеп, уйланып ята.

Без йоклаган арба төбендәге кичә генә чабып кайтарылган печән исе дә мине исертә. Хәтта шул исле чәчәкләр арасына кысылган әрем исе дә кыйммәтле хушбуйлар исеннән тәмлерәк булып тоела. Әллә ничә төрле яшел белән бизәнеп, иртәнге кояш яктысында күзләрне иркәләп күренгән урманлы таулар гына түгел, хәтта читән буйларына сырышып үскән алабуталар да, кычытканнар да Шишкин пейзажларыннан матуррак булып күренәләр.

«Әйе, дөнья матур, чиксез матур...» Шулай дип, үзалдыма үзем кычкырып җибәрә яздым.

Биремнәр һәм сораулар

1. Өч әсәрдә дә сүз лирик геройның хисе турында бара. Лирик геройның хисләренә исем бирегез. Алар күпме?
2. Безнең мисалларны да, лирик шигырьләрне яки җырларны өчкә бүлгән кебек, өчкә бүлеп буламы? Бүлеп карагыз.
3. Язучылар туган якларын ничек күз алдына китерәләр?
4. Безнең мисалларда нинди охшашлыклар бар?

Габдулла Тукай

Шүрәле

I

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл — Кырлай диләр;
Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр.
Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем,
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.
Ул авылның, — һич онытмыйм, — һәр ягы урман иде;
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
Зурмы? — дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
Халкының эчкән суы бик кечкенә — инеш кенә.
Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава,
Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.
Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.
Бик хозур! рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы-нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.
Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр[1].
Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.
Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр килеп,
киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.
Бервакыт чук-чук итеп сайрый Ходайның кошлары;
Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары[2].
Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул;
Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.
Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби;
Бинигая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.
Кылт итеп искә төшәдер намнары[3], дәүләтләре
Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен саулэтләре[4].
Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Аh! дисең, без ничек болай соң? Без дә Хакның бәндәсе...

. . . .

---

[1] *Гонҗә* — ачылып җитмәгән чәчәк.
[2] *Садаи хуш* — ягымлы тавыш.
[3] *Нам* — исем.
[4] *Саулэт* — батырлык.

III

Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар,
Юк түгел аю, бүре; төлке — җиһан корткыч та бар.
Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, поши;
Очрата аучы булып урманда күп йөргән кеше.
Бик куе булганга, монда җен-пәриләр бар, диләр;
Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр.
Һич гаҗәп юк, булса булыр,— бик калын, бик күп бит ул;
Күктә ни булмас дисең,— очсыз-кырыйсыз күк бит ул!

IV

Шул турыдан аз гына — биш-алты сүз сөйлим әле,
Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле.
Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер Җегет
Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп.
Тиз барып җиткән Җегет, эшкә тотынган баргач ук,
Кисә башлаган утынны балта берлән тук та тук!
Җәйге төннең гадәтенчә төн бераз салкын икән;
Барча кош-корт йоклаган булганга, урман тын икән.
Шундый тын, яхшы һавада безнең утынчы исә,
Алны-артны, уңны-сулны белмичә, утын кисә.
Балтасы кулда, Җегет эштән бераз туктап тора;
Тукта, чу! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.
Сискәнеп, безнең Җегет катып кала аягүрә;
Аңламастан, каршысында әллә нинди «ят» күрә.
Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Йә өрәкме, нәрсә бу?
Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!
Борны кәп-кәкре — бөгелгәндер тәмам кармак кеби;
Төз түгел куллар, аяклар да — ботак-тармак кеби.
Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,
Кот очар, күрсәң әгәр төнлә түгел — көндезләре.
Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;
Урта бармак буйлыгы бар маңгаенда мөгезе.
Кәкре түгелдер моның бармаклары — бик төз төзен,
Тик килешсез — һәрбере дә ярты аршыннан озын.

V

Бик озак торгач карашып, күзне күзгә нык терәп,
Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?»
— Бер дә шикләнмә, Җегет, син; мин карак-угъры түгел;
Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугъры түгел.

Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм;
Мин әле күргәч сине шатланганымнан үкерәм.
Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым;
Булгалыйдыр көлдереп адәм үтергән чакларым.
Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и
Яшь Җегет! Килче, икәү уйныйк бераз кети-кети.
— Яхшы, яхшы, сүз дә юктыр, мин карышмый уйныймын,
Тик сине шартымга күнмәссең диеп мин уйлыймын.
— Нәрсә шартың, сөйлә, и бичара адәмчеккенәм?
Тик тизүк уйныйкчы, зинһар, нәрсә кушсаң да күнәм.
— Сөйлием шартымны сиңа, яхшы тыңлап тор: әнә
Шунда бар ич бик озын һәм бик юан бер бүрәнә.
Мин дә көч-ярдәм бирермен, — әйдә, иптәш, кузгалыйк,
Шул агачны бергә-бергә ошбу арбага салыйк.
Бүрәнәнең бер очында бар әчелгән ярыгы,
Шул җиреннән нык кына син тот, и урман сарыгы!
Бу киңәшкә Шүрәле дә күнде, килмичә кире,
Китте кушкан җиргә, атлап адымын ире-ире;
Куйды илтеп аузын әчкән бүрәнәгә бармагын, —
Кариәм[1], күрдеңме инде яшь Җегетнең кармагын!
Суккалыйдыр балта берлән кыстырылган чөйгә бу,
Хәйләсене әкрен-әкрен китерәдер көйгә бу.
Шүрәле тыккан кулын — селкенмидер, кузгалмыйдыр;
Белми инсан[2] хәйләсен — һич балтага күз салмыйдыр.
Суккалый торгач, ахырда чөй чыгып, бушап китеп,
Шүрәленең бармагы калды кысылды шап итеп.
Сизде эшне Шүрәле дә: кычкыра да бакыра,
Сызлана һәм ярдәменә шүрәлеләр чакыра.
Хәзер инде Шүрәле безнең Җегеткә ялына,
Тәүбә итә эшләреннән, изгелеккә салына:
— Син бераз кызган мине, коткарчы, и адәм генәм;
Мондин ары үзеңә, угълыңа, нәслеңгә тимәм.
Башкалардан да тидертмәм, ул минем дустым, диеп,
Аңгар урманда йөрергә мин үзем куштым, диеп.
Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр;
Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар сиңа, ни бар?
Тибрәнә дә йолкына, бичара гакълыннан шаша;

---

[1] *Кариәм* — укучым.
[2] *Инсан* — кеше.

Шул арада яшь Җегет өйгә китәргә маташа.
Ат башыннан тоткан ул, бу Шүрәлене белми дә;
Ул моның фөрьядларын[1] асла[2] колакка элми дә.
— И Җегет, һич юк икәндер мәрхәмәт хиссең синең;
Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! кем син? исмең кем синең?
Иртәгә килгәнче дустлар тәндә җаным торса гәр,
Шул фәлән атлы кеше кысты диермен, сорсалар.
— Әйтсәм әйтим, син белеп кал: чын атым Былтыр минем.
Бу Җегет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем!
Шүрәле фөрьяд итәдер; аудан ычкынмак була,
Һәм дә ычкынгач, Җегеткә бер-бер эш кылмак була.
Кычкыра: «Кысты, харап итте явыз Былтыр мине,
Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?»
Иртәгесен шүрәлеләр бу фәкыйрьне тиргиләр:
— Син җүләрсең, син котырган, син тилергәнсең,— диләр.
Әйтәләр: «Кычкырма син, тиз яхшылык берлән тыел!
И җүләр! Кысканга былтыр, кычкыраламы быел!»

Сораулар һәм биремнәр

1. Әкиятне берничә өлешкә бүлегез. Һәр өлешкә, нәрсә турында булуына карап, исем бирегез.

«Бу әсәр нәрсә турында?» дигән сорауны башкача «әсәрнең темасын әйтегез» дип үзгәртәләр.

Әсәрне сөйләгәндә, кыскарта-кыскарта, бик кечкенә вакыйгага калдырырга мөмкин. Бер җөмләгә генә калдырып кыскартырга да була.

Бу әсәр фәлән турында дип, бер сүз белән дә әйтергә мөмкин. Әсәрнең бик нык кыскартылган, ягъни бик нык гомумиләштерелгән эчтәлегенә **тема** диләр.

Менә хәзер сорауны бүтәнчә итеп бирик: һәр өлешнең темасын әйтегез.

2. Әйдәгез, башта әкияттәге каршылыкны табыйк. Игътибар итегез, Габдулла Тукайның авылы башка авыллардан бер генә ягы белән дә аерылып тормый. Гап-гади, хәтта адәм рәтле суы да булмаган авыл. Менә шул кечкенә, гап-гади авылны шагыйрь бик матур итеп сурәтли. Моның өчен ул, билгеле, гипербола алымы куллана. Әкияттә Габдулла Тукай арттырган урыннарны табыгыз.

3. Габдулла Тукай: «Кырлай авылында хәтта тавыклар да җырлый»,— ди. Ни өчен шулай ди? Ул безне, чыннан да, монда тавыклар

---

[1] *Фөрьяд* — зарланып елау.
[2] *Асла* — һич тә.

«Әллүки» көенә җырлыйлар дип ышандырырга тырышмыйдыр бит! Әллә тырышамы? Нигә шулай дип яза?

4. Әйдәгез, хәзер әкиятне өлешләргә бүлик. Башта шагыйрь авыл матурлыгы турында яза. Бу өлешкә шулай дип, ягъни «Авыл матурлыгы» дип исем бирик тә. Ә калган өлешләргә нинди исем бирәбез? Исемнәр биргәндә, кабатланган сүзләр кулланудан курыкмагыз. Мәсәлән: «Авыл матурлыгы», «Урман матурлыгы» дип ике өлешне дә матурлык сүзе белән атыйсыз икән — калсын. Гомумиләштергәндә, бу өлешләр икесе дә матурлык турында дип, өлешләрне кушарга уңай булыр. Әкияттә тагын «матурлык» дип атарлык вакыйга бар. Шуны табыгыз һәм башта сюжетын, аннары матурлыгын сөйләгез.

5. Әкияттәге өлешләрнең матурлык турында булганнарын бер өлеш дип саныйк, чөнки алар барысы да матурлык турында. Хәзер менә ямьсезлек турындагы урынны табыгыз. Ул урынны әкиятнең икенче өлеше дип әйтә алабыз. Шул урынны кычкырып укыгыз һәм темасын әйтегез.

6. Әкияттәге матурлык белән ямьсезлек,— билгеле, әсәрдәге төп каршылык. Әмма анда әле ваграк каршылыклар да тулып ята. Мәсәлән, «Былтыр кысты» сүзләрендә каршылык бар. Ул ничек ясалган?

Без әдәби әсәрләрнең эчтәлеген — хисләрне өйрәндек. Хисләрнең сыйфатларын да, төрләрен дә белдек. Әдәби әсәр эчтәлеге булган хисләрне әсәрнең үзен анализлау нәтиҗәсендә генә өйрәнеп булуына да ышандык. Хәзер үзебез белгәннәргә таянып нәтиҗә ясыйк.

Безгә таныш таякны искә төшерик. Беренче дәрестә таякның озынлыгына, яхшылыгына бәя бирү юлларын өйрәнгән идек. Алдагы дәресләрдә башка якларына тукталып тормадык. Ә бит әлеге таякның башка яклары да бар. Мәсәлән, таяк ике башлы. Агачтан. Яна, суда батмый, каты, аны юнып була, шомартып була һ. б. Бу якларны искә төшергәч, мондый сорау куя алабыз: таяк нәрсә ул? Болай дип җавап бирик: таяк — югарыда санап чыккан сыйфатларның җыелмасы. Шул сыйфатлар үзара мөнәсәбәткә кереп, таякны таяк итәләр. Бу сыйфатларның әле берсе, әле икенчесе безгә әһәмиятле була. Ихтыяҗ чыкканда нинди дә булса сыйфатларның безнең өчен аеруча әһәмият алуын әйбернең мәгънәсе дигән идек. Таягын таяк, ә менә кеше нәрсә ул? Бу сорауга да җавап бирик.

Кешенең сыйфатлары аеруча күп. Кеше уйлый, йөри, йоклый, сөйләшә, тәртипле йә тәртипсез була. Көнче була, ярата ала, нәфрәтләнә ала, көчле була ала, көчсез була ала. Гармун уйный ала, йөк күтәрә ала... Башка сыйфатларын үзегез әйтеп карагыз.

Ләкин кешене кеше итә торган, мәгънәле итә торган аеруча мөһим сыйфатлар җыелмасы бар. Алдагы дәресләрдә без шул сыйфатларның бер өлешен өйрәндек. Җир йөзендә яшәгән халыкларның барысы да кешеләрнең иң күркәм сыйфатлары итеп ата-ананңы, туган җиреңне ярата белү, дусларга тугрылыклы булу сыйфатларын исәплиләр. Ата-анага мәхәббәт, туган илне ярату хисе — даими хисләр. Алар кешеләрне һәрвакыт дулкынландырып, шатландырып, борчып торалар.

Татар халкы борынгы заманнардан бирле бу хисләрне изге хисләр дип, буыннан-буынга күчереп, саклап, тәрбияләп килә. Матур әдәбият шундый изге хисләрне саклап, үстереп, башкалар тәҗрибәсендә кешеләрне тәрбияли. Шундый хисләргә ия булмаган, башкаларны яратмаган кешеләргә халык «мәгънәсез» ди, «мәнсез» ди. Мондый кешеләрне бервакытта да хөрмәт итмәгәннәр.

Ата-анага, туганнарга мәхәббәт, туган җирне ярату, дуслык хисе кешене баета, бәхетле итә. Шундый риясыз ярату хисе кешедә гаять дәрәҗәдә әһәмиятле ике күркәм сыйфат — **игелеклелек** **һәм** **гаделлек** сыйфатлары тәрбияли. Кешене кеше итә торган сыйфатлар арасында бу ике сыйфат аеруча дәрәҗәле урын алып тора. Кешенең игелеклелек һәм гаделлек сыйфатларына **әхлак** сыйфатлары диләр. Игелекле һәм гадел кешеләрне **намуслы, тәрбияле, культуралы** кеше диләр.

Әхлакның бу мөһим сыйфатлары матур әдәбият эчтәлегендә аеруча зур урын алып тора. Әсәр эчтәлегенең бу өлешен өйрәнү өчен дә без барыбер әсәргә анализ ясарга тиеш булабыз. Игелек белән гаделлек сыйфатлары һәрвакыт төрле-төрле хис белән төрелгән була.

Шуның өчен, әсәрне анализлаганда, без андагы хисләрне дә өйрәнергә тиеш булабыз.

КЕШЕЛӘРДӘГЕ ИГЕЛЕКЛЕЛЕК ҺӘМ ГАДЕЛЛЕК КЕБЕК ӘХЛАК СЫЙФАТЛАРЫН ӨЙРӘНҮ

Игелекле, шәфкатьле, гадел, сүзендә торучы, әдәпле кешеләргә әхлаклы кеше диләр. Әхлак, — димәк, бик күп гүзәл сыйфатларны гомумиләштергән сүз.

Бу сыйфатларны безнең борынгы бабаларыбыз да иң күркәм сыйфатлар дип бәяләгәннәр. Әхлаклы кешеләрне хөрмәт иткәннәр. Андый кешеләргә кинәшкә килгәннәр, балаларын да шуңа охшатырга тырышканнар. Аларны

Карама беләгенә, кара йөрәгенә;
Каты йөрәк бер яшәр, изге йөрәк мең яшәр;
Кулың пакь булса, йөзең ак;
Яхшы барган — юл алган, яман барган — югалган,—

кебек мәкальләр әйтеп тәрбияләгәннәр.

Үзендә булганны башкалар белән бүлешә торган кешеләргә игелекле кеше дип әйткәннәр. Шәфкатьле кеше дип башкаларның хәленә керә белүче, нечкә күңелле, киң күңелле, рәхимле, изге кешеләргә әйткәннәр. Дөреслекне яклаучыларга гадел кеше дигәннәр.

Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын, ди халык. Ләкин йөз дустың булу өчен, синең үзеңне башкалар дуслашырга лаеклы кеше дип бәяләргә тиешләр. Бу мәкаль дә кешеләрне әхлаклы булырга чакыра. Шуңа күрә:

Яхшы белән юлдаш булсаң, эшең бетәр,
Яман белән юлдаш булсаң, башың бетәр,—

дигәннәр.

Һәркем әхлаклы булса гына кешеләр дә тату яши, ил дә тыныч була. Шуңа күрә һәркемне әхлаклы итү — бөтен җәмгыятьнең төп бурычы. Матур әдәбиятның төп максаты да шуннан гыйбарәт. Әмма без аеруча белергә тиешлесе: һәркем үзе өчен үзе җаваплы, кеше үзен әхлаклы итеп бары тик үзе генә тәрбияли ала. Ә моның өчен һәркем үзенә башка кеше булып бәя бирә. Үзе үк ялгыш эшләрен күреп ала һәм башка аны кабатламаска үзенә үзе сүз бирә.

Үзенең вак-төяк теләкләрен җиңә, үзенә тәнкыйть белән карый белгән кешеләргә көчле кешеләр диләр.

Зыя Мансур

Кырмыска

Бер кырмыска, арып-талып,
Эштән кайтып килә икән.
Нәкъ шулвакыт, җил кузгалып,
Бу мескенең суга төшкән.

Чыга алмас иде, бәлки,
Күпме генә тырышса да.
Бер акыллы малай күреп,
Чыбык сузган кырмыскага.

Уен ич бу! Малай әллә
Җан-фәрманга тырышканмы?
Юк, дусларым, ә шулай да
Коткарган ул кырмысканы...

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьнең эчтәлеген ничек белергә? Моның өчен эшне башта аның темасын табудан башларга мөмкин. Ә теманы без сюжетны кыскарта-кыскарта табарга өйрәндек.
Кыскартып сөйли-сөйли шигырьнең темасын табып карагыз әле. Табыламы?
2. Табып булмаса, әсәрне өлешләргә бүләргә кирәк. Моның өчен аның нинди алым белән төзелүен табыйк. Алым шигырьне хәзер ике якка аерып ташлый. Шигырь нинди алым белән язылган?
3. Өлешләрне аерыгыз да аларның бәйләнешен табарга тырышыгыз. Менә шунда эчтәлек табыла да инде.

Нәҗип Мадьяров

Әби күзлеген эзли

Кайда икәнен белми,
Әби күзлеген эзли.
Күзлеге бит кулында,
Әмма ул аны сизми.

— Әби, әби,— дим аңа,
Каршысына ук килеп.—
Җайлы булыр эзләргә,
Күзлегеңне ки элек.

Әби күзлеген кия,
Үзе елмаеп көлә.
— Рәхмәт, табып бирдең,— ди,
Аркамнан сөя-сөя.

Бирем

«Кырмыска» шигыренә ясаган кебек анализ ясагыз.

«АЛМАЧУАР»
ХИКӘЯСЕН УКЫР АЛДЫННАН

Әдәби әсәрнең эчтәлеге менә мин дип кычкырып тормый. Аны әле эзләп табасы бар.

Фикерне ачыклау өчен, әйдәгез әле, бер бик мәшһүр, бик батыр язучы һәм очучының «Нәни принц» исемле әкиятен искә төшерик.

Әкиятен ул болай башлый: «Мин джунглидагы тормышның гаҗәеп күп маҗаралары турында уйландым-уйландым да төсле каләм белән үземнең беренче рәсемемне ясадым.



Менә нәрсә эмәллэп куйдым: «Мин үземнең иҗат җимешен өлкән кешеләргә күрсәттем, һәм сезне бу рәсем куркытамы?»,— дип сорадым.

— Эшләпә куркыныч була димени?— диделәр алар.

Ә минем эшләпә ясаганым да юк. Мин җәнлекләрне тере килеш йота торган буар елан ясаган идем. Эшләпә дигәннәре фил йоткан елан иде. Шуннан соң мин еланны, олыларга аңлаешлырак булсын өчен, эче күренерлек итеп ясадым. Менә ул рәсем.

Бу — әкиятнең башы гына. Калган өлеше белән сез әле танышырсыз. Чөнки ул иң кызыклы әкиятләрнең берсе — Сент-Экзюпери абыегызның «Нәни принц» әкияте.

Ә без кабат әлеге рәсемнәргә әйләнеп кайтыйк. Матур әдәбият әсәре дә, эшләпәгә охшаган елан кебек, ике, хәтта өч катлы итеп төзелә. Бер кат укып карыйсың — эшләпә! Тагын укыйсың — тагын эшләпә! Әсәр төзелешенең алымнарын белгәч кенә, эшләпәнең елан икәнлеген һәм аның эчендә теп-тере фил утыруын белеп алабыз.

«Алмачуар» хикәясен беренче кат укып чыкканда уйлап та бирмисез:

— Бу бит Закир исемле малайның атка гашыйк булуы турында!— дип кычкыруыгызны сизми дә каласыз.

Олыларга әйтеп карыйсыз... Ә олылар ни диләр? Алар да бу хикәя атка мәхәббәт турында диярләрме?

Олылардан сораганчы, әйдәгез әле, хикәянең нәрсә турында булуын үзебез белеп карыйк.

Иң әлек сез Закир әтисенә башкорт баеның ат бүләк итү вакыйгасы белән танышасыз. Бу вакыйга башта ук тәмамлана. Шуңа күрә без аны аерым бер өлешкә саный алабыз. Аннары: туктале, бу вакыйга үзе шундый зур метафора була алмыймы дип, үзебезгә үзебез сорау бирәбез. Димәк, мин, бу метафора-вакыйганы бик нык өйрәнсәм, төп вакыйга эчтәлеген ачу өчен ачкыч таба алачакмын дигән уй, билгеле, шунда ук һәммәбезнең башына килә. Шуңа күрә метафора-вакыйганы бик нык өйрәнергә тиеш булабыз. Башта, мәгълүм инде, аның темасын табабыз.

Әйдәгез, хикәяне укыган чакта ук аның өлешләрен, вакыйгаларның охшаш якларын чамалыйк.

Галимҗан Ибраһимов

Алмачуар

(*Бер мәхәббәтнең тарихы*)

I

Миңа, күп куйганда, җиде-сигез яшь булгандыр, әллә нинди коточкыч кара йөзле, усал елтыр күзле бер башкорт һич көтелмәгән җирдән үзенең кара бурлы, матур, зур симез биясен безгә бүләк итте, алай-болай гына түгел, үз кулы белән йортыбызга китерә, капка төбендәге зур ташка утыра да кешеләр алдында дога кылдырып бирә.

Авыл халкы бу эшкә башта аптырап калалар: ни сәбәптән бу — тирә-якка усаллыгы, саранлыгы белән даны чыккан явыз көрәшче Әлемгол — тик торганда үзенең гомерлек дошманы Хафизга (безнең әткәйгә), бер бия китереп, фатиха кылдыра?!

Эштән чыккан бер мал булса, тагын бер хәл иде! Биясе нәрсә бит: бөтен тирә-якта дан тоткан ике алмачуар чабышкының анасы! Җитмәсә тагы, карынында бер колын бар! Мондый бер хәл һичкемнең башына сыя алмый...

Безнең кардәш Сафа карт та, ак сакалын сыйпап:

— Китапча итеп әйтсәң инде, ди, мин әйтәм, ди, таштан су чыгар, усак агачы алма бирер, ди, Әбүҗәһел иманга килер. Әмма, ди, Әлемгол бай, ди, бу данлыклы бияне карынындагы колыны белән тиктән тик Хафизга

китереп бирмәс, монда берәр этлек юкмы икән, балалар,— ди.

Башкорт боларның һәммәсен тыныч кына тыңлап тора да, бераз елмаеп, кара күзләрен тагы да ныграк елтыратып, үзенең хәлен сөйләп бирә.

II

Безнең әткәй Мөхәммәтхафиз исемле булса кирәк. Буйга зурлыгы өчен аны Озын Хафиз дип йөртәләр.

Ул яшь чакта имән кебек таза, лачын кебек үткен, арыслан кебек гайрәтле булган, дип сөйлиләр. Тирә-якта, кирәксә сугышка булсын, теләсә көрәшкә булсын, аңа тиңдәш, охшаш чыкмаган. Иң зур Сабантуйларында да ул әллә кайлардан килгән данлыклы көрәшчеләрне шаяртып кына чөеп ташлый торган булган...

Менә бервакыт Чишмәдә зур Сабан туе ясала. Асыл сөяк чабышкы атлар, үз тирәсендә исем казанган көрәшчеләр, шәп йөгерүче җегетләр бу җыенга йөзәр чакрымнан киләләр — көч сынамакчылар, үзләрен күрсәтмәкче, дан алмакчылар.

Көрәш башлана. Ни күрәсең? Хафизга кем чыдасын!

Безнең әткәй чыккан бер баһадирны аз-маз шаярта да чөеп үк ташлый.

Ахырдан килеп чыгаябык, чандыр бер кара башкорт.

Ике баһадир, билләрен берәр тартып сыныйлар да, берберсенең сыртларына кулларын салган хәлдә, бөтен халыкның күзе астында, түгәрәк мәйданда әйләнәләр.

Йа Ходай! Бу ни эш?!

Кинәт данлыклы Хафиз тәгәрәп-тәгәрәп китә дә чалкан барып төшә!

Мәйдан гөж килә. Әткәйнең дуслары бу хурлыкка чыдый алмыйлар:

— Башкорт хәрәмләде, аяк чалды!— дип, шау-шу күтәрәләр, яңадан көрәшергә чыгуны сорыйлар.

Ике як та риза була. Баһадирлар тагы түгәрәк мәйданда. Бөтен халык тагын, тыннарын да алмыйча, бу зур көрәшкә карап катканнар!

Ал аякларын бер-берсенең сыртларына салган арыслан белән юлбарыс кебек, ике ир каһарман ярты сәгать буенча, бер-берсенең билләреннән алган хәлдә, мәйданны урап йөриләр.

Тагы кинәттән, һич көтмәгән бер секундта, башкорт каһарман сиздермәстән генә кысып ала да үзе җиргә ята, баш очыннан Хафиз баһадирны шундый көч белән селтәп җибәрә ки, ул, әллә кая барып, сул кулы өстенә бик каты егыла.

Халык шау-шу килә. Мәйдан кайный!.. Сабан туе элеккечә шаулап калды, әткәй кызыл башлы сөлгеләр белән яшел чапанны бер як кулбашына салды да, икенче кулын кызыл билбау белән муенына асып, акрын гына кайтып китте...

Ахрысы, бик гарьләнгәндер:

— Җитәр инде: заманында көрәштек, бусы актыгы булыр!— диде.

Һәм сүзендә торды: шуннан соң Сабантуйларына аяк атламады...

III

— <...> Шулаймы? Сез татарлар да боларны беләсезме? Әмма менә җиңүче башкортның йөрәгендә аннан соң ниләр булганы сезнең төшегезгә дә кермәгәндер, ди, Хафиз агакай, ди, мин сине екканда хәйлә ясадым... Үзеңә дә, карап торучыларга да сиздермәстән, уң аягыңны бераз чалдым... Бу вакыт күңелемә шик килде. Шулай да үземне тыя алмадым, — ни булса, шул булыр, бәлки, бер юлга Ходай кичерер дидем дә сине шул хәрәмләвем аркасында баш аша чөйдем... Күңел — әүлия, диләр бит, дөрес сүз икән: Сабан туеннан кайтып та җиттем, түшәккә дә егылдым: эчем бора, сул кабыргам астында нәрсәдер тырный, чәнчә башлый. Шуның белән өч ай акырып ятам, ашаганым — аш, эчкәнем су булмый... Шул каты хәстә чагымда: «Бу авыру Хафизга каршы хәйлә эшләп, аны рәнҗетүдән килгәндер, терелсәм, бурлы биямне аңа дога кылдырырмын»,— дип нәзер әйткән идем. Терелдем. Нәфес — шайтан бит: «Әй, ул татарның рәнҗеше төшәме соң»,— дип уйладым. Бияне бирергә кызгандым. Берничә ел үткәч, тагы шул хәстә: эчем бора, сул кабыргам астында нидер тырный, нидер чәнчә... Һич түзәр хәлем калмады, бөтенләй авырыйм... «Терелсәм, бер көн кичекми илтеп бирәм»,—дип, тагы нәзер әйтәм. Күрәсез, мин терелдем. Менә нәзеремне үтим.

Картлар бөтенләй хәйран калдылар. Сафа бабай башкортның аркасыннан кага:

— Китапка язган кебек сөйлисең: этлеккә генә түгел, яхшы сүзгә дә синең акылың, телең җитә икән,— ди.

Башкалар да рәхмәт укыйлар, яңадан чүгәләп дога кылалар.

— Хафизның бик авыр еллары иде. Улы белән кызыннан да аерылган чагы иде. Бурлы бия җиңел аягы белән килгән булсын! Бу йортка бәрәкәт китерсен!— диләр.

IV

Картлар сүзе дөрес: безнең йортның, чынлап та, авыр еллары иде. Әткәй кебек зур, таза баһадир, сылу абзамны нахак бәлагә эләктерделәр. Авылыбызда бик череп беткән бер кара бай бар иде. Акчасы күп, имеш; күкрәкчә ясап, янында йөртә, имеш, дип сөйлиләр аның хакында. Ул бай белән безнең әти арасында, ниндидер бер җир талашы сәбәбеннән, әллә кайчаннан бирле дошманлык бара иде. Кыш көне шул кара черегән байны, каядыр китеп барган чагында, урманга алып кергәннәр дә, авылдан бер чакрым җирдә, көпә-көндез суйганнар. Гөнаһ шомлыкка каршы, шунда ук бетерә алмаганнар. Өенә кайткач, үләр алдыннан, әзрәк һушына килеп, бөтенләй нахактан: «Башкаларын танымадым... Берсе Озын Хафизның улы Шәяхмәт иде...»— дигән.

Абзыйны шул сәгатьтә үк богаулап алып киттеләр. Хөкем була.

Әткәй, бу нахак бәладән коткарыйм дип, көн чаба, төн чаба. Бөтен авылда мәлгуньнең дошманлыктан гына әйткәнен беләләр. Әткәй, коткарам дип йөри торгач, актык атыннан, сыерыннан яза, абзыйны егерме елга каторгага хөкем итәләр... Без бөтенләй фәкыйрьлектә калабыз...

Шул кайгы җитмәгән кебек, бердәнбер абыстай да түбән очның гармунчы Фәхригә ябышып чыга...

Картларның «авыр ел» дигәне менә шулар иде.

Аларның догасы кабул булды. Башкорт биясе безнең йортка җиңел аягы белән килде, һәм үзе белән безнең йортка бәрәкәт тә китерде: әткәй бу — моңарчы муены камыт күрмәгән симез бияне ике көн эчендә җигәргә өйрәтте дә дөнья җимереп эшләргә тотынды. Һәм шундый бәрәкәт булды инде: көз көне безнең әткәй шул кәсептән, йөрүдән, игеннән җыелган акчага икенче ат та алды. Башкача да йорт-җирне байтак төзәтте...

V

...Бурлы бия буаз. Без хәзер аны җикмибез...

Әнкәй моның өчен һаман сукрана:

— Ике атың бар өстеннән, нәрсә шул хәерче кебек лыртлырт белән йөрисең? — ди.

Эткәй аны бер сүз белән туктата:

— Йә, куй сукрануыңны, ди, нигә, ди, баланы юкка елатырга,— ди. «Бала» дигәне мин булам.

Чыннан да, берәр авыр йөккә, ерак җиргә җигә башласалар, мин эткәйгә барып сыенам, иркәләнәм: ул минем... күз яшьләремне күрә дә, мыек астыннан көлеп, башымны сыйпый:

— Йә, син, Закир, юкка елап барма... Ярар, җикмәбез,— ди.

Мин шатлыгымнан кая сикерергә урын тапмыйм...

Сафа бабай әйтә, озакламас, колыннар инде, ди. Күз-колак булып торырга кирәк, ди...

Тавык ояларыннан йомырка урладым. Яшереп куйган ширпы алдым да, шуларга алдап, малайларны үзем белән елга буена, болынга, бия каравылларга алып китәргә әзерләнә башладым...

Кармакларны, селәүчәннәр, икмәкләр, йомыркалар, шырпыларны алабыз да, кыйбла якка, якты кояшка карап, болын буйлап Өзән елгага чабабыз <...>

VII

Безнең бия йөргән җиргә якын гына зур яту бар. Монда өч яктан өч елга килеп кушыла. Болар кушылалар да, ул җиргә чаклы кечкенә бер «кул» гына булып агып яткан Өзән елганы берьюлы зурайтып җибәрәләр. Боларның суларын үз эченә алгач, безнең Өзән елга киңәеп, тулып китә: әллә ничек олы сыман булып, мәһабәт булып ага башлый...

Беләсе иде, кайдан чыга, кайларга бара икән бу сулар!

Беләм, бик беләм: таулар, болыннар буйлап килеп, безнең авылның буеннан аккан бу елга Өршәккә, Өршәк Димгә, Дим Агыйделгә коя. Агыйдел кая барадыр — анысын бер Алла белә.

Тик бик күп дөнья гизгән Сафа бабай гына кайвакыт сөйләп куя: көз көне кошлар китә торган якта, ди, Әчтерхан дигән бер зур шәһәр — борынгы ханнар шәһәре бар, ди, шуның аръягында, ди, гаҗәп зур бер диңгез бар, ди. Агыйдел, ди, бик күп авыллар, шәһәрләр, таулар, кара урманнар эченнән агып, айлар, еллар буенча бара-бара да, ди, әнә шул олуг диңгезгә барып коя, ди; сез моннан бер йомычка салып җибәрсәгез, ди, ул, ди, Өршәкләр, Димнәр, Агыйделләр буйлап

агар-агар да әнә шул ерак диңгезгә барып төшәр, ди... Их, күрәсе иде ул диңгезләрне!

Мин әллә нинди уйлар белән бурлы бия тирәсендә аңардан күземне ала алмый уралып йөргәндә, тегендә, яр башында балык каптырып йөргән малайлар миңа кычкыра башладылар:

— Закир, Закир, шырпы белән йомыркаларны китер, тизрәк ягабыз да көлдә пешерәбез,— диләр.

Кармакларны ташладылар; уйнап, шаярып, көрәшеп, янган ут тирәсендә йомыркалар пешүен саклыйлар.

Безнең яннан гына Өзән елга һаман ага да ага... Минем хәтеремә бабайның сүзе килде.

— Беләсеңме, Апуш,— дим.— Бу елга кая коя?— дим.

Ул бик усал нәрсә:

— Бер йомырка артык бирсәң, барын да сөйләп бирәм,— ди.

— Ярый,— дим,— бирермен.

— Өзән елганы күрәсеңме?— ди. Күрсәң карап тор, ди.— Бу елга, ди, унике чакрым киткәч, Өршәккә төшә, Өршәк Димгә кушыла, ди. Дим матур болыннар арасыннан бара-бара да Өфе дигән зур кала янында, әллә нинди биек таулар каршында Агыйделгә барып чыга,— ди.

Кемдер аның сүзен бүлә:

— Агыйдел кая бара?

— Агыйделме?— ди. Агыйдел, ди, урманнар, таулар, калалар арасыннан бара-бара да Әчтерхан диңгезенә төшә,— ди.

Малайлар кычкырыша башлыйлар.

— Егет син, Апуш, ал бер йомыркаңны,— диләр...

Аяк астында бер зур йомычка ята иде, шуны алдым да, малайларга күрсәтеп:

— Әйтегез,— мин әйтәм,— Өзән елгага салып җибәрсәм, менә бу нәрсә кыйбла ягындагы ерак диңгезгә барып төшәрме, юкмы? — дим, йомычканы ярдан ярга тулып аккан Өзән елганың киң күкрәгенә ташлыйм. Дулкыннар аны кочаклап алалар да, ашыктырып-ашыктырып, үзләре белән түбән таба алып китәләр.

Малайлар талашырга тотына.

Апуш:

— Тукталмас та, батмас та, диңгезгә барып төшәр,— ди.

Башкалары:

— Барып җитә алмас, су белән авыраеп батар янәсе, читкә чыгып, камыш арасында туктар,— диләр.

Инде төш тә ауды... Кайтырга чыктык. Малайлар: «Килү бушка китмәде»,— диештеләр. Унар-унбишәр балык алганнар...

Мин, күздән югалганчы, биягә борылып карый-карый бардым. Ул һаман шул хәлендә: ашамый, урыныннан кузгалмый, башын бераз аскарак салган да тик кенә тора. Ниләр уйлый икән минем бурлы биям?

VIII

Өйдә табак тутырып бәрәңге пешергәннәр. Мин эттән яман ачыкканмын икән. Күземә ак-кара күренмәде, каз йомыркасы зурлыгындагы бәрәңгеләрне, тозлап-тозлап, арыш икмәге белән бөгәргә тотындым.

Үзем, авыз тулы көенчә, бурлы бия турында туктамый һаман сөйлим.

Әнкәй бер көлә, бер ачулана:

— Сиңа, ахры, ат җене кагылгандыр, торсаң — шул, ятсаң — шул, бар белгәнең шул булды,— ди.

Мин, аның белән карулашырга уйлап, авызымны гына ачкан идем, түбән оч Фәхринең зур улы Сәпәр урам як тәрәзәдән баш тыкты да ут чыккан кебек акырып җибәрде:

— Закир! Закир! Сөенче! Бурлы бияң колынлады,— ди.

Ни эшләгәнемне белмәдем, әни, аптырап:

— Ай, бу бала харап була инде шул мал өчен!— дип кычкырып калды, мин, ашъяулыклар, табаклы бәрәңгеләр өстеннән атылып, йортка чаптым.

Әткәй бакча буенда арба төзәтеп маташа иде. Туры аңа ташландым.

— Әткәй, әткәй, әйдә тизрәк, бия колынлаган,— дип акырам.

Гаҗәп яратам мин әткәйне! Ул әз генә дә ачуланмады, минем сүзне ишетү белән, урыныннан торды да коймага эленгән нуктаны алды:

— Кем әйтте, сөенче бирдеңме? <...>

X

Тик өйгә алып кайтып, бияне кое баганасына бәйләп куйгач кына, мин үз-үземә исәп бирә алырлык булдым.

Колын, чыннан да, гаҗәеп бернәрсә иде: аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар. Бәкәлләре озын, шундый нечкә-озын ки, мондыйлар тик чабышкы атларда гына була, диләр...

Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын яра кашка — бу колынны мең миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз итеп күрсәтәләр. Шундый... сылу, шундый асыл сөяк булып яратылганнар.

Кайдандыр ишетеп, безнең Сафа бабай да ак сакалын җилбердәтеп килеп керде. Ул — бөтен тирә-якка ат тану белән дан тоткан кеше.

Колынны күрүгә, бабайның йөзе ачылды:

— Сөбханалла... Сөбханалла... Күз тимәсен... Бу колын да үзенең элекке ике агасына охшаган икән,— диде...

Тагы бераз читкәрәк китеп карады да әткәйгә:

— Беләсеңме, Хафиз, бу нәкъ агалары кебек булыр, төсе дә тиз арада алмачуарга әйләнер... Хәерле булсын, хәсрәтең зур иде, ике өлкән балаң хафасы сине бик картайткан иде, бурлы бия бу йортка җиңел аяк белән килде, бәрәкәт китерде,— диде.

Ике өлкән баласын хәтергә төшерү һәрвакыт безнең әткәйнең йөрәгенә авыр була...

— Сөйләмә инде, Сафа абзый, ул, ике балам адәм түгел, лачыннар, арысланнар иде, үзләре дә бәхетсез булды, минем дә вакытсыз чәчләремне агарттылар...— диде. Бераз туктап торып:

— Язганы шулдыр инде... Менә бар өмет бу кечкенәсендә,— дип куйды.

XI

Шул көннән алып Алмачуар минем тормышымның үзәге була. Шатлыкларым, кайгыларым шуннан чыга, шуңа кайталар. Төшемдә шуны күреп саташам. Иртән торуга, киенмәстән, битемне юмастан, мин абзарга, Алмачуарны карарга, аның исәнлеген белергә йөгерәм. Исән, бик исән!

Ул, әкияттәге баһадир кебек, ай үсәсен көн үсә, үзе көннән-көн матурлана, асыллана бара...

XII

Җәй, аның артыннан көз үтеп китә. Әллә нинди карлы, яңгырлы, болытлы чаклар килә. Мин иртәгә «Покрау» бәйрәме дигән көндә, ничектер, иртәрәк уяндым, шулай да торырга иренеп ятам.

Әткәй белән әнкәй чаршау артында пыш-пыш сөйләшәләр. Тавышларында әллә ни бар: куркалармы, кайгыралармы, нәрсәнедер, кемнәндер яшерергә телиләрме? Бернәрсә белмим.

— Син аңа белдермәскә тырыш! Ишетмәсең!— диде дә эткәй, кулындагы арканын җилкәсенә салып, тиз генә чыгып китте...

Әни мич алдында, чыж-пыж итеп, нидер кыздыра калды, мин аннан-моннан киендем дә урамга чыктым.

Каршыма Апуш килә:

— Их, малай, бәхетең бар икән... Исән калган бит,— ди. Мин шашып киттем:

— Ни бар?.. Ни булган? Кем исән? Апушның күзләре дүрт булды:

— Әй тавык баш! Шуны да белмисеңме? Бүген тауга бер көтү бүре килгән. Дүрт колынның бугазын чәйнәп, каннарын эчкәннәр, үтереп киткәннәр... Синең Алмачуарың үлмәгән, тик азрак яраланган гына...— ди.

Башыма нидер сукты, телем тотлыкты, сүз әйтә алмый катып калдым.

Апуш, моны күргәч:

— Тиле, нәрсә торасың! Бар, йөгер! Әнә алып кайтып киләләр,— дип, түбән очка, күпергә таба күрсәтте...

Чыннан да, ул яктан бер көтү халык әллә ничаклы бияләр, тайлар, колыннар куып киләләр иде.

Үземне-үзем белмәдем, шул якка очтым.

Ни күрим!

Зур арбага безнең кола ат җигелгән: тәртә янына бурлы бия бәйләнгән, ул бертуктамый кешни, каядыр китәргә, ычкынырга азаплана.

Арба янында эткәй килә...

Якынрак баргач, тагы авыр хәл: минем Алмачуарым, аяклары бәйләнеп, арбага салынган...

Ни эшлим? Аптырадым. Каттым...

— Эткәй, безнең колынны да үтергәнмени?— дип кычкырып елап җибәрдем.

XIII

Яра тирән түгел икән. Минем бәхет җиңде: көн-төн карау аркасында, бер атна дигәндә, минем Алмачуарым бөтенләй элекке хәленә кайта алды.

Алмачуарым белән бергә мин дә авырган — йокымны, ашау-эчүемне югалткан идем, ул терелеп уйный башлагач, мин дә аңардан калышмадым.

Кыш шулай үтеп китте. <...>

XV

Җәй, көз, кыш үтә. Яз килә.

Минем Алмачуар өченчегә керә. Авылда, бу яшькә җиткәч, тайларны «беренче сабанга керде» дип сөйлиләр. Акрынлап, җиңелчәләп җигә башлыйлар.

Мин үзем моңа якын китермәдем. Ләкин гөлләр чәнечкесез булмый икән шул. Гөнаһ шомлыгына каршы: «Тарыны йомшакка чәчсәң, чүп басып харап итә»,— дигән дә, эткәй Кысылдык башкортларыннан мәңге сабан-сука кермәгән бер җир, каты чирәм сатып алган. Тимер сабанны чыдатырлык түгел — урыны-урыны белән ташлы, чыбыклы җирләре дә бар. Шуңа күрә әллә кайчаннан кузгалмый яткан авыр төрән сабанны тартып чыгаралар. Моны ике ат йөртә алмый. Дүрт, иң азында — нык, таза өч кирәк.

Үзара сөйләшкәннәр дә өченчегә Алмачуарны җигәргә булганнар. Моны ишеткәч, мин, еларга җитешеп, эткәйгә бардым.

— Ник минем Алмачуарны сабанга җигәсез?— дидем дә түзә алмый елап ук җибәрдем.

Минем тавышка әнкәй дә килеп керә. Ул Алмачуарны миннән көнләшә булса кирәк. Кайчан гына шул турыда сүз чыкмасын, мине тиргәргә, каһәрләргә тотына...

— Фу, илаһым,— ди,— нинди бәла-каза килгән дип торам... Бер тай өчен адәм шулчаклы акырыр икән,— ди...— Әллә аны гомер буена җикми асрар идеңме? Менә тилергән нәрсә!..— ди.

Эткәй ачуланмый, кызмый, мине юатырга тырыша. Мин аның саен ярсыдым, аның саен елый бирдем.

Ашарга чакырдылар — кермәдем. Туктаусыз еладым да еладым...

Уянып китсәм, ишегалдында түшәктә ятам.

Төш ауган. Кояш түбәнәеп бара... Йортта бер кеше дә күренми. Сабаннар, арбалар да юк, капка тулы ачык тора.

Сикереп тордым да абзарга йөгердем.

Барсам, ни күрим?! Минем Алмачуар, озын тезген белән бәйләнгән хәлдә, улакның бер башыннан икенче башына йөреп тора...

Телләребез сөйләмәсә дә, без бер-беребезне бик тирән аңлыйбыз. Мин килеп күренүгә, ул шатланып ук китте...

Улагын төзәттем, коега илтеп, су эчерттем дә өйгә кердем.

Әнкәй ярым шелтә, ярым елмаю белән каршы алды:

— Елак малай! Җинден бит, ахрысы! Вилдан абзыйларың да безнең белән бергә янәшә чирәм алганнар икән, шулар белән алмашлап сөрергә булдылар,— ди.

Шатлыгым йөрәгемнән тулып таша. Җире-күге, бөтен дөньясы минем шатлыгымнан һәммәсе бииләр кебек тоела.

Бүген әни яныннан китмәдем. Ни кушса, барын-барын тыңладым.

Утын керт, диде — аны керттем. Каз бәбкәләрен Өзән елгага илтеп кайт, диде — аларны илттем. Тавыклар йомырка салгандыр, ояларны кара, диде — аңа йөгердем...

Бу юлга җиңүен җиңдем...

Әмма бу җиңүләр миңа бик кыйммәт төшкән чаклар да булды.

Мин берәр төрле карулаша башласам, тыңламасам, хәзер күз алдыма Алмачуарны китереп куялар.

— Бик күп сөйлән тагын! Алай бик каршылансаң, Алмачуарыңны тотарбыз да урманга җигәрбез,— дип куркыталар.

Моңа җавап кайтарырга сүзем булмый, телем киселә: үземне җиксеннәр, аңа риза, тик минем Алмачуарыма гына тимәсеннәр... Урманга, тауга-ташка, сабан-сукага җиксәң, ул ничек чаба алачак? Ни булса булыр, авырга җиктермим, менәм, чабыштырам, чабарга өйрәтәм, тирә-якта беренче чабышкы ясыйм!

XVI

Менә күптән көтелгән көн килеп җитте.

Бүген Сабан туе!

Андый-мондый гына түгел, тирә-якта бик сирәк була торганы — бик зурысы, бик шәбе! Данлыклы чабышкылар җыелалар. Атаклы көрәшчеләр киләләр. Алмачуар белән минем өчен дә бүгенге көн, бәлки гомергә бер генә килеп китә торган зур көннәрдәндер. Айгырым сыналмаган түгел, үзара ат ярышлары күп булды. Һичкемнең аты минем Алмачуарга якын килмәде — кузгалып китү белән мин очам, башкалар күз күреме җир артта калалар.

Әмма, әмма бу Сабан туе башкарак. Әллә кайдагы, тау эчендәге башкортлар дан тоткан чабышкылары белән килгәннәр, диләр. Араларында бер Күк бияне бик мактап сөйлиләр, үткән ел Өфе каласында чаптырганда, бөтен атларны адәм күлкесенә калдырган, диләр.

Башкаларны уйламыйм да. Менә шул Күк бия мине куркыта. Кайдан гына килеп чыкты икән соң ул гөнаһ шомлыгы нәрсә?!

Чаба торган атны бөтенләй башкача әзерләргә тиешле була икән: заманында күп чабышкы ат асраган Сафа карт, яз чыккач ук, әткәйгә моның юлларын өйрәтте: нәрсә ашатырга, ничек эчертергә, көн саен ничек аз-аз гына йөртеп кайтарырга — һәммәсен әйтеп бирде.

Әти иренми, көн-төн карый. Мин аңа ияреп йөрим. Ансыз да асыл сөяк булган Алмачуарым бу арада карап туйгысыз булып чибәрләнде.

Ул электән дә ашауга бик назлы иде. Ахрысы, ярыш көннәренең якынаюын сизәдер, үзен үзе бик артык саклый башлады. Шуның белән бергә, аны тыюлар бик авырайды. Атланып кына барырга кирәк чакта да, башка берәр ат арттан килеп уза башласа, тыеп тотармын дип уйлама, — авызлыкны тешләп ала да канатланып оча гына!

Әткәй белән Сафа бабай, шаяртыпмы, чынлапмы, кайбер вакыт башка берәр малайны мендереп чаптыру турында сөйлиләр:

— Син яшьсең. Алмачуар да әле зур җирләрдә чабып өйрәнмәгән,— диләр.

Мин якын да килмим. Тагы әйтсәләр, күзләрем яшьләнә башлый.

XVII

Бүген бөтен авылның асты өскә килә. Әллә ничә йөзләп егетләр ат менеп чыкканнар да, яшь киленле йортларга кереп, сөлге җыеп йөриләр. Малайлар, кайсы атта, кайсы җәяү, өйдән өйгә йомырка җыярга чыкканнар.

Башка Сабан туйларында мин дә шулар эчендә кайнаша идем. Бусында күңелем ул якка бармый.

Алмачуарның йөрәге түзми, баскан җирендә тора алмый. Мин аны менеп, берничә мәртәбә урап кердем. Яраулануы җитсен, дим.

Камчының бик зәһәрен әзерләделәр. Өскә кызыл кижеле күлмәкнең калынын кидем. Минем ат чибәрлектә беренче: аңа атланган малай да начар күренмәсен, дим.

XVIII

Мәзин өйлә намазына азан әйтергә дип манарага менгән генә иде, тагы Сафа бабай килде:

— Атлар китәргә вакыт җитә, әйдәгез мәйданга барыйк,— ди.

Йөрәгем суга, тәнем бераз калтырый, күкрәгем никтер кысып-кысып ала.

Алмачуар миннән дә яманрак тынычсызлана.

Эти айгырны җитәкләде, мин аякны чишендем, чалбарны салдым да бер кулга камчы белән яшел яулыкны алдым.

Өчәүләп Җамали карт тыкрыгыннан туры мәйданга таба карап киттек.

Безнең авылның кояш батышы ягында зур киң бер сырт бар. Сабан туен һәрвакыт шунда ясыйлар.

Бер якта аллы-гөлле, кызыллы-яшелле чүпрәк диңгезе үзалдына дулкынланып тора, — болар хатын-кызлар. Икенче якта, бик куе булып, ирләр бер түгәрәк ясап оешканнар. Монда көрәш барадыр. Болардан читтә бала-чага, карт-коры, сатучы-фәлән, ат, арба, белмим, әллә ниләр кара болыт кебек бөтен сыртны каплап алганнар.

Бераз еракта, басу киртәсе буендарак, атлар йөреп тора.

Кайберенең өстендә яулыклы малай, кайберләрен икенче атка менгән кеше җитәкләп йөртә. Барының да эчләре суырылганнар. Бары да — карап торырга сөлек кебек маллар. Болар — чабышкылар.

Без теге халык диңгезеннән сулга, шул чабышкылар йөргән якка таба киттек. Боларга якынайган саен, минем Алмачуарның сабырсызлыгы арта бара иде.

Ул арада мәйданнан Садыйк абзый атка атланып килеп чыкты. Кулында зур таяк, аның башына кызыл башлы сөлге элемгән.

Ул чабышкыларга якынрак килде дә:

— Вакыт җитте, китә башлагыз, алдан китүчеләр «Ялгыз каен» янында көтәрләр,— дип кычкырды.

Мине Алмачуарга күтәреп менгерделәр, яулыкны урадылар; кәләпүшне әткәйгә бирдем.

Башка сүз әйтмәделәр. Тик Сафа бабай гына:

— Башта бик куалама, аерманың бу ягына чыккач кызганма, нык сук! Берүк тезгенеңне иркен куй! Тарткалап баруны ярата торган мал түгел бу! — дип, кат-кат әйтеп калды.

Без, Ялгыз каенга карап, үзеннән-үзе очарга барган атларыбызны көч белән тыя-тыя киттек.

XIX

Ялгыз каен бездән унбиш чакрым.

Башка елларда булса, җиде-сигез чакрымнан чаптыралар иде, быел, төрле илләрнең данлыклы атлары килгәнгә, шулай ерактан куйганнар, диләр. Ялгыз каенга ничек килеп җиткәнне белмим. Бу бик артык газап булды. Әлбәттә, атлап

кына барырга кирәк. Алмачуарны тыяр хәл юк. Алда яисә артта берәр ат күрсә, авызлыкны тешләп ала да оча гына. Мин барып җиткәндә, атларның күбесе андалар иде инде. Ерак китмичә, туктаусыз йөреп торалар.

Боларны күргәч каушап калдым: берсеннән-берсе сылу, берсеннән-берсе асыл маллар. Өметем азаеп ук калды. Болар бит берсе дә Алмачуардан ким түгел!

Теге данлыклы Күк бия дә килеп җитте. Күрүгә, шуңардан күзләремне алмадым. Гаҗәп бер мал икән: кыска яллы, сирәк койрыклы, чандыр гәүдәле нәрсә. Очасы тар, бер якка бераз чалыш, аркасы бераз бөкрерәк. Әмма күкрәк дигәне бөтенләй арысланныкы — шундый киң, шундый нык күренә. Тезләре ике яккарак китеп тора, бәкәлләренә карагач, тагы хәйран калдым: алар шундый озыннар ки, мин гомеремдә андыйны күргәнем юк. Күзләре зурлар — уйнап, ялкынланып торалар. Өстенә кечкенә, кап-кара, башы бөтенләй ялангач, кулына камчы тотып, бер башкорт малае менгән.

Кечкенә булса да, күп чапкан малайдыр, ахры, бер дә каушамый, атның холкын бик белгәнгә охшый.

Чабышкылар арасында иң тыныч торганы шул Күк бия иде.

Атлар килеп бетте, Садыйк абзый безне тезә башлады. Бусы бик зур бәла икән: инде тигезләп тездем генә дигәндә, йә берәүнең аты кузгалып, алга китеп бара, йә баскан урынында тора алмыйча, кире чигенә. Күп азаплардан соң тезеп җиткерде:

— Берәү, икәү, өчәү! Һайди, туганнар!— дип кычкырып та җибәрде.

Ул «һайди»ның «һ»сен әйтеп бетерә алмагандыр, атлар әйтерсең канатланып очтылар.

Башкалар кая киткәннәрдер, узганнардырмы, артта калганнардырмы — белә алмадым. Урыннан кузгалуга, без өч ат: мин, Күк бия, тагы бер җирән чабышкы, бер-беребезгә бәрелә язып, янәшә оча идек.

Аяклар җиргә тияме, әллә атлар яшерен канатлары белән һавадан баралармы — әле дә аерып җитә алмыйм. Агачлар, елгалар, зур-зур баткаклар — алда, ничектер, күзгә чалынырга өлгерә алмыйлар, без аларны яшен кебек үтеп тә киткән булабыз.

Аеркул дигән бер тайгак елга бар. Бу юлда иң куркыныч нәрсә шул, диләр иде.

Очкан кошлар кебек, без бер-беребезне таптап, узып, каулашып, ул баткаклы елгага өчәү килеп кердек, ләкин ярның янында Күк бия белән минем Алмачуар гына иде, өченче иптәш — җирән чабышкы, малае белән баштүбән шунда баткакка чумды булса кирәк.

Инде икәү ярышабыз...

Көчләр бик тигез: бервакыт аның аты чак кына арттан бара, ләкин тагы бер каулый, минем атның башы Күк биянең койрыгы янына кала.

Тагы бер баткак; минем башым әйләнә, үзем егылам кебек булам. Күңелгә шөбһә килә; күзне йомам да Алмачуарның ялларына тотынам. Ачсам, баткакны чыкканбыз, ләкин Күк бия миннән өч-дүрт сажин алдан оча.

Инде якынлыйбыз да бугай, авылның манаралары күренгән кебек була.

Гайрәт белән бер тартам, камчы белән уңга-сулга җан ачуы белән сугам. Алмачуарым «әһ» дип суырып ала да, күз ачып йомганчы, Күк биянең алдына барып чыга...

Менә авыл, әнә басу капкасы, менә сырт өстен каплаган кара болыт кузгала!

Чабышкы иясе безгә каршы ат өстендә киләләр.

Арада әткәй дә күренеп кала.

— Һайди, Закир, тагы бер сук! Тагы бер! Тагы!

— Һайди, Алмачуар!

— Һайди, Күк бия!..

Ике яклап безне каулыйлар... Кычкыралар, сугалар, шаулашалар.

Ләкин Алмачуар белән Күк бия бөтенләй диярлек янәшә киләләр.

Тагы бер тартып җибәрдем, тагы бер бөтен гайрәтем белән уңнан-сулдан сугам...

Алмачуар «әһ» дип бер суырылып ала да, Күк бияне аршын ярым чамасы калдырып, мәйданга килеп тә керәбез...

Кара болыт икегә ярыла.

Күк биянең башы минем Алмачуарның кабыргасындарак булган хәлдә чикне дә узып китәбез!

Шау-шу, тавыш, тапталыш! Әйтерсең мәхшәр көне!

Старостаның бер кулында яшел чапан — бусы беренче килгәнгә, икенче кулында зур сөлге — бусы икенче килгәнгә билгеләнгән.

Тузан, шау-шу эчендә староста, ялгышмы, ничектер, чапанны Күк биягә сузды, минем Алмачуарның муенына сөлгене ташлады:

— Син икенче килдең бугай,— ди.

Ни эшләгәнемне белмәдем, күз алдым караңгыланды, камчы белән уратып-уратып старостаның йөзенә селтәдем дә, кызулык белән Күк биядән чапанны тартып алып, бу кара болыт эченнән чыгып, читкә киттем. Камчы тигәндерме, юкмы — белмәдем...

Аны карап торырга вакыт та юк: чабып килгән атны туктатырга ярамавы һәркемгә билгеле бит!

Ул арада Сафа бабай, эткәй, күршеләр килеп, мине ат башыннан кочаклап алдылар. Һәммәсе мактый, һәммәсе рәхмәт укый. Сафа бабай, кат-кат башымнан сыйпап:

— Егетсең, балам, йөзне хур итмәдең,— ди.

Эткәй Алмачуарны җитәкләп йөртә башлады. Мин, яулыкны ташлап, кәләпүш кидем дә кайнашып торган халык туфанына барып кердем.

Малайлар мине куркыта башладылар:

— Камчы белән сугып, старостаның битен яргансың. Ну, бирер үзеңә дә кирәгеңне! — диештеләр.

Ул арада староста үзе дә килде. Йөзе, чыннан да, ярылган булса кирәк: ак яулык белән бер күзе ашасыннан бәйләнгән.

Мин аңардан курыкмадым, тик аптырап калдым. Ул ачуланмады гына түгел, мине кочаклады, башымнан сыйпады да:

— Мин — балачакта үзем дә атка менеп күп чапкан кеше. Алдан килеп тә, икенченең бүләген бирсәләр, җан түзәлми аңа. Мин сиңа ачуланмыйм, арыгансың, бар кайт инде,— дип, миңа егерме тиенлек көмеш бирде.

Дөнья минеке иде. Бөтен тирә-якта дан тоткан Күк бияне узып килү Алмачуар өчен һичкемнең акылына килмәгән бер бәхет иде.

XX

Ләкин бу бәхет тиз арада бик артык авыр бәхетсезлеккә әйләнде. Белмим, атымны кызу каулап яндырганмынмы, белмим, килеп җиткәч, староста белән талашып, туктап тору харап иткәнме — ни дә булса булган: Сабан туеның икенче көнендә Алмачуар аякларына баса алмас булды, ашавыннан-эчүеннән калды. Бичаракаем, адәмнән болай акыллырак күзләре белән һәркемгә мөлдерәп карап, бер атнага якын

ыңгырашып ятты да җомга көн иртә белән сәгать унда дөньядан китте.

Алмачуар җан биргәндә, мин аның баш очында идем. Елый алмадым. Йөрәгем таш булып катты.

Шуннан соң дөньяда һичбер малга, һичбер әйбергә күңелем дә, күзем дә төшмәде: һичбер нәрсәне сөя алмадым.

Алмачуар минем йөрәгемдә җиргә, күккә, адәмнәргә — бөтен нәрсәләргә булган мәхәббәтемне үзе белән бергә алып китте.

1922, февраль, Казан

Без сезнең белән күләмле, күп вакыйгалы әсәр белән таныштык. Бу әсәрдә катнашучылар саны да, аларның сөйләгән сүзләре дә күп. Ләкин ул, шигырьләрдәге яки җырлардагы кебек, дүртәр юлга бүленмәгән, көйгә салынмаган. Гадәти сөйләм телендә язылган. Гадәти сөйләм телендә язылган әсәрләргә **чәчмә әсәр** диләр. Көйгә салынган, сүзләре бер тәртипкә салынган, тәртип белән төзелгән шигырьләргә, җырларга **тезмә әсәрләр** диләр. Аз гына кеше катнашса, бер яки ике генә вакыйгасы булса, андый чәчмә әсәрләргә **хикәя** диләр. Әмирхан Еникинең «Матурлык» әсәре — хикәя, чөнки анда бик аз кеше катнаша, вакыйгалар бик аз. Ә менә «Алмачуар» әсәрендә вакыйгалар күп. Башкортның Хафизга ат бирү вакыйгасы, балыкка бару вакыйгасы, Закирның абыйсын нахакка төрмәгә ябу вакыйгасы, Алмачуарны ярату вакыйгасы, Сабан туе вакыйгасы... Бу вакыйгаларның берише бөтенләй башкаларга бәйләнмәгән мөстәкыйль вакыйгалар рәвешендә киләләр. Бу әсәрдә катнашучылар да күп. Соңрак күрербез, бик мөһим мәсьәлә дә күтәрелә. Шундый катлаулы чәчмә әсәргә **повесть** диләр.

Әсәрне өйрәнергә керешик. Әсәрне өйрәнү — аңа анализ ясау дигән сүз икәнлеген без инде беләбез.

Катлаулы әсәргә анализ ясау да катлаулырак булачак, әлбәттә. Ә анализ ясарга кирәк. Шулай итми торып, вакыйгаларга автор салган эчтәлекне, бәяне белә алмаячакбыз.

Әйдәгез, башта әсәрне укыганнан соң туган беренче тәэсиргә таянып кына повестьның темасын белеп карыйк. Аны беләсе дә юк, автор үзе «Бер мәхәббәтнең тарихы» дип язып куйган бит, диярсез. Шулай, әлбәттә. Повестьта мәхәббәт турында күп языла. Шулай булгач, бу әсәр мәхәббәт турында булырга тиеш. Ләкин автор мәхәббәтнең тарихы дигән, кемгә

мәхәббәт икәнлеген әйтмәгән. Тарихын ачыкламаган. Тагын әйтерсез: билгеле, Закир исемле малайның Алмачуарга булган мәхәббәте турында, диярсез. Чыннан да, әсәрдә атка булган мәхәббәт турында шундый матур итеп язылган, чаптар атның үзенчәлекләрен, Сабан туендагы ярыш вакытындагы ат һәм ат өстендәге малай кичерешләрен укып хәйран каласың! Ул урыннарны табып, дәрестә сөйләсәгез, тагы да яхшы булыр иде. Ләкин бәяне Закирга түгел, ә язучы Галимҗан Ибраһимовка бирергә тырышыгыз. Чөнки шундый самими итеп, ышандырырлык итеп, яратып сөйләүче Закир язучы сүзләрен сөйли бит. Шуның өчен сүз язучының осталыгы турында барырга тиеш.

Ә хәзер анализга әйләнеп кайтыйк. Чыннан да, бу әсәр мәхәббәт темасы белән генә чикләнәме? Әллә анда башка тема да бармы? Шуны белик.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәрдәге төрле вакыйгаларның темаларын белик. Башкортның Хафизга ат бирү вакыйгасын сөйләгез. Бу вакыйгага бер сүз белән исем бирегез: ул нәрсә турында?

2. IV бүлектәге кара бай һәм Закирның абыйсы вакыйгасын сөйләгез. Аңа бер сүз белән нинди исем бирер идегез?

3. Ат китерүче башкорт Әлемгол бай хисләрендә каршылык бармы? Аңа авыл халкы нинди бәя бирә? Авторга Әлемголны саран итү нигә кирәк булган?

4. Әлемголның кара бай белән уртак ягын һәм аермасын күрсәтегез.

5. Бу ике вакыйганы кушып, бер темага язылган вакыйгалар дияргә мөмкинме?

6. Закирның старостага камчы белән сугу вакыйгасын сөйләгез. Аңа да бер сүз белән исем бирегез: бу вакыйга нәрсә турында — шуны әйтегез.

7. Бу вакыйганы да әлеге ике вакыйгага кушып буламы?

8. Әгәр өч вакыйгада бер үк тема табабыз икән, димәк, автор белеп бер үк нәрсәне өч мәртәбә кабатлаган дигән сүз. Ә без беләбез: язучы үзенә бик әһәмиятле нәрсәне генә кабатлый. «Мокамай» шигырендәге урман шаулавы кабатлануын исегезгә төшерегез. Шул сәбәптән бу өч вакыйганы бер өлеш итеп ала алабыз. Шулай итсәк, икенче өлешкә нинди вакыйганы кертәбез?

9. Әсәрдә Закир турында күп сөйләнә. Закирның әтисе белән әнисенә мөнәсәбәте нинди? Ул әтисен ни өчен аеруча нык ярата?

10. Закирны әнисе ни өчен гел ачуланып тора? Ул хаклымы? Закир әнисенә ярдәм итәме? Ничек ярдәм итә?

11. Закир ни өчен балыкка бара? Ул балык тотарга яратамы?
12. Закир Алмачуарны ни өчен ярата?
13. Алмачуар үлеменә кем гаепле? Бу хакта әсәрдә ничек әйтелгән? Сез ничек уйлыйсыз?
14. Сезгә Закир ошыймы? Ошаса яисә ошамаса — ни өчен?
15. Һәр ике өлешнең эчтәлеге белән танышкач, ике өлеш арасында бәйләнеш табып карагыз. Беренче өлеш икенчесенә чагыштыру — метафора була аламы? Була алса, ни өчен, була алмаса да ни өчен икәнлеген әйтегез.
16. Повестьта Галимҗан Ибраһимов вак елгаларның, кушылып, диңгезгә коюлары турындагы вакыйганы өч мәртәбә кабатлый. Бу вакыйга әсәр идеясенә метафора — чагыштыру булып килә аламы? Килсә, нинди мәгънә бирә ала?

Габдулла Тукай

Исемдә калганнар

I

Минем атам Мөхәммәтгариф, Кушлавыч авылында Мөхәммәтгалим исемле мулланың угылы булып, карт атасы тере вакытта ук авылыбыз Кушлавычка мулла булмыштыр.

Минем туганыма биш ай үткәч, атам аз гына вакыт авырып үлгән. Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам, мине авылыбыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрь карчыкка вакытлыча асрарга биреп калдырып, үзе Сасна исемле авылның мулласына кияүгә чыккан...

Мин бу карчык өендә кадерсез, артык бер бала булганлыктан, ул мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән: тәрбияләү түгел, яшь балаларның иң мохтаҗ булдыклары ачык йөзне дә күрсәтмәгән.

Мин үзем ул карчыкта үткән заманның ничеклеген белмим. Ул вакыт мин ике-ике ярым яшемдә генә булганмын дип уйлыйм.

Хәзер авылда минем балалык вакытымны күргән карчык вә хатыннар тәрбияче карчыгымның минем белән бик начар мөгамәләдә булганлыгын үземә хикәя итәләр.

Җөмләдән берсе: «Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк күлмәкчән көенчә тышка чыгам икән дә бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачмак балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, табигый, мин ишекне ача алмыйм вә ишек төбендә аякларым бозга ябышып катканчы көтеп торам икән».

Карчык исә үзенең: «Кадалмас әле килмешәк!» — дигән «шәфкатьле» фикере илә мине үзе теләгән вакытта орыша-орыша кертә икән...

Ул карчык үлгән инде; Алла аңар рәхмәт итсен.

Мин бу карчыкта торган вакытта, анам да теге муллага үзләшеп җиткән булса кирәк, ул бервакыт мине үзе янына Саснага алдырырга атлар җибәрткән.

Хәер, алып киткәннәр генә түгел, шул атка утырып киткән минутларда мин, бала булсам да, хәзер дә атта утырып Саснага барганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда, күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам.

Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвеш бардым, мине кемнәр каршылады — анысын белмим; ләкин үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә.

Ләкин бу рәхәт озакка бармаган. Минем анам бу муллада бер ел кадәрме, күпмедер торгач, белмим, нинди авырудандыр вафат булган.

Әни дә үлгәч, мин бөтенләй ятим булып җиткәнгә, мин бу Сасна мулласы өенә дә сыймаганга, ул мулла мине Өчиле авылындагы анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән.

Минем анамның анасы булган үз әбием әни кыз чакта ук үлгән булганга, бабай кайсы мулладандыр тол калган бер хатынны аңа ияреп килгән алты баласы илә алган булган.

Өчиле авылы (исеменнән дә мәгълүм) бик кечкенә вә бик ярлы бер авыл булганга, шуның өстенә мин ятим калган елларда ул тарафларда каты ачлык булганга, бабайның көнкүреше гаять начар булган.

Менә шул фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызлы булган гаилә эченә мин ятим бала булып килеп кергәнмен.

Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине еласам — юатучы, иркәләним дисәм — сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә кызганучы бер дә булмаган, мине этәннәр дә төрткәннәр.

Бу гаилә эчендә фәкыйрьлек шул дәрәҗәгә җиткән булырга кирәк ки, мин, хәзер дә булса, бабайның күрше баерак авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтканын исемдә тотамын.

Шул рәвешчә көннәр үткән, мин, монда торганда, чәчәк белән дә авырганмын, башка әллә нинди хәстәлекләр дә күргәнмен, тәмам зәгыйфьләнгәнмен.

Бу гаиләдә һәммәсе (бер җитеп килә торган Сажидә исемле кыздан башкасы) минем авыруыма: «Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде»,— дип кенә караганнар. Мин әле хәзер әйткәнем Сажидә апайның, үги әбидән яшереп кенә, мине юатканын вә сөйгәнен, әби килә башлагач та, минем белән эше юк кеше шикелле, үзенә икенче кыяфәт биргәнен һаман хәтеремдә саклыйм.

Ни күрсәм дә күргәнмен, ни булса да булган, һәрничек мин бу гаиләгә сыймаганмын. Беркөнне бабай, үги әбинең киңәше илә булырга кирәк, авылыбыздан Казанга бара торган бер ямщикка мине утыртып, Казанга озаткан.

Ямщик Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан алтмыш кына чакрым), Печән базарында: «Асрарга бала бирәм, кем ала?»— дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктан алган. Ул мине, асрау бала итеп, өенә алып кайткан.

Мин монда торганымны ярты йомык күз белән генә күргән шикелле булам.

Мәсәлән, бервакыт әллә нинди авырудан күзем авырган вакытта, мине бер карчыкка алып барганнарын, ул минем күзгә шикәр салганын, үземнең салдырмаска азапланганымны, тартышканымны беләм.

Бу яңа ата-анамның хәлен дә бераз язып китим әле. Миңа әти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Торулары Яңа Бистәдә иде.

Әти толчокта сату итә идеме, әллә тиречә идеме шунда — анысын яхшы белмим. Әни, бер дә армый-талмый, байларга кәләпүш эшләп чыгара иде.

Әни, Печән базарына кәләпүш чыгарганда яки бер хезмәт илә байларның өенә барганда, кайвакыт мине дә ияртеп баргалый иде.

Бу ата-анам икесе дә эш кешеләре булдыкларыннан, монда миңа ач торырга туры килми иде.

Кайчакта әни белән Ташаяк базарына барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самокатларда шатланып-шатланып агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем.

Мин дә атланыр идем — акчам юк. Әнидән сорарга куркам, ул үзе белеп бирми иде.

Шулай итеп, мин кеше рәхәтенә генә кызыгып кайта идем. Аннан соң җәй көне ике бистә арасындагы яшел үлән өстендә малайлар илә каз йоннары куып йөргәнемне, арыгач, хан мәчетенә юнәлеп ятып, чирәмдә ял иткәнемне бер дә онытмыйм.

Мин бу ата-анамда ике елмы, күпмедер торгач, әти дә, әни дә — икесе берьюлы авырый башлаганнар.

Алар, үзләренең үләчәкләреннән куркып: «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, исән чакта, авылына кайтарыйк»,— дип, теге мине Казанга китергән ямщикны табып, мине янәдән, аңарга утыртып, Өчиле авылына җибәргәннәр.

Инде миннән мәңгелеккә котылдык дип уйлаган бу гаиләнең мине ничек каршы алганлыкларын уйлап белергә мөмкин.

Мин кайтып бераз торгач та, әби белән бабай, инде мине шәһәргә җибәрүдән өмет кисеп, кая булса да бер чит авылга асрарга бирергә уйлашканнар.

Болар Өчилегә килгән һәрбер чит авыл кешесенә үзләрендә асрарга бирергә бер ятим бала барлыгын сөйләгәннәр.

Шулай мәшәкатьләнә торгач, бездән җиде генә чакрым Кырлай исемле авылдан ир баласыз Сәгъди исемле бер кеше килеп, мине үзенә алып киткән...

II

Бабайлар өеннән чыгып, Сәгъди абзыйның арбасына утырдым. Бабай белән әби (Сәгъди абзыйдан яхшысынмый гына булырга кирәк) мине озатырга чыктылар...

Арба кузгалды. Сәгъди абзый белән без янәшә утырып киттек. Ул юлда миңа: «Менә хәзер Кырлайга кайтып җитәбез, анда әниең каршы чыгып көтеп тора торгандыр. Алла боерса, бездә катык, сөт, ипи күп, теләгәнчә ашарсың»,— дип, миңа барып җитәргә ике-өч кенә чакрым калган бәхетләр илә мине юатып бара иде.

Мин дә, ачык йөзләрне бик күптән күрмәгәнгә күрә, эчемнән бик шатлана идем.

Бу вакыт җәйнең матур чаклары булганга, тирә-яктагы яшел чирәмнәр вә урманнар, артык эссе булмыйча, үзенең нурлары белән сөеп кенә торган кояш, икенче яктан, тагын рәхәтләндерәләр иде.

Ниһаять, Кырлайга барып кердек. Сәгъди абзыйның йорты басу капкасыннан кергәч күп ерак түгел икән, аз гына баргач, коймасы читәннән булган тәбәнәк кенә салам түбәле бер өйгә туктадык.

Юлда, Сәгъди абзый әйткәнчә, вакыйган, минем әни каршы чыккан икән, ул капканы ачты; мине ачык йөз илә каршы алып, арбадан күтәреп төшереп, өйгә дә алып керде...

Тыштагы эшләрен караштыргалагач, атын туаргач, әти дә өйгә керде. Кергәч тә, әнигә эндәшеп: «Хатын, бар, балага катык белән ипи китереп бир»,— дип әмер итте.

Әни дә, шунда ук баздан катык алып менеп, миңа зур гына икмәк телеменең яртысын тоттырды.

Мин исә, Казаннан кайтканнан бирле юньләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, икмәк белән катыкны ялт иттердем.

Тамак туйгач, әнинең рөхсәте илә, урамга чыктым. Мин, анда чыгып, адашудан куркып, артыма карый-карый гына барадыр идем, менә берзаман тирә-ягымны әллә кайдан килеп чыккан авыл малайлары сарып алдылар.

Алар, һәркөн авылның бер башыннан бер башына йөгереп тә, бу көнгә кадәр мине күрмәгәнгә, аннан соң минем өстемдә Казаннан киеп кайткан каюлы ситсы күлмәк, башымда да, мине Өчилегә кире җибәрер алдыннан, әнинең, миңа сагынмалык булсын дип, төрле төсле хәтфәләрдән корамалап ясаган кәләпүше булганга, бу Кырлай малайлары миңа бик гаҗәпләнеп карыйлар иде.

Малайлар карап-карап тордылар да таралдылар; мин бүген аларга катыша алмадым, өйгә кереп киттем.

Өйгә кайтып керсәм, анда ике җиткән кыз күрдем.

Боларның берсе таза гына гәүдәле, кызыл йөзле, күк күзле, икенчесе арык кына, сары йөзле, култыгында агач таяклары бар, аксак бер кыз иде.

Әни миңа: «Менә болар — апайларың: берсе Саҗидә апаең, берсе Сабира апаең, күреш!» — дигәч, мин, әкрен генә барып, кулымны суздым.

Болар Сәгъди абзыйның кызлары булып, аксагы Саҗидә атлы икән. Шулай итеп, мин монда яхшы гына тора башладым. Авыл малайлары белән таныштым...

Мин барып бер аймы, күпмедер торгач, урак вакыты җитте. Әти, әни вә ике апай уракка китә башладылар.

Мин исә уракка бармый идем. Иптәш малайлар белән авыл буенча йөгерә вә болынлыкларда көн буе ауный идем.

Алар, әбәттән (көндезге аштан) соң ишекне бикләсәләр дә, минем ашарга кайтасымны белеп, ян тәрәзәне эчтән бикләми китәләр иде.

Урак вакытында бөтен халык һәммәсе эшкә китеп, авылда эшкә ярамаган карчыклардан башка һич кеше калмаганлыктан, без бакчадагы яшел суганнар башына бер дә кәҗәдән ким бәла булмыйдыр идек...

Әгәр уйный торгач тирләсәк, хәзер үзебезнең ындыр артындагы кечкенә генә инешкә төшеп, шуннан әллә ничәшәр сәгать чыкмыйча коенып, күлмәк-ыштаннар белән вак балыклар сөзеп ята идек. Күңелле чаклар!

Бервакыт шулай уйнап йөргәннән соңра, кич белән өйгә кайтсам, өй эчендә һәммә кешене күңелсез вә кәефсез күрдем. Бу нидән икән дип уйлап торгач, Сабира апаның идәннән сәкегә котырган шикелле йөрүен вә кая барып бәрелгәнен дә белмәвен һәм күзләре әллә нинди коточкыч булып акайганын күргәч, аның урактан «җенләнеп» авырып кайтканын белдем.

Ул төнне өйдәгеләр берсе дә йокламый үткәрделәр. Мин генә, бик йокым килгәч, тыштагы арбага чыгып йокладым.

Иртә белән, таң сызылып килгәндә, колагыма: «Сабира апаң вафат булды; син йоклап ятасың, тор, тор!» — дигән бер тавыш килгәч, күземне ачып карасам, каршымда әни тора иде.

Бу, билгеле, миңа да гади хәбәр түгел — йокы тәмле булса да, сикереп тордым.

Шул көнне Сабира апаны җирләделәр. Аны җирләп берничә көн үткәч, әнинең әтигә:

— Менә «үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр; үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр» шул инде ул, мөгаен, шуның шомлыгыннан булды инде бу! — дип сөйләгәнен ишеткәли башладым.

Аннан соң кайчакларда әнинең йә кушкан йомышын тыңламасам, йә җиренә җиткерми эшләсәм; шул сүзне әйткәли торган иде.

Әти белән без бик тату идек. Ул бер дә миңа каты сүз әйтми иде.

Мәсәлән, бервакыт минем Казаннан киеп кайткан күлмәк-ыштаннарым, читек-кәвешләрем, казакиларым тузгач, әти үзенең мин килмәстән бер ел элек үлгән улының күк киндер күлмәге белән бишмәтен миңа бирмәкче булды.

Шунда әни: «Мин үз улымның төсе итеп саклаган киемнәрне кешегә бирер хәлем юк»,— дип бик озак тарткалашты.

Ахырда әти: «Йә, хатынланма әле юкка, үзеңнән тумаган бала дип, әллә аны шыр ялангач йөртерсеңме?»— дип, киемнәрне, көчләп диярлек, миңа алып киертте.

III

Шулай итеп, урак бетте, көз җитте. Ашлыклар эшен бетергәч, бакчага чыгып, бәрәңге казырга вакыт җитте.

Бу бәрәңге казу вакытында, миңа урак вакытындагы кеби уйнап йөрергә туры килмәде: миңа казып чыгарган бәрәңгеләрне капчыкка тутырырга куштылар. Мин дә үз хезмәтемне яхшы гына эшләдем.

Бу вакыт көз көненең салкын вакытлары булса да, мин яланаяк идем.

Бервакыт шулай аякны балчыкка күмеп бәрәңге чүпләгән чагында, теге бәрәңге казучы аксак Сәҗидә апай ялгыш минем аякка тимер көрәк белән чапты.

Аяк шактый тирән җәрәхәтләнде, мин дә, урынымнан сикереп торып, бераз читкә барып утырып еладым да, соңра җәрәхәткә балчык сибеп, янә хезмәтемдә дәвам иттем; ләкин бу юлы аяклар никадәр туңсалар да, балчыкка күмәргә курыктым.

— Моны ни өчен яздың?— диярләр.

Ни өчен яздым? Шулвакытта аягым бик авыртканга вә хәзер дә аякта шул җәрәхәтнең эзе булганга, тоттым да яздым.

Бара торгач, бакча эшләре бетте.

Беркөнне кич әти белән әни иртәгә иртүк мине абыстайга укырга илтәчәкләрен мәгълүм иттеләр.

Таң атты, кояш чыкмас борын ук торып, чәй эчтек. Чәйне җыештыргач, әни мине кулымнан җитәкләде дә үзебездән биш-алты гына адым булган Фәтхерахман хәзрәт өенә алып барды.

Анда барып кердек, мине укытачак абыстай кулына чыбык тотып утырган; аның тирә-ягында минем яшемдәге кечкенә кыз балалар булганы кеби, шактый җитеп килә торган кызлар да бар иде. Алар арасында, богдай арасындагы берничә борчак кеби, берничә минем шикелле ир балалар да бар иде.

Әни иң элек ике бөтен икмәк белән бер тиенме, ике тиенме акчасын абыстайга тоттыргач, алар да, бөтен шәкертләр дә бик озак дога кылдык.

Әни мине тапшырып үзе киткәч, мин кызлар белән бергә «әлеп, пи, ти, си»не берничә көн такмаклагач, миңа «Иман шарты» да тоттырдылар...

IV

Бу Кырлайдагы беренче кышым үтте. Яз җитеп, карлар эри башлады. Озакламый кырлар, игенлекләр, тәмам кардан яланга калып карала башладылар.

Менә бераздан Сабан туе җитте. Мине Сабан туе көнне иртә үк уятып, кулыма янчык дәрәҗәсеннән аз гына үткән кечкенә бер капчык тоттырдылар.

Мин, шул капчыкны тотып, авыл буенча киттем.

Авыл халкы, тегеләй дә иртә торучан булса да, бүген Сабан туе бәйрәме көне булганга, бигрәк тә иртә торганнар, вә һәр өйдә һәркемгә күләч йөз, тәмле сүз иде.

Мин кайсы гына өйгә керсәм дә, ятим калган мулла баласы икәнемне искә алгач, миңа башка малайларга биргән кеби конфет, бер-ике перәнник кенә бирмичә, һәр йорт иясе дә буялган күкәй бирәләр иде.

Шунлыктан минем капчыгым буялган күкәйләр илә бик тиз тулып, өйгә дә кайтып кердем. Башка малайлар һаман йөреп калдылар шикелле.

Әти белән әни дә минем капчыгым болай тиз тулуына гаҗәпләнделәр дә, шатландылар да.

Ул көнне чәй эчтемме, юкмы — анысын белмим, капчыкны әнигә бирдем дә үзем, кулыма берничә күкәй тотып, урамга чыгып чаптым.

Мин урамга чыкканда, кояш күтәрелгән, бөтен авыл нурланган, авыл егетләре, авыл кызлары, ак оекларын мөмкин кадәр шомартып киеп, чабата киндерәләрен дә бик тырышып, матурлап бәйләп, урамга чыкканнар иде.

Бер яктан Сабан туе башлыгы да, кулына бер таяк башына чүпрәк таккан әләм тотып, өй саен яулык, ситсы кеби нәрсә җыеп йөри иде. Без яланаяклы малайлар исә аның артыннан бер дә калмыйча йөгерә идек.

Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач, бөтен авыл халкы — хатын-кызы, баласы-чагасы болынлыкка төштеләр.

Көрәшләр, узышлар башланды.

Болынлыкта йөк-йөк белән торган чикләвек, көнбагыш вә кызыл билле ак перәнникләр хисапсыз иде...

Атлар да чабышты. Малайлар да йөгереште, яулыклар да алынды, шулай итеп, Сабан туе да бетте.

Исемдә юк инде — бу Сабан туе ничә көн булгандыр, мин бер көнен генә яздым. Бәлки, өч-дүрт көн булса да, миңа бер генә көн кеби тоелгандыр.

Шуны да әйтергә кирәк: мин бу җәйне үткән җәй кеби йөгереп, уйнап үткәрә алмадым, чөнки шушы язга чыгар алдыннан гына Сәгъди абзыйның бер ир баласы дөньяга килгәнгә, мин, әни эштә чагында, һәрвакыт шул баланы юатып, тирбәтеп утыра идем.

Менә тагы урак вакыты да җитте, үткән җәй, бөтен авыл халкы эштә булганда, урам буе чабып йөргән мине — бер малайны — быел Садрины (ул бала Садретдин исемле иде) тартып йөрергә уракка да алып чыктылар. Шунлыктан бу җәем эш белән үтте.

Бу бала тугач, әтинең мине сөюе әүвәлгечә бөтен калса да, әни миңа, эш кушарга кирәк булмаса, сүз дә дәшмәс булды. Шөйлә ки, мин үз өлешемә төшкән аз гына мәхәббәттән дә коры калдым.

Җитмәсә тагы, теге аксак кыз да: «Үз энем! Җан энем!» — дип Садрины юри мине кәефсезләндерү өчен сөйгән була иде.

V

Көз җитте. Гадәттәге бәрәңге хезмәтемне иткәч, мине бу юлы (кызлар белән бергә абыстайга түгел) мәдрәсәгә бирделәр.

Мин мәдрәсәдә үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт торырга туры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар.

Шул балалар арасында авылыбызның бер бай баласы да булып, ул мине, хәлфәсе кебек итеп, чәйгә вә эченә борай ярмасы салган бәлеш ашарга чакыргалый иде.

Бер яктан, мин сабагымны яхшы белсәм, икенче яктан, аз булса да йорт хезмәтләренә ярый башладым.

Мәсәлән, иртә белән менеп морҗа ачу, аннан соң морҗа ябу, мичкә ягу өчен салам көлтәләр бәйләү, сыерны көтүгә чыгару, кич каршы алу кебек эшләр — һәммәсе минем кулымнан киләләр иде.

Кайвакыт җәй көне әти белән Әтнә базарына бара идек. Ул үзенең хезмәтләре илә базар арасында йөргәндә, мин атны тотып тора идем.

Авылыбызның мулласы Фәтхерахман хәзрәт, белмим, берзаман әтинең сабакташы йә дусты булганмы, нидәндер, миңа атна саен биш тиен акча бирә иде.

Мин бу акчага Әтнә базарында ак күмәч сатып алып, өйгә кайтканда, юл буе ашап кайта идем.

Әти мәрхүм, арбаның артында күмәч ашап утырганда, миңа кисәктән әйләнеп карап: «Күмәчеңне әниеңә дә калдыр»,— дип куя иде. Мин дә, әлбәттә: «Ярар»,— дия торган идем. Ләкин ул күмәч, авылга кайтып җиткәнче, вак-вак кына капкаласам да, әнигә кала идеме, юкмы — хәтерләмим.

Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным булганга, андагы хатирәләргә озаграк туктарга туры килде.

Саҗидә апа, чахотка белән бик озак авырып, хәтта мунчага-фәләнгә барганда, аны әти үзенең аркасына күтәреп йөри торгач, ниһаять, үлде. Әтине дә, кич белән әллә кайсы авылдан кайтып ат туарган чакта, кисәктән килгән бер авыру эләктерде. Аның шунда ук аңсыздан бер аягы аксады. Бу авыру хакында «ат җене сукты», «йолдыз атты», фәлән кеби төрле хөкемнәр йөрттеләр. Әти бу авыру сәбәпле эштән калмады, тик бер аягы гына чатанлап йөрүчән булып калды.

Бервакыт, көз көне, өйләдән соң, әти белән әни ындырда иде, мин ян тәрәзә төбендә «Рисаләи Газизә» укып утыра идем, безнең капкага бер арбалы кеше килеп туктады.

Бу кеше, атын куеп, өйгә керде дә миңа: «Әти-әниең кайда?» — диде.

Мин: «Ындырда»,— дидем. Бу кеше: «Бар, чакырып кайт»,— дигәч, мин, тиз генә ындырга йөгереп барып: «Өйгә әллә нинди бер кеше килгән, сезне чакыра»,— дигәч, алар хәзер кайтырга булдылар.

Бераздан ишектән әти белән әни килеп керделәр, мосафир белән күрештеләр.

Чәй куелды. Бу юлы, кунак булса да, чәй янына, нидәндер, мине дә утырттылар вә, гадәткә каршы буларак, минем алдыма бер шакмак шикәр дә куйдылар.

Әтинең: «Ни хезмәт илә килдегез?» — дигән сөаленә каршы, мосафир: «Менә бу баланы алырга килдем»,— диде.

Бу сүздән әти, бик гаҗәпкә калып: «Ничек ул? Ник син алырга килдең?» — дип сөальләр бирә башлагач, мосафир бу рәвешчә сүзгә башлады:

— Мин — Кушлавыч кешесе. Бу бала — авылыбызның имамының баласы. Без аны ничә еллардан бирле югалтып, кайда икәнлегеннән хәбәрсез идек, менә хәзер таптык. Ул сездә икән. Җаек каласында аның атасы белән бертуган апасын алган җизнәсе бар. Менә шул җизнәсе, каенесенең болай кара кешеләр арасында йөрүен ишетеп, аны Җаекка

үз катына чакырмакчы була. Менә мин быел Җаектан, аның кушуы буенча, бу баланы эзләргә чыктым, менә хәзер алып китәм»,— диде.

Мосафирның бу сүзләренә этинең дә, әнинең дә бик кәефләре китте. «Ярар менә, без икмәкнең поты фәләнчә кадәр кыйммәт вакытта аны өч-дүрт ел ашатып торыйк та, хәзер, эшкә ярар вакыты җиткәч, сиңа биреп җибәрик, имеш. Юк, булмас. Әгәр ул кардәше булса, ник аны әүвәлдә күрмәгән» кеби сүзләр илә нык тартыштылар.

Ара-тирә әни дә: «Юк, бездә кешегә бирә торган бала юк!»— дип куйгалый иде.

Мосафир Бәдретдин абый: «Юк, сез не имеешь право кеше баласын тотып торырга, мин хәзер урядникка әйтәм, әле без аны таба алмыйча йөрсәк, ул сездә икән. Мин сезне подсуд җибәрермен»,— дип, авыл халкын куркытырга җитәрлек иттереп сөйләгәч, бичара эти-әни йомшардылар.

Бераздан минем тату тормаган әнием: «Йә атасы, бирик инде, ахры, кеше баласы безгә булмас, Алла сакласын, әллә ниләр күрербез»,— дип, үкереп елап та җибәрде.

Озакламый, җил басылганнан соңра, бераз дулкынланып торган диңгез кеби, актык вә йомшак тартышу белән генә тартышкач, эти дә риза булды.

Иске-москы бишмәтләремне, тишек киез каталарымны кидереп, күп тә үтми, мине арбага чыгарып утырттылар.

Эти-әни, бичаралар, һәр икесе егълаганнары хәлдә, мине басу капкасына кадәр озатып бардылар.

Ахырда әни: «Онытма безне, онытма! Безне онытсаң, тәмуг кисәве булырсың»,— дип, ахыр сүзен кычкырды да, без авылдан чыгып киттек. Минем китү мәсьәләм бөтенләе ярты сәгать диярлек аз вакытта хәл ителгәнгә, авылдагы иптәшләр вә таныш-белешләр илә күрешә алмадым. Алар белми калдылар.

Без юлга чыккач, күп тә үтми кич булып, караңгы төшә башлады.

Юлда Өчиле авылына — бабайларга төштек. Анда чәй эчтек. Бу гаиләнең һәммәсе мин күргәндәгечә бергә торалар, фәкать Сажидә апай гына кияүгә киткән иде.

Чәй эчкәч, әллә нинди Югары Аты, Түбән Аты, Урта Аты авылларын үтеп, төн урталарында үземнең туган авылым Кушлавычка барып кердек.

Юлда килә-килә, мин, арбада шактый ватылган булырга кирәк, Бәдри абзыйның өенә кергәч тә, эреп йокладым.

Иртә белән торгач, үземне бер кара өй эчендә күрдем. Бу өйнең эчендә табак-савыт, кашык-чүмеч, камыт-шлея кеби нәрсәләр генә булып, җиһаз-фәлән кеби нәрсәләр бер дә юк иде.

Чәй эчтек. Бәдри абзыйның Гайшә исемле зур гәүдәле, күк күзле, ачык кына йөзле бер хатыны, Камалетдин исемле 14—15 яшьлек бер угылы вә Кәшифә исемле 12 яшьләрендә бер кызы, вә Нәгыймә исемле бер имчәк баласы бар иде.

Чәйдән соң өйдән чыгып, аңа каршырак салынган ак өйгә кердек.

Бу инде мин кунган кара өйгә охшамый. Стеналары сапсары нараттан, җиһазлары вә язу өстәлләре авыл кешесе өчен җитәрлек иде.

Бәдри абзыйның амбарлары тулы ит, бодай, арышларны күргәч, мин аның бу авылның иң бай кешеләреннән берсе икәненә хөкем иттем.

Тагы Камалетдин миңа, көз җиту сәбәпле яме киткән булса да, умарта оялары белән тулган шактый зур бакчаларын да күрсәтеп йөрде.

Мин инде, бер кергәч, бу ак өйдән чыкмас булдым вә шунда куна да башладым...

Кая барсам да, мине мулла баласы дип халык башка малайлардан аерганга, хәтта җыеннарда яшьтәш кызларым илә «таккаравыл» уйнау да миңа гаеп булганга, мин үзем дә үземне һәрвакыт мулла баласыча тотарга вә укыган китапларым илә гамәл итәргә тырыша идем.

Мәсәлән, берзаман Бәдри абзыйларга килгәч, минем илә күрешергә Ситдикъ исемле, авылымызның шактый могтәбәр кешесе килде, үзе исерек иде.

Миңа килеп сәлам бирде — сәламен кайтармадым, кулын сузды — кулын алмадым.

Сәбәбен сорадылар. Мин шулвакыт «Бәдәвам»ның:

Исереккә сәлам бирмә,
Ул бирсә дә, син алма... —

бәетен ярдым да салдым. Моңар бөтен Бәдри абзый гаиләсе гаҗәпләнүдән башка, минем бу диндарлыгым авылга җәелде.

Бәдри абзый, мине өенә алып кайткач та, үзе бер эш белән Казанга китте.

Ул анда бер ай торган арада, мин дә буш ятмадым. Камалетдин илә бергә авылыбызның мәдрәсә шикелле бернәрсә-

сенә барып, сабак укыдык. Күп вакыт куныш укырга да туры килә иде.

Хәзрәтләре, ахры, бик «кысып» укыта торган вә кешене «гыйлем» итә торган кеше булырга кирәк ки, шул аз вакыт эчендә дә мин аның көн саен әллә ничәшәр баланы эт урынына кыйнаганын күреп, калтырап торганым бар.

Кайчан да булса бервакыт бу хәзрәт таягының миңа да эләгү ихтималы мине куркытканга вә таң белән, шәкертләр белән бергә куылып, иртә намазына бару бик авыр булганга, эчемнән: «Ай, Бәдри абзый кайтса, тизрәк Җаекка китәр идем»,— дип көтә идем.

Берзаман Бәдри абзый кайтты. Миңа яңа бүрек, яңа киезката, яңа бишмәт алып кайткан.

Мин бу яңалыкларны бик зур куанычлар илә кидем дә үземнең иске киемнәремнән бүрегемне, «бервакыт кайтып карармын» дип, чормага яшереп, саклап куйдым. Бу да гаҗәп эшләремнән берсе иде.

Шуннан соң Кушлавычта берничә көн генә тордык та Бәдри абзый белән Җаекка таба юнәлеп чыгып киттек.

Бер тәүлек кадәр баргач, Казанга килеп кереп (Печән базары тирәсе булырга кирәк), бер урынга тукталдык.

Шулвакыт күрдек ки, безгә таба күзләре яшәргән, куллары җәелгән, сакалы агарып бетә язган бер кеше йөгереп килә.

Бу, минем яныма килгәч тә: «Әле син теремени?! Анаң әле кичә генә сине төшендә күргән иде, әйдә өйгә алып барыйм: чәй эчәрсең, бездә кунарсың»,— дип, мине алып китте.

Өйгә барып кердем. Анда әни каршы алды. Бичара, сагынган икән, ул да елады.

Минем өчен хәзер чәй куелды. Әни харчевнядан пилмән алып чыкты: сыйландык. Миннән моңа кадәр ниләр күргәнемне сораштылар. Мин дә онытмаган кадәрене сөйләдем...

Бу ата-анамның, мин аерылып торган вакытта, әтинең сакалы агаруы вә, Яңа Бистәдә булып, хәзер Иске Бистәгә күчүләреннән бүтән үзгәреш күренми иде.

Ул кичне шунда кундым. Иртәнге чәйне эчкәч, әни мине ләгәнгә утыртып юындырды. Яхшы кәләпүш һәм кыш көне барачак минем озын сәфәрем өчен кирәкле булган бер тире чалбар китерде...

Без торган номер бик начар да, бик яхшы да түгел, уртача гына бер номер иде.

Җаектан мине алырга килүче Алты-биш Сапый дигән кеше әле Казанга килеп җитмәгән иде. Шул сәбәпле Бәдри абзый белән без бер-ике атна кадәр шул кешене көтеп яттык.

Ниһаять, безнең көткән Алты-биш Сапыебыз килеп, без торган номер күршесенә төште.

Ул килеп берничә көн торгач, Бәдри абзый мине аның номерына күчерде дә, үзе, миңа алты данә икешәр тиенлек унике тиен акча биреп, авылга кайтып китте...

Бәдри абзыйдан калган унике тиенгә тозлы балык — вобла һәм көнбагыш алып ашадым.

Берничә көн торгач, Җаекка юнәлдек.

Мине, чыпталы чананың өстен каплап, Алты-биш Сапыйның хатыны алдына утырттылар да һичбер яктан да сулыш алырга бирмәделәр...

Мин никадәрле: «Җәяү барсам да, тышта, иркендә барам»,— дип гозерләнсәм дә, «туңарсың, җизнәң туңдырмаска кушты»,— дип, мине чыгармыйлар иде.

Шул сәбәпле ябык чана зинданында, мең төрле газаплар эчендә, тәмам унсигез көн булды дигәндә кичкә таба Җаекка барып кердек.

Җаекта иң әлек Сапый абзыйның өенә төштек.

Кичкә таба, икенде белән ахшам арасында, Сапый абзыйның җитәкчелегендә җизниләргә киттем.

Юлда яшел чапан бөркәнгән яшь кенә бер хатын очрады. Алты-биш Сапый: «Бу — апаең, күреш»,— дигәч, моның илә күрештем.

Җизниләрнең өе бер ун сажин гына булыр ераклыкта икән, капкадан кереп, биек-биек баскычлардан менеп, өйнең икенче катына кердем.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Исемдә калганнар» — чәчмә әсәр, ләкин хикәя дә, повесть та түгел. Габдулла Тукай башта ук «исемдә калганнар» дип кисәтеп куя, башымнан үткәннәрне генә сөйлим, ди. Шуңа күрә бу әсәрдәге вакыйгалар урыннарын үзгәртергә дә, арттырып сөйләргә дә баш-аяклары белән каршы торалар. Алай да, кечкенә Габдулла әле бер гаиләдә, әле икенче гаиләдә яшәгән дип, әсәрне өлешләргә бүлә алабыз. Шул өлешләрнең һәрберсендә Тукай үзе күрмәскә тырышкан каршылык бар. Искә төшерик әле: кечкенә Габдулла, кая гына тормасын,

бер генә урында да бәхетле булмый. Кем тәрбиясендә генә яшәсә дә, аның тормышы авыр була. Әмма Габдулла Тукай бер генә урында да зарланмый. Зарланмый гына түгел, хәтта үз тормышын мактый да. Нигә шулай итә? Югыйсә без барыбыз да зарланырга яратабыз бит.

2. Бу әсәрдә ике Тукай бар. Берсе — кечкенә Габдулла. Барлык вакыйгаларда да ул катнаша, бала күңеле белән һәрнәрсәгә бәя бирә. Икенчесе — автор Тукай — Габдулла Тукай. Автор үзенең бала чагын исенә төшерә һәм хәзер шул чактагы вакыйгаларга да, андагы кешеләргә дә, кечкенә Габдуллага да бәя бирә. Ә кечкенә Габдулла көлә, шатлана, кайгыра, рәнҗи, кимсенә. Габдулла Тукай — автор — хәзер шул кечкенә Габдулланың кичерешләре өчен дә үзе кабат кайгырырга, шатланырга, үкенергә тиеш була. Автор Тукай үзенең бала чагына нинди бәя бирә? Кечкенә Габдулла хисләре — әсәрдә автор Тукай хисләренең сәбәбе бит. Мәсәлән, Габдуллага Сабантуйларында бүләкне күп бирәләр. Габдулла җыйган йомыркаларына чиксез шатлана. Олы Тукай бу шатлыкны ничек кабул итә?

3. Габдулла Тукайның бабасына бәя бирегез. Үз бәягезне шагыйрь бәясе белән чагыштырыгыз.

4. Габдулла Тукай истәлекләрен игелек турында дияргә дә була. Шуны исбат итегез. Кемнәр кемнәргә игелек эшлиләр?

5. Әсәрдә авторның игелеге күренәме?

6. Габдулла Тукай бик яратып, үзенең иң бәхетле көннәре дип, Сабан туен яза. Ни өчен Сабан туе көннәрен үзенең иң бәхетле көннәре дип бәяли?

МИФЛАР

Мифлар — бик борынгы бабаларыбызның иҗат җимеше. Мифларда дөньяга, тормыш күренешләренә, кош-кортларга, җәнлекләргә, хайваннарга, кешеләргә аңлатма бирелә. Кешеләрнең, җирнең, утның, суның, үсемлекләрнең яки кош-корт, хайваннарның төрле сыйфатларының ничек барлыкка килүе турында әйтелә. Миф — борынгы кешеләрнең фәне дә, матур әдәбияты да. Аң дәрәҗәләре түбән булганга, борынгыларның бу иҗат җимешләре дә беркатлы, безнең өчен хәзер көлке булып чыккан. Алай да, шул беркатлы мифларында бабаларыбыз гаҗәп матур сурәтләр, вакыйгалар уйлап тапканнар. Әсәрләренә тирән мәгънәләр салганнар. Шундый мифларның дүртесе белән танышыйк.

Тавык

Бик борын заманда хайваннар, кош-кортлар берәр-берәр генә булганнар. Бөтен Җир шарында бер сыер, бер арыслан, бер елан, бер эт, бер тавык — һәммәсе, һәммәсе берәр генә булган. Бер-берсен кыерсытмаганнар, бар да үлән белән генә тукланганнар, шуңа күрә үзара бик тату яшәгәннәр.

Көннәрнең берендә җыен кош-корт, хайван, җәнлек җыелганнар да бергәләп кое казырга дигән карар чыгарганнар. Шулай уйлашканнар һәм коены казый да башлаганнар. Дуслар бар да тырышып казый, тик тавык кына эшләмичә чүпләнеп йөри, эшләми.

— Казыш, казышмасаң, су эчертмәячәкбез,— дип кисәткәннәр тавыкны.

— Үзегез казыгыз, миңа кое кирәкми. Миңа, эчәсе килгәндә, яфракка төшкән чык та җитә,— дип җавап биргән тавык.

Тырыша торгач, дуслар коены казып бетергәннәр. Туйганчы су эчкәннәр дә төрлесе төрле якка үз эшләре белән киткәннәр. Ә казышырга ярдәм итмәгән тавык эчмәсен дип, коеларын сакларга арысланны калдырганнар.

Җәйнең эссе чаклары булган. Кояш кыздырган да кыздырган. Күктә яулык кадәр дә болыт заты күренмәгән. Төннәрен дә эссе булган, яфракларга бер тамчы чык төшмәгән. Кое казучылар эчәселәре килгән саен килпләр дә эчәләр, киләләр дә эчәләр. Тамагы бик кипкәч, кое янына тавык та килгән. Ләкин арыслан аны куып җибәргән. Тагын килгән тавык, арысланга килеп тагын ялварган: «Бер генә тамчы бирче, тамагым бик кипте»,— дигән.

— Бар, әнә үлән яфракларындагы чык тамчыларыңны эч,— дип җавап биргән арыслан.

Ә кояш кыздырган да кыздырган. Сусаудан тавык җан бирер дәрәҗәгә җиткән. Арыслан аны барыбер коега якын китермәгән. Хайваннар арасында әчеле-төчеле мөнәсәбәт шуннан башланган.

Ниһаять, түзәр чамасы калмагач, тавык күккә караган да Аллага ялвара башлаган:

— Йә Алла, мин дөньяда бердәнбер тавыгың бит. Мин сусаудан үлсәм, җирдә бер генә тавык та калмаячак. Бер генә тамчы булса да су бирә күр, коткар,— дигән.

«Чыннан да, бу ялкау үлсә, җирдә тавык калмый. Тагын берне тудырып була булуын, тик аның өчен тагын мәшә-

катьләнәсе бар, башка эшне ташлап торырга туры киләчәк. Йә, ярый, әйдә, яшәсен»,— дип уйлаган Алла. Ә тавыкка болай дигән:

— Хуш, синеңчә булсын. Әйдә, яши бир. Мин сиңа су бирәм. Тик белеп тор, син гаделсезлек эшләдең, кешеләр казыган коедан су эчмәкче булдың. Башкалар сүзен тыңламадың, ялкауландың, киреләндең. Шуның өчен җәза алачаксың. Моннан соң авызыңа алган һәр тамчы суыңны миннән рөхсәт сорап кына эчәрсең.

Тавык шатланган. Ләкин арыслан биргән бер тамчы суны томшыгына капкан да Алладан рөхсәт сораган: «Эчәргә рөхсәт итсәңче»,— дигән. Рөхсәт алгач, тагын, тагын шулай иткән, тамчы суын рөхсәт алгач кына йоткан.

Шул көннән башлап, тавыклар барысы да, су эчкәндә, башларын күккә күтәреп рөхсәт алалар да йоталар, рөхсәт алалар да йоталар.

Тәрбиясез тавык борын-борын заманда шундый җәза алган. Аның гаебе аркасында нәселләрендәге бөтен тавык су эчкән саен иза чигә.

Нәркәс чәчәге

Борын-борын заманда бер чибәр егет яшәгән. Егет шулкадәр чибәр булган, аңа хәтта кояш та көнләшеп карый торган булган. Шул заманда һәм шул ук урында чибәрләрнең дә чибәре бер кыз да яшәгән. Аңа кояш та, ай да сокланып карый торган булганнар. Ике чибәр бер-берсен яратырга тиешләр иде дә бит, ләкин алай булып чыкмаган. Кыз егеттән күзен ала алмаган, шулкадәр яраткан. Егетнең исә исе дә китми икән. Хәер, аның, гомумән, бернәрсәгә дә исе китмәгән. Кыз килеп сүз дәшә, егет җавап бирми, кыз алдына килеп баса, егет борылып китә. Каядыр карап, нидер уйланып бара да бара, бара да бара. Шулай бара торгач, бик матур түгәрәк күл янына килеп чыккан. Менә ул күл суында битен юарга иелгән һәм суда бер бик чибәр егет йөзен күргән. Егет үзенең шәүләсенә шунда ук гашыйк булган. Судагы шәүләсенә караган килеш торган да торган. Кызның иseме Кайтаваз икән. Ул егеткә берничә мәртәбә сүз катып караган. Әмма тегесе берни ишетмәгән, һаман үз шәүләсенә карап торган. Ашамаган, эчмәгән егет, судагы шәүләсеннән аерыла алмаган. Үзенә үзе шул дәрәҗәдә гашыйк булган. Торган, торган һәм

шул баскан җирендә нәркәс чәчәгенә әйләнгән. Нәркәс чәчәге шулай барлыкка килгән.

Ә Кайтаваз кайгысыннан таулар эченә кереп киткән. Кызның башкалар белән кайгысын уртаклашасы килгән. Сөйләшәсе килгән. Ләкин ул сүз әйтә алмас хәлгә килгән. Нибары кеше әйткәнне генә кабатлаган. Кешеләр, килеп: «Ау»,— дип кычкыралар. Кайтаваз аларга: «Ау»,— дип җавап бирә. «Кайтаваз! Син кайда?»— дип дәшәләр. Ул аларга: «Кайтаваз! Син кайда?»— дип җавап бирә.

Кешеләр, җәнлекләр сүзен, тавышын кабатлап, Кайтаваз таулар арасында һаман кайгысын уртаклаша алмыйча йөри. Теләсәгез сез аның белән хәзер дә сөйләшә аласыз. Ләкин ул нибары сезнең сүзләрне кабатлый гына ала.

Песи

Бик борынгы заманда, кош-корт, җәнлекләр арасындагы татулык беткәч, песи чыпчык тоткан һәм корбанын ашарга җыенган. Чыпчык, хәленең мөшкеллеген белеп, хәйләгә керешкән:

— Язмышым сиңа азык булудыр. Ярый, ашасаң ашарсың. Үлгәнче үзеңә бер үгет бирәсем килә. Син мине шулай ук битеңне-кулыңны юмый ашаячаксыңмы? Бу бит — әдәпсезлек. Әдәпкә өйрәнергә кирәк.

Песи уйлап-уйлап торган да чыпчык сүзләре хаклы дигән нәтиҗәгә килгән,— кулларын, битләрен ышкырга, чистарырга керешкән. Ләкин авызын сөртә алмаган — авызындагы чыпчыгы комачаулаган. Песи чыпчыкны авызын сөрткәнче генә куеп тормакчы булган. Ә чыпчыкка шул гына кирәк тә, песи авызыннан төшү белән очкан да киткән.

Песи үзенең алдануын бик тиз аңлап алган, ләкин инде соң булган, чыпчык агач башында, ә ул ач калган. Шул көннән алып песиләр кулларын, битләрен ашаганнан соң гына юа башлаганнар.

Дөреслек

Бер кеше үзенә биек, зур кәрзин үргән. Ябар өчен капкач та ясап куйган. Капкачын ачып, кәрзингә башын тыккан да «дөреслек» дип кычкырган һәм тиз генә капкачын ябып куйган.

Булды, дөреслек миндә, хәзер ни генә эшләсәм дә дөрес эшләячәкмен, дип уйлаган. Эшен бетергәч, бу кеше бәхет эзләргә чыгып киткән. Дөреслек синдә булганда бәхет табу җиңел булуына аз гына да шикләнмәгән.

Кәрзинен аркасына аскан да киткән бу. Бара торгач, зур күл күргән. Янына килеп күлгә караса, анда — алма. Берәү генә дә түгел, икәү, бишәү, унау. Кәрзин хуҗасы шатланган. Дөреслек бәхет китерә башлады да, дип уйлаган һәм алмага дип суга кереп киткән. Кулын су астына тыгып эзли — алма юк. Чыгып ярдан карый — алмалар үз урынында. Тагын суга кереп китә — алмалар тагын югала. Тагын чыгып карый — алмалар тагын үз урынында.

Бу кәмитне читтә бер карт карап тора.

— Ни эзлисең күлдә?— дип сорый.

— Алма,— ди кәрзин хуҗасы.

— Суда алма үсми. Агач башында үсә, башыңны күтәреп кара, әнә бит яныңда гына тора,— дигән хуҗа.

Әлеге бәхет эзләүче кеше башын күтәреп карамакчы була, ләкин булдыра алмый, аркасына аскан кәрзине комачаулый. Кәрзинен салып өскә караса, алмалар, чыннан да, ярда алма агачында үсеп утыралар. Суда ул аларның шәүләсен генә күрә икән. Бәхет эзләүченең кәрзиненә, бигрәк тә кәрзине эчендәге «дөреслек»кә бик нык ачуы килә. Тотына таптарга, тотына таптарга, яньчеп, җимереп бетергәнче таптый. Бу хәлне күреп, картның кәефе була.

— Дөрес эшләдең. Синдә булган дөреслек әле ул бердәнбер дөреслек түгел, дөреслек ул башкаларда да, табигатьтә дә бар,— ди.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Тавык» мифында әсәрне әсәр иткән иң мөһим урынны табыгыз. Ул мифның кайсы өлеше? Хайваннарның татулыгымы, берәр генә булуымы, кое казуларымы, тавыкның аерылуымы, суны башын күтәреп йотуымы?
2. Бу мифтагы гаделлекне ничек аңлатасыз?
3. «Нәркәс чәчәге» мифын үз сүзләрегез белән сөйләп чыгыгыз. Егетнең чәчәккә, кызның кайтавазга әверелү сәбәпләрен табыгыз. Бу сәбәпләр арасында нинди аерма бар?
4. Кайтаваз кичереше турында сөйләгез. Кыз хисләренә бәя бирегез.
5. Егеткә бәя бирегез. Аны «Алмачуар» повестендагы Закир белән чагыштырыгыз. Алар арасында нинди уртаклык бар, шул хакта сөйләгез.

6. «Песи» турындагы миф белән «Тавык» турындагы миф арасында нинди охшашлык бар?
7. Песигә нинди җәза бирелә? Ул ач кала. Ә тагын нинди җәза?
8. «Дөреслек» мифында карт: «Дөреслек берәү генә түгел»,— ди. Ул ни әйтмәкче була? Дөреслеккә мин генә ия, дигән кешегә бәя бирегез. Андый кешене тавык, нәркәс белән чагыштырыгыз.

БЕЛЕМЕБЕЗНЕ НЫГЫТУ ӨЧЕН КҮНЕГҮЛӘР

Ак бүре

(*Әкият*)

Борынгы заманда бар иде бер патша. Аның дүрт улы бар иде. Бу патшаның хатыны беренче дәрәҗәдә чибәр иде. Берзаман патша, хатыны белән икәү, ялан-япан сахрага чыктылар. Төннең бер мизгелендә боларның чатырларын бик каты җил исеп күтәреп ташлады. Шул ук вакыт һавадан бер дию пәйда булып, патша хатынын күтәреп алып китте. Патша, ат җиткән җиргә ат җибәреп, хат җиткән җиргә хат җибәреп, төрле якка эзләүчеләр җибәреп, хатынын эзләргә тотынды.

Бер елдан соң патшаның өлкән улы атасына әйтте:

— Инде, эти, мин укуның чигенә чыктым. Син инде миңа әнине эзләргә бер елга рөхсәт бир,— дип.

Атасыннан үзенә юлдашка бер йөз солдат алып, бер елга җитәрлек акча, азык-төлек алып, анасын эзләргә чыгып китте. Ай китеп, ел китеп, әйләнгән җирдә әйләнмә үсеп, тулганган җирдә кызыл тубылгылар үсеп, ташка тары үскәндә, бозга бодай үскәндә, аны шатыр-шотыр урып ятканда, болар барып җиттеләр куе бер урман эченә. Туктадылар су буена, сахралык җиргә. Иптәшләре, атларыннан төшеп, куышларын корып, шул ук сәгать суга киттеләр. Ашларын пешереп ашап утырган чакта, патша улының чатырына бер Ак бүре килеп керде һәм сәлам биреп әйтте:

— Әй ахмаклар, кем рөхсәте белән минем урманыма кереп, үләнемне таптап йөрисез? Рөхсәтем юк, хәзер үк чыгып китегез,— диде.

Патша улы:

— Син үзең кайдан килдең, шунда кит. Минем йөз солдатым бар, хәзер аттырырмын да үтертермен,— диде.

Ак бүренең бу сүзләргә ачуы чыкты. Алай да һаман боларга чыгарга кушты. Ләкин сүзен тыңламауларын күреп,

боларга карап бер дога укыды, өрде, тегеләр шуннан соң бар да торататш булып каттылар.

Бер елдан соң ике уртанчы улы да аталарыннан рөхсәт сорадылар:

— Без дә энине эзләргә чыгыйк,— диделәр.

Аталары, бик күп сорый торгачтын, боларга да бер елга рөхсәт бирде.

Болар да йөзәр атлы солдат, акча, азык-төлек алып, ике йөз дә ике кеше булып, юлга чыгып киттеләр. Шул чыгып китүдән иртән киттеләр, кич киттеләр, барып җиттеләр баягы урманның бер як читенә. Су эзләп алып килеп, аш пешереп ашарга утырганда, баягы Ак бүре килеп кереп:

— Кем рөхсәте белән килеп, бу чаклы солдат, атлар белән урмандагы үләннәрне таптап килеп кердегез?— диде.— Һич рөхсәтем юк,— дип, боларны да куа башлады.

Патшаның уртанчы уллары да, бүредән алайрак ачуланып, ике йөз атлы гаскәрләренә таянып:

— Син үзең кайдан килдең, шунда кит,— диделәр. Яхшылык белән берничә мәртәбә әйткәннән соң тыңламагач, Ак бүре боларны да торататш итеп катыра.

Тагын бер ел үткәч, кече улы патшага әйтте:

— Агаларым кайтмады, берәр хәл булгандыр. Миңа да рөхсәт бир дә, мин дә китим инде,— диде.

Көн-төн сорый торгач, атасы моңа да рөхсәт бирсә дә бирде, бирмәсә дә бирде.

Патшаның кече улы гаскәр алмады, азык-төлек алмады, бер бик яхшы атка атланып, юлга чыгып китте. Күп айлар, күп көннәр, сәгатьләр, күп минутлар киткәннән соң, әлеге урманның читенә барып җитте. Муенындагы мылтыгын корып, үземә ашарга берәр кош атып килә алмаммы икән дип, урманның эченә кереп китте. Бер ун адым гына киткән иде, баягы Ак бүре килеп чыкты. Бүре әйтте:

— И егет, син монда нишләп йөрисең, монда минем рөхсәтемнән башка үләннәрне таптавың җитмәгән, кошлар атарга барасың,— диде.

Егет Ак бүрегә:

— Бик арыдым, талдым. Бик ерак җирдән килдем. Инде алай булгач, синең рөхсәтеңнән башка мин монда бер эш тә эшләмим, кошыңны да атмыйм, атымны да ашатмыйм. Әнә күрәсең, атымның башын югары күтәреп бәйләп куйдым. Чыгам да китәм,— диде.

Бүре аңа каршы:

— Инде, егет, мин сине күрәм, үзең күркәм, сүзең тәмле, һичбер каршы килгән җирең юк. Алай булгач, мин сиңа бөтен урманымда йөрергә, атыңны ашатырга, кошларымны атарга рөхсәт итәм. Теләгәнеңне эшлә. Аш ашарга мин килермен,— дип әйтте дә үз юлына китте.

Егет кош атып, чатырын корып, аш хәзерләп, атын үләнгә җибәреп, әлеге Ак бүрене көтеп калды. Моның чатыры янына искәрмәстән генә бер яшь егет килеп чыкты да моңа сәлам бирде. Егет тә якты чырай белән каршы алды, ашын куеп, моны ашарга чакырды. Хәзерләнгән ашны тәмам ашап бетерә яздылар. Шулчакта келт итеп патша улының исенә Ак бүре килеп төште.

Кунак егет, моның уйлаганын күреп:

— И дустым, күңелле генә утырган чакта, әллә ни күңелсезләнеп киттең. Нәрсә уйлыйсың, ник эчең поша?— дип сорагач, патша улы Ак бүрегә бергә ашарга вәгъдә бирүен сөйләде.

— Инде хәзер шул Ак бүре килсә, ни ашатырмын, дип уйлый башладым,— диде.

Кунак егет аңа каршы:

— Аның өчен бер дә кайгырма. Ул бүре булып күренгән нәрсә мин идем. Минем җитмеш төрле һөнәрем бар, җитмеш төрле сурәткә керә алам,— диде.

Шуннан соң егетнең кайгысы бетеп, үзенең каян, ни өчен юлга чыгуын, агаларының югалуын — барысын да баштан-аяк сөйләп бирде.

Ак бүре моңа каршы:

— Соң син ул агаларыңны хәзер күрсәң таныр идеңме?— дип, иң олы агасының тораташ булып каткан җиренә алып китте.

— Менә бусы — синең өлкән агаң, янында яткан ташлар — аның батыр солдатлары. Алар минем сүземә каршы килделәр дә, мин аларны менә бу сурәткә керттем,— диде.

Егет елап җибәрде. Ак бүредән аларны яңадан әүвәлге кыяфәтләренә кайтаруын сорап ялына башлады.

Ак бүре егеткә:

— Ярый, мин, синең сүзеңне тыңлап, аларны әүвәлге кыяфәтләренә кайтарыйм. Мәгәр синең бу агаларың һәм аларның гаскәрләре сиңа юлдаш булырга ярый торган кешеләр түгел. Терелгәч тә, син аларны тиз генә шәһәргә кайтарып җибәр,— диде.

Ак бүре, тискәре якка карап, озын бер дуга укып, ташларның өсләренә өргән иде, бар да, сикереп торып, үзләренең иске кыяфәтләренә керделәр. Патшаның кечкенә улы барысын да аталары янына шәһәргә кайтарып җибәрде. Чатырга кайткач, бу егет Ак бүрегә:

— Мин юл кешесе, юл кешесенең юлда булуы яхшы, син мине тотма. Урманыңнан чыгып китәргә рөхсәт бир,— диде.

— Рөхсәт итәм,— диде Ак бүре.— Мәгәр мин сине, бу урманнан чыгып киткәнче, үзем озатып җибәрим.

Юлда барганда Ак бүре егеткә:

— Йә егет, мин белгәнем кадәр юлларыңны өйрәтим, бәлки, минем әйткәннәрем сиңа файда булып төшәр. Минем урманымнан чыгып өч көн, өч төн киткәннән соң, дию патшасының җиренә барып чыгарсың. Ул дию җиреннән өч көн, өч төн барганнан соң, алтмыш колач юанлыгы алтын тирәккә очрарсың. Аның астында бер кечкенә генә күл булыр. Аның янына землянка казып, үзеңне үзең күмәрсең, тик ике күзең генә калсын. Бу күлгә бер көтү елкылар килеп су эчәрләр. Аннан соң күк күкрәтеп, җир дөбердәтеп алтмыш колачлы ала айгыр килер дә алтын тирәкнең бер ягына ялын ышкый башлар. Озак ышкына торгач, әлеге алтын тирәкне сындырыр. Шулвакыт син базыңнан сикереп чык та бик тизлек белән ала айгырга атланырга тырыш. Атлана алмасаң, ялынаябышырга, ялынаябыша алмасаң, койрыгына ябышырга тырыш. Әгәр дә шулай итә алсаң, син анаңны табарсың. Инде ябыша алсаң, ул утка керсә — утка кер, суга керсә — суга кер, кулыңны ычкындырма. Ычкындырсаң һәлак булырсың.

Егет:

— Инде мин ни күрсәм дә чыдарга, анамның юлында корбан булырга дип килдем, һәммәсенә түзәчәкмен,— диде.

Егет Ак бүре белән исәнләшеп, аның урманыннан чыгып китте.

Бүре әйткәнчә, өч көн, өч төн барганнан соң, дию патшасының җиренә килеп керде, алтын тирәкнең янына барып җитте. Күл буена тиз генә баз казып, күзен генә калдырып, үзен күмеп куйды. Азмы-күпме ятканнан соң, бер көтү елкы су эчеп китте. Берәр сәгать үткәннән соң, зилзилә кубарып, күкне күккә орып, җирне җиргә орып, өермәләр өердереп, алтмыш колачлы ала айгыр алтын тирәкнең төбенә килеп, ялын ышкый башлады. Шул заманда, бик каты ышкуга чыдый алмыйча, алтмыш колачлы алтын тирәк шартлап

төбеннән сынды. Тиз заман егет ала айгырның ялына ябышты. Бик биек булганлыктан, өстенә менеп утыра алмады. Айгыр, ялына адәм заты ябышканны белеп, җилтерәтеп, бер җиргә, бер күккә, бер тауга, бер ташка орып алып китеп җиттеләр ут тавына. Ала айгыр егетне өстерәп утка алып кереп китте. Ут эчендә егетне өч сәгатьләп бутап йөрткәннән соң, аргы ягына барып чыктылар. Егет атның ялына тагын да катырак ябышып алды. Бер диңгезгә барып җиттеләр. Ат егетне диңгезгә алып кереп китте.

Өч көн, өч төн йөзгәннән соң, диңгезнең аргы ягына чыктылар.

Бераз коры җир белән барганнан соң, бер бик куе урманга җиттеләр. Бу урман аша чыпчык үтәрлек тә юл юк иде.

Ала айгыр егетне урманга алып кереп китте. Урманның куе агачлы бер җирендә егетне арлы-бирле агачларга сугып харап итмәкче булды. Әмма егеткә һичбер зарар килмәде.

Өч көн, өч төн үткәннән соң, мең мәшәкать белән болар урманның аргы ягына барып чыктылар. Азмы-күпме киткәннәр иде, бер бик биек тау-таш араларына килеп җиттеләр.

Ала айгыр:

— Йә инде, егет, хәзер, кулыңны миннән ычкындырып, шул җирдә кал,— диде.

Әмма егет:

— Үлсәм үләрмен, һичбер ычкындырасым юк,— дигәч, ала айгыр ачуланып, моны бер тауга, бер ташка орып, өч көн, өч төн киткәчтен, бер япан җиргә барып чыктылар.

Ала айгыр:

— Инде, егет, син хәзер күп нәрсәләр күрдең. Бу сулар, утлар, таулар, ташлар — бар да дию патшалыгыннан адәм үтмәсен өчен эшләнгән эшләр иде. Инде афәттән котылдың, өстемә менеп утыр да, мин сине бара торган җиреңә кадәр алып барыйм,— диде.

Шуннан соң ала айгыр, егетне атландырып, өч көн, өч төн барганнан соң, күп япан җирләр үтеп, бер бик зур ком тавына килеп җитте. Шунда җиткәннән соң, ат, егеткә таба карап:

— И минем дустым, юлдашым, инде мин өстемнән бурычымны төшердем. Миңа моннан ары барырга рөхсәт юк. Син инде өстемнән төш тә бу ком тавының аргы ягына чыгарга тырыш. Ул ком тавының артында Каф тавы, Каф тавының аръягында яман диюләр, усал арысланнар, аждаһалар яталар. Алар янына чыга алсаң, анаңны табарсың,— диде.

Егет моңарга күп рәхмәтләр укып, өстеннән төшеп, тау итәгендә калды. Алтмыш колачлы айгыр үз юлына китте.

Бу егет, азрак тамагын туйдырып, тауга менә башлады. Бераз менгән иде, ком ишелеп, янә түбән төште. Никадәр менәргә тырышса да, ком ишелеп, һичбер менә алмады. Бик арып-талып, күңеле тулып, анасын исенә төшереп утырганда, һавадан бер болыт кисәге төшеп килгәнен күрде дә куркып китте. Төшеп җитә башлагач, егет күрде: бу — бер кош, пырылдап әйләнеп, моның янына килеп төште дә:

— И егет, әйдә, минем өстемә менеп утыр. Мин сине бер җиргә алып китим,— диде.

Егет һавага менгәннән соң курка башлагач, кош:

— И дустым, син мин барында курыкма. Инде мин, сине бу ком тавына кадәр килгәндер дә анда менә алмый торгандыр дип кызганып, сәмруг кош сурәтенә кереп килдем. Мин күптәнге дустың Ак бүре. Мин сине хәзер Каф тавының башына илтеп куярмын, аннан ары барырга миңа рөхсәт юк. Үзең ничек булса да чыгарсың да анаңны табарсың,— диде. Аннан соң саубуллашып, очып кире китте.

Егет, тау башында бик күп ат вә адәм сөякләре күреп хәйран-вәйран булып торганнан соң, ике кулына ике ат сөяге алып, таяк итеп таянып, тауның бер ягына таба төшеп китте. Янә бер кечкенәрәк кенә тауга очрады. Тауның башына менеп караса, еректан бер ялтыраган нәрсә күреп, шуңа карап китте. Килеп җитсә, дөнья зурлыгында эшләнгән бер бакыр сарай булып чыкты. Егет, гайрәткә килеп, эчтәге кызларга сәлам бирде.

Бер бик сылу, кызыл битле, кара кашлы бер кыз, ишекне ачып, егетнең сәламен алды. Кыз егеткә:

— Ат килсә, тоягы көя, кош килсә, канаты көя торган җиргә син адәми зат булып ничек килеп җиттең?— диде.

Егет аңа каршы:

— Минем күп заманнардан бирле ашаганым юк, тамагым туйдыр,— диде.

Кыз моңа каршы:

— Минем абыстаем адәми заттан — диюнең хатыны. Мин аңардан рөхсәт сорап чыгыйм,— дип кереп китте.

Абыстай, кыз сөйләгәннәрне тыңлаганнан соң:

— Адәми зат булса керт, ашат, рөхсәт,— диде.

Кыз егетне абыстасы каршына алып килде. Һәм, төрле кош итләре куырып, егетне сый-хөрмәт итте.

Егет ашаганнан соң, абыстай, аның янына килеп: «Син кайдагы кеше, ни җирлек?»— дип сорады. Егет барын да сөйләп бирде. Сүзен: «Инде моннан соң кая барасымны үзем дә белмим»,— дип бетерде.

Абыстай аңа каршы:

— Бу сарайның иясе җиде башлы дию тугыз айлык юлга китте. Әгәр дә тиз көннән кайта алсаң, минем сараема сугылмый китмә,— диде.

Абыстай янә:

— Син анаңны тапкан шатлыгыңнан мине онытырсың. Онытмас өчен менә мин сиңа шул үзеңә ишек ачкан кызны никахлап бирим дә, ул монда калсын. Син дә, аны исеңә төшереп, минем яныма керерсең,— диде.

Егет, разый булып, инде мин бара торган җиремә барыйм дип, абыстайдан рөхсәт сорап, саубуллашып юлга чыгып китте.

Бакыр сарай буйлап өч көн, өч төн барганнан соң, бер көмеш сарайга килеп чыкты. Көмеш сарайның тәрәзәсеннән караган иде, кызларның, өстәлләргә салып, ит юып торганнарын күрде.

Янә гайрәткә килеп, ишеккә барып сәлам бирде.

Баягыдан да матур бер кыз, чыгып, моның сәламен алып:

— Адәми затмы син, пәри затмы син?— дип сорады.

Егетне бу сарайда да адәми зат — дию хатыны янына кертеп сыйладылар. Сораштылар һәм, кайтканда керми китмә, дип кисәттеләр. Монда да, керми калмасын дип, ишек ачкан кызны никахлап бирделәр. Моннан да саубуллашып чыгып китте.

Көмеш сарай буйлап өч көн, өч төн үткәннән соң күрде: бер бик зур алтын сарай янына бик зур вә матур итеп бакчалар корылган. Егет бу юлы да тәрәзәдән чибәр кызлар күрде, сәлам биреп кергәч, сәламен баягыдан да матур, бер бите ай, бер бите кояш кебек кыз килеп алды.

Егет ашарга сорагач, аны тагын адәми зат — дию хатыны янына керттеләр. Китергән кош итләрен ашап, эчемлекләрне эчкәч, егет, абыстайга карап:

— И абыстай, син кайсы шәһәрдән буласың? — дип сорады.

Абыстай моңа:

— Мин фәлән патшаның хатыны, фәлән шәһәрдән идем, мине урлап шушы дию бу җиргә алып килде. Минем дүрт

улым бар иде. Инде алар да үсеп, синең кадәр булганнардыр,— диде.

Егет аңа каршы:

— Улларыңнан берсе синең яныңа килсә, син аны таныр идеңме? — диде.

— Әлбәттә, таныр идем, кеше үз баласын танымыймы? — диде бикә.

— Мин синең улың булам. Мин фәләнчә айлардан бирле сине эзләп монда килеп җиттем. Аллага шөкер, синең нурлы йөзеңне күрдем,— дип муенына барып асылынды. Сорашып, шатлыкларыннан елаштылар.

Сүзләре тәмам булгач, абыстай улын бер сарайның ишеге төбенә алып килде дә алдан улын кертеп җибәрде. Егет сарайның уртасында биш йөз пот авырлыгында бер шар күрде. Анасы шул шарны егеткә алып чыгарга кушты. Улы шарны урыныннан да кузгата алмады. Шуннан соң анасы улына:

— Синең кавырсының да катмаган икән. Диюебез унике айлык юлга киткән иде. Китүенә инде ике ай булды. Тагын ун айсыз кайтмаячак. Диюнең шундый бер бакчасы һәм бер күле бар. Шул алма агачының алмасын ашап, күленнән су эчкән кеше дөнья йөзендә беренче батыр булачак. Син өч ай иркенләп шул агачтан алма ашап, күленнән су эч. Бу көйгә син батыр түгел әле. Сиңа ышанып юлга чыгарга ярамый,— диде.

Егет өч ай шунда ашап-эчеп ятканнан соң, анасы моңа шарны яңадан күтәреп карарга кушты һәм болай диде:

— Диюнең һөнәре шул иде: буш вакытларында шул шарны менә шул биек тауның башына ыргытып, шар төшкән чагында яңадан бер кулы белән тотып алып, һавага ыргытып җибәрә иде.

Егет шарны тау башына ыргытып, шар тәгәрәп төшкәндә, тотып алыйм дигәндә генә тота алмыйча, шар егетне бәреп егып, тагын да үз юлына китеп, тау итәгенә барып төште.

Егет, яңадан алма ашап, бакчада тора башлады. Ай ярым торганнан соң, анасы:

— И балакаем, инде тагын бер сынап карыйм, вакыт кыскарып бара,— дип, егеткә яңадан шарны ыргытырга кушты. Егет әлеге шарны ыргытып, шар төшкән вакытта бер кулы белән генә тотып, яңадан биек тауның башына сыңар кулы белән ыргытып җибәрде. Икенче кат тагын тотып алып, ыргытып җибәрде. Шулай итеп уйнаганнан соң, анасы улына:

— Инде хәзер көчең диюнеке белән тигезләнде. Дию аңсыздан кайтып керсә дә, көрәшерлек көчең бар,— диде.

Шуннан соң анасы, тагын бер сарайга алып барып, ишеген ачып, икәүләшеп шунда булган, һавада очып йөри торган бер зур иске машинаны алып чыгып, ватылган җирләрен төзәтеп, тузаннарын кагып, юлга китәргә әзерләп куйдылар. Сарайдан кырык бер кызны да, кәләшен дә үзләре янына утыртып, югарыга күтәрелеп киттеләр.

Киткән чакта егетнең анасы бер әфсен укып, алтын сарайларны һәм бакчаларны юк итеп, бер алтын күкәй итеп йомарлап, кесәсенә салды. Машина белән килгәндә кунак булып киткән көмеш сарайның турысына килеп җиттеләр. Егет, анасына карап:

— Әни, без бераз монда туктыйк әле. Монда минем тагын бер кәләшем бар. Аны да алып чыгарбыз,— диде.

Машинаны борып, көмеш сарайга килеп төштеләр. Ашапэчеп, ял итеп, бу сарайны, алтын сарайлар кебек, көмеш йомырка ясап, кесәләренә салып, эчендәге кырык бер кол кызны һәм үзенең хатынын да алып, тагын алга таба очып киттеләр.

Бакыр сарай турысына килеп җиттеләр. Бу чакта бакыр сарайның диюе кайткан иде. Болар килеп төшкәннән соң, каршы һичкем чыгып алмады.

Егет бакыр сарайның ишегеннән кереп китте.

Монда диюнең хатыны һәм кол кызлары үкереп елап каршы алдылар.

— Бәхетебез юк икән, диюебез кайтты. Җир астында фәлән сарайда йоклап ята. Тора калса, сине дә, безне дә үтерер,— диделәр.

Егет подвалның ишеген ачып кереп китте. Керсә, ни күрсен, дию, тугыз башын тугыз якка салып, бернәрсә белмичә, җәйрәп йоклап ята. Керүгә алмаз кылычын чыгарып, бер башын кисеп төшерим дигәндә генә, исенә килеп: «Тукта әле, йоклаган кешене кем дә үтерә. Мин моны уятыйм да көчемне сынап сугышып карыйм. Үлсәм, хак үлем булыр»,— дип, диюнең баш очына килеп бераз утырды. Дию һаман уянмады.

Соңра сарайга кереп, диюнең хатынына:

— Бар, диюне уят. Мин аның белән көрәшеп, сугышып, көчемне сынап карар идем,— диде.

Диюнең хатыны:

— Аны уята торган бер без бар. Син шул безне ал да табан астына кертеп бетереп бута. Шуны сизеп уяныр. Уянгач

та сиңа тәмле сүзләр сөйли башлар. Алданма. Ул бик хәйләкәр!— диде.

Егет, безне алып, диюнең бер табанына тыгып бутаган иде, дию бернәрсә дә сизмәде. Икенче табанына ныграк тыгып бутаган иде, дию уянды да, хатынына кычкырып:

— Адәми зат килгән икән. Нигә кунак итмисез?—диде.

Егет аңа каршы:

— Мин ач түгел. Мин синең белән сугышырга килдем. Тор, әйдә, чыгып алышыйк,— диде.

Дию бу сүзләргә гарьләнде. Торып урамга чыгып, алышырга тотындылар. Шулкадәр алыштылар ки, тигез җирләр түмгәккә, түмгәкле җирләр тигезлеккә әйләнделәр. Озак алыша торганнан соң, егет диюне күтәреп алып ыргыткан иде, дию тезенә кадәр җиргә батты. Дию сикереп торып егетне күтәреп бәргән иде, биленә кадәр җиргә батты. Егет күтәреп бәргән иде, дию бил тиңентен җиргә батты. Шулай итеп, нихәтле алышсалар да, берсе берсен җиңә алмады.

Соңра дию белән егет, сахрага чыгып, тагын алыша башладылар. Егет диюне күтәреп бер ыргытып бәргән иде, дию башларына кадәр җиргә батты. Шулвакыт егет, алмаз кылычын чыгарып, диюнең тугыз башын тугыз җиргә кисеп ташлады. Хатын һәм кызлар, бу хәлне күреп, егеткә күп рәхмәтләр укыдылар. Бу көнне дә күрәсебез бар икән, дип бик шатланыштылар...

— Менә инде күрәсез, бу дию ничә еллардан бирле никадәр кешенең башына җитте,— дип, сарайга кереп ашарга утырдылар.

Егетнең анасы:

— Монда инде бик озак тордык,— дип, машина белән югары күтәрелеп киттеләр...

Бераз көннәр яланда очып килделәр. Тагын бераз килгәннән соң, Ак бүре урманына килеп җиттеләр дә бер бик әйбәт аланга килеп төштеләр. Ак бүре боларның килгәннәрен белеп, ул да болар янына килеп җитте. Бик матур егет сурәтенә кереп, болар белән килеп күрешкән иде, бөтен кызның күзе ут булды. Патша улы, моның Ак бүре икәнен белеп, танышып-күрешеп, бик ныклап сыйлап, эчереп, Ак бүрегә карап:

— И дустым, Ак бүре, менә сиңа сүзем шулдыр: кызлардан үзегезгә ошаган берсен сайлап алыгыз, бу өчесен үзем алып кайтам, бу өчесен агаларыма багышладым, калганнарыннан сайла,— диде.

Бүре сайлап алганнан соң, кыз да: «Бигрәк матур егеткә туры килдем»,— дип, бик шатланды.

Соңра болар саубуллашып янә үзләренең шәһәрләренә очып киттеләр.

Юлда бер зур шәһәргә туры килеп, көмеш сарайның хуҗасы:

— Бу минем шәһәрем,— дип, егеткә күп рәхмәтләр укып, үз шәһәренә төшеп калды. Бу хатын шул шәһәрнең патша хатыны иде.

Янә аз гына очып барганнар иде, тагын бер зур шәһәр турысына килеп җиттеләр. Монда бакыр патша иясе төшеп калды. Егет, үзләренең теләүләре буенча, кызларның барысын да бу шәһәрдә калдырды.

Бу шәһәрдән озак бармадылар, үзләренең шәһәрләренә кайтып җиттеләр. Патшаның уллары боларны каршы алды. Патша хатынын өенә алып кайтты. Егет агаларына дигән кызларны да никахландырып, утыз көн, утыз төн туен ясадылар. Егет үзенең хатыны белән алтын сарайда утырып калды. Егет сараенда гаиләсе белән әле дә рәхәтләнеп тора, ди.

Сораулар һәм биремнәр

1. Моңа кадәр өйрәнгән башка әкиятләрне исегезгә төшерегез. Алар бар да бер-берсенә каршылыкта торган ике вакыйгага бүленә иде. «Ак бүре» әкиятендә дә шундый ике каршылыклы вакыйганы табыгыз.

2. Ике каршылыклы вакыйганы патша улының җиңүе белән бәйлик. Ул җиңүгә ничек ирешә?

3. Ике сорауга җавап биргәннән соң, әсәрнең темасын табып була. Темасын әйтегез. Бу әкият нәрсә турында?

4. Әкияттәге охшаш (кабатланып килә торган) вакыйгаларны табыгыз. Аларның уртак якларын һәм аермаларын әйтегез.

5. Патша улларының үз шәһәрләреннән чыгып киткәч озак барулары турындагы урыннарны табып укыгыз. Алар арасында аерма бар. Аерма әкиятнең авторларына нигә кирәк булган?

6. Бу әкияттә дә шаян кереш бар. Аның нигә кирәклеген әйтегез.

7. Айгыр, утларга, суларга, таш араларына кертеп, патша улын үтермәкче була. Ләкин соңыннан ала айгырның егеткә мөнәсәбәте үзгәрә. Ни өчен үзгәрә?

Хәкимҗан Халиков

Болытлар

Чыктылар да зәңгәр офыктан
Ак мөгезле кара болытлар,
Сөзештеләр — утлар атылды,
Күк гөмбәзе гүя ватылды.
Авырттымы әллә башлары,
Ник болытлар елый башлады?

Сорау һәм бирем

1. Бу әсәрнең нигезендә нинди әдәби алым ята?
2. Чагыштыруларны, метафораларны алып ташлагыз. Үз сүзләрегез белән чынлыкта ни булуын әйтегез. Аннан соң шул гап-гади вакыйганы шигырь белән чагыштырыгыз. Аермасын табарга тырышыгыз.

Зыя Мансур

Суык

Бүген көн бигрәк салкын шул, суык.
Чыпчыклар поса чормага, туңып.
Суык, суык!
Ап-ак бәс белән капланган чыбык.
Маэмайлар ята саламда, чумып.
Суык, суык!
Күл тоташ бозга әйләнгән, су юк.
Наратлар шартлап ярыла, туңып.
Суык, суык!
Ә урманчы туның сала, кызып.
Нишләп монда юк икән ул суык?
Кызык, кызык!

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне өлешләргә бүлегез. Бүленеш нигезендә яткан әдәби алымны табыгыз.
2. Охшаш урыннарны бергә җыегыз. Исем бирегез.
3. Ике өлеш үзара ничек бәйләнгән? Шул ук сорауны икенче төрле итеп бирик: әсәрдәге каршылык ничек югала?

Ибраһим Гази

Кояш артыннан киткән тургай

Туган-үскән авылымны сагынып, кунакка кайттым. Туган җирдәге бөтен нәрсә ник болай җанга бик якын була икән? Хәтта урам туфрагына басканда да күңелем тетри...

Беренче көнне үк малай чакта ат саклаган чокыр-чакырларны, җилкәләп утын ташыган урманнарны, суын эчкән инеш буйларын — яхшы-яман истәлекләре белән күңелдә калган урыннарның барысын да йөреп чыктым. Йөрмәгән тик Олы күл буе гына калды. Мин аны юри соңгарак калдырдым. Олы күл ерак. Анда барып кайту өчен, үзенә бер көн кирәк.

Әйтергә онытканмын, кызарып җиләк пешкән чаклар иде бу. Ашлыклар күкрәп үсеп торган чак. Бик матур чак. Кояш кызуы басыла төшкәч, мин, Олы күлгә барырга дип, юлга чыктым. Көн сүрелеп бетмәгән иде әле. Кечкенәдән үк бик таныш, бик күп тапкырлар атта да, җәяү дә чабып узган юл буйлап әкрен генә барам. Тузанның кайнарлыгы хәтта ботинка табаны аша сизелә... Кояш гүя эрегән һәм мենә-менә минем башка тамачак. Әлсерәп авызларын ачкан кара карга балалары мин бик якынайгач кына, анда да теләр-теләмәс кенә, канатка күтәреләләр дә, ерак та китмичә, яңадан төшеп куналар.

Барып җиткәч, балык сикерүдән җәелгән су алкаларына карап, төрле уйлар уйлап, чирәмдә бик озак утырдым. Малай чагында йөгереп йөргән җирләргә кире кайткан кешенең уйларга уйлары табыла инде.

Аннары күлне бер тапкыр әкрен генә әйләнеп чыктым. Аннары тагын иске урынга килеп утырдым. Инде озак утырылды бугай. Өйдәгеләр мине югалтканнардыр. Ләкин никтер кузгаласым килми: кайчан әле мин тагын кайта алырмын, утырып калыйм. Камышта тирбәлгән кечкенә генә сары кошка карап утырам да утырам.

Кояш үз юлы белән әкрен генә төшеп бара... Өлгерә башлаган бодай исе, татлы бал исе борынга керә... Рәхәт! Ә тургайлар кичкырын бигрәк тә котыралар икән. Баш түрымда сайрыйлар да сайрыйлар. Әллә инде бөтен безнең район тургайлары минем баш очыма җыелганмы? Гөрләшәләр генә... Мин, күккә карап, чалкан ятам. Чалкан ятып, тургай моңын тыңлыйм. Әнә берсе... Әнә икенчесе... түгәрәкләр ясый-ясый, һаваны бораулап менеп баралар. Мин аларны күздән ычкын-

дырмаска тырышып карап ятам. Колак төбендә: челтер-челтер, туррый-туррый, яй-яй...

Кояш бата, ахры инде. Күл буйларына дымлы караңгылык төшә башлады. Ә күк йөзе әле зәп-зәңгәр, яп-якты... Бигрәк тә кояш баешы ягы... Ә болытлар кып-кызыл... Баягынак кар тауларыдай өелеп торган ак болытларга кинәт ут капты, болытлар ялкынланып яналар...

Кояш иңгән саен, тургайлар күтәреләләр, күтәреләләр... Гүя кояштан аерыласылары килми, гүя кояш — аларның әниләре...

Мин бер-ике тургайны һаман күздән ычкындырмыйм. Алар инде миңа кичке тәрәзәдә йөри торган күбәләк кадәре генә булып күренәләр. Үзләре һаман менә, һаман менә... Вакыт-вакыт мин инде аларны күздән дә югалтам. Аннары тагын эзләп табам.

Җирдә инде күптән кояш юк. Ә югарыда бар әле. Күккә чәчрәгән соңгы кояш нуры тургай канатында кызарып чагылып китә. Әнә шулчакта инде мин югалган тургайны яңадан шәйли башлыйм.

...Күренер-күренмәс кенә булып лепердәп торган бер тургай кинәт җиргә таба егыла башлады: кояш артыннан ияреп барырга аның көче, күрәсең, җитмәде... Әнә ул, канатларын җыеп, таш кебек атылып төшеп килә...

Менә җир тургайга каршы сикерде. Мескен кошчык бәрелде, харап булды дип торганда гына, тургай канатларын җәеп җибәрде дә солы арасына әкрен генә килеп төште. Калган икесе әле һаман күтәрелә, һаман сайрый... Никадәр генә биек менгән булсалар да, моңлы җырлары әле һаман җиргә төшеп җитә: челтер-челтер, туррый-туррый, яй-яй...

Әнә тагын берсе егылып төшеп килә. Нәкъ борчак кыры турысына... Минем сикереп торасым, аны учыма тотып аласым килә. Менә мин сикереп аягыма бастым...

Талпындым... Бусы да, канатын җәеп җибәреп, әкрен генә борчак арасына төште.

Ә соңгысы? Әнә ул болыт таулары фонында кара нокта булып кына леперди. Ул әле һаман менә. Ул кояшны күрә булса кирәк. Ә җир инде кояшны күрми. Камыш ышыгында су өсте инде кап-кара. Ә камышлар инде йокыда...

Ә тургай, ялгыз тургай, һаман менә, һаман күтәрелә... Бәлки, аның әнисе кояштыр? Әнкәсеннән аерыласы килмичә, ул һаман югарырак, һаман яктыгарак менәдер...

Мин керфек тә какмыйча карап ятам. Күзләремне йомып кына алсам да, тургай инде югалачак. Кайда соң әле ул? Мин аны күрми башладым. Юк, юк, күрәм. Әнә ул, әнә... Тузан хәтле генә инде... Ә шулай да тавышы челтерәп агып тора...

Мин көтәм, менә ул канатларын җыяр да, иптәшләре кебек үк, җиргә таштай атылып төшәр. Җирдә яралган — җирдән аерыла алмас. Көтәм, ә ул һаман төшми. Ул һаман менә... һаман сайрый...

Мин инде аны күрмим. Юк, күрмим... Ә челтерәп аккан тавышын әле ишетәм. Ишетәм әле. Әллә ишетәм кебек тоела гынамы? Була ич шулай: җырчы җырлап туктаганнан соң да колак төбендә аның җыры беравык чыңлап ишетелеп тора...

Кая китте икән соң ул? Ник җиргә төшмәде? Ник бүтәннәр кебек, канатларын җыеп, түбәнгә атылмады? Әллә сайрый-сайрый кояш артыннан киттеме? Кояш артыннан... Әнкәсе артыннан...

Мин башымны артка ташладым да әллә ни гомер күккә карап тордым. Бәлки, ул бик югарыдыр, кояш артыннан барадыр? Тик минем күзләрем генә аны күрә алмыйдыр? Шулайдыр...

Кичке чыктан юешләнгән үләннәр өсләп, әкрен генә авылга таба атлый башладым. Атлыйм... Уйлыйм... Кояш артыннан киткән тургай хакында уйлыйм... Ә күлнең аргы башында, җәйге матур көнне котлап, бакалар кешнәшә...

ХИКӘЯНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Хикәянең темасын туган җиргә мәхәббәт дип атарга була. Анда, чыннан да, туган авылның матурлыгы турында язылган. Шуның өстенә туган авылы язучының хәтерендә гүзәл балачак, яшьлек булып саклана икән. Бу хикәя хәтердәге яшьлек хисләре белән бизәлгән туган як матурлыгы турында да.

Әмма хикәянең икенче өлешендә әдипнең игътибары күктәге бер ноктага туктала. Ул тургайлар турында сөйли башлый.

Гадәттә, тургайларның матур сайравы турында язалар. Ибраһим Гази да шулай итә. Аның тургайлары да бик матур итеп сайрыйлар. Ләкин, шуның белән бергә, әдип тургайларның моңа кадәр берәү дә язмаган бер гаҗәп матур сыйфаты турында сөйли. Алар кояшны мактап сайрыйлар һәм өзлексез кояшка таба очалар икән. Карагыз нинди бәйләнеш! Кояш баткан саен, тургайлар өскәрәк менәләр. Ә аларның канатларына кояш нурлары... ни эшләгән дип уйлыйсыз? Чәчрәгән! Менә ни эшләгән. Кояш нуры чәчри дип, метафора белән уйлый ала торган бик оста әдип кенә әйтә ала.

Ике тургай арып җиргә төшсә дә, берсе күтәрелә дә күтәрелә. Күпме генә күтәрелмәсен, җыры барыбер җиргә килеп җитә. Кая бара, кая оча соң ул күктә калган тургай? Кояш нурлары эзләп оча икән. Кояшның үзенә таба оча икән. Чөнки кояш — аның анасы. Һәрхәлдә, әдипкә шулай булып тоела.

Ә иң соңыннан Ибраһим Гази бака турында яза. Тургай сайрый, ә бака нишли? Кешнәшә.

Хикәянең эчтәлеген белү өчен, тургайның, күккә күтәрелеп, кояшка таба менүен, менә алмаса да, шуңа ышанып омтылуын һәм аңа каршылыкта торган бака вакыйгасын әдәби алым итеп карарга кирәк. Аннары кояшның, тургайның һәм бакаларның мәгънәләрен беләбез һәм хикәянең эчтәлеген табабыз.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хикәянең сюжетын сөйләгез.
2. Хикәядә кабатланган урыннар күп. Шуларның ни өчен кабатлануын аңлатыгыз.
3. Күрәсез, язучы, туган ягы турында сөйләгәндә, күзенә күренгән һәрнәрсәне мактамый. Бер генә күренешкә туктала да, шул күренеш аша туган ягына булган мәхәббәтен дә, фикерен дә әйтә. Тургай, уйлап карасаң, тургай да, шул ук вакытта тургай түгел дә. Бака — бака да, шул ук вакытта бака да түгел. Язучы сайлап алган күренешен (тургайларны) бакалар белән каршылыкка китерә, тургайлар, бакалар турында сөйләгән булып, үзенең кешеләр турындагы уйларын әйтә.

Сез дә, туган авыл яки шәһәр күренешләре эченнән нинди дә булса мәгънә чыгарлыгын сайлап, инша язып карагыз.

Салих Баттал

Бала

Өч көпчәкле велосипед
өстендә нәни бала.
Тәгәрмәче тешләрендә
чыра шытырдап бара.

Юри беркетелгән чыра
шытырдый мотор сыман!
Бара сабый, чын моторны
эшләткән батыр сыман.

Бала үсәр. Самолётта
очып йөрер күкрәп.
Моңар ышандыра мине
сабыйдагы чын йөрәк.

Тик шундый хәлләр дә була
гомер юлын узганда:
шытырдый — әйләнеп карыйм,
ләкин йөрәк юк анда.

Биремнәр

1. Шигырьдә вакыйга һәм аның мәгънәсе бар. Ике өлешкә ул шулай бүленә. Исемнәр куярга кирәксә: уен һәм мәгънәсе дип тә, самолёт моторы һәм кеше йөрәге дип тә бүләргә мөмкин. Ике өлешнең берсе — метафора. Бу шигырьнең эчтәлеге ничек табыла? Сөйләп бирегез.
2. Шигырьдә өч катлы мәгънә бар. Өчесен дә әйтегез.

Фәнис Яруллин

Туган ягы кирәк кешегә

Читтә йөргән чакта, сагындырып
Керер өчен төнлә төшенә,
Зәңгәр таңлы, биек аяз күкле
Туган ягы кирәк кешегә.

Зур уңышлар яулап, заманалар
Матур бәя бирсә эшенә, —
Шатлыкларын ишеттерер өчен,
Туган ягы кирәк кешегә.

Йөри-йөри күңле тупасланса,
Тузан кунса яшьлек хисенә,—
Бер сафланып килер өчен тагын
Туган ягы кирәк кешегә.

Яшәр өчен бетмәс көч алырга
Олысына һәм дә кечегә,—
Мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле
Туган ягы кирәк кешегә.

ШИГЫРЬНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Фәнис Яруллин шигырен кабатлау алымы белән төзегән. Һәр строфаның соңгы юлындагы кабатлауны эзләп торасы да юк. Ул үзе үк мин монда дип кычкырып тора. Ләкин кабатлау — кат-кат бер үк нәрсәне әйтү генә түгел ул. Бу шигырьдә әдип туган якның күркәм сыйфатларын санап чыга. Алар төрлеләр, ләкин барысы да — туган якның матур сыйфатлары. Сагынганда да, шатланганда да, күңеле тупасланса да, көч алу өчен дә кеше туган ягына кайта икән, димәк, бу сыйфатларның барысына да туган як йә дәва, йә юаныч була дигән сүз.

Алым табылгач, эчтәлекне бергәләп эзлик.

Сораулар һәм биремнәр

1. Кешенең шатлыгы зур булса, ни өчен туган ягына кайтырга кирәк? Дус-ишләре башка урында да юкмыни? Аларга да сөйләп була бит шатлыкны.
2. Фәнис Яруллин туган якка мәхәббәтле, ямьле, мәрхәмәтле дип бәя бирә. Шундый бәя биргәндә, ул нәрсәне күз алдында тота?
3. Шагыйрь туган якка кайту сәбәпләренең берничәсен генә әйткән. Ләкин кеше туган якларына башка сәбәпләр белән дә кайта бит әле. Шуларның берәрсен сайлап алыгыз һәм шигырьгә тагын бер строфа (куплет) өстәп языгыз.

Фәнис Яруллин

Тугры дус

Һич хыянәт итми торган
Бер дустым бар янымда:
Күңелем минем кимлек сизми,
Янда ул бар чагында.

Ул булганга, ил алдында
Кызармый минем йөзем.
Кая барсам — кадерем бар,
Сөйләсәм — үтә сүзем.

Ул булганга күңелем якты,
Офыкларым киң һаман.
Арысам да, авырсам да
Туя белмим дөньядан.

Ул — минем шатлык, юаныч,
Ул — минем зур горурлык.
Дөньяда һичнәрсә юктыр
Аңарга тиң булырлык.

Ул — минем тормыш тоткасы,
Ул — минем бетмәс көчем.
Тугры дустымның исеме —
Хезмәтем минем, эшем!

Бирем

Шигырь нинди алым белән язылган? Хезмәт ни өчен дустым дип бәяләнә?

Илдар Низамов

Теш үтмәгәч

Сөйләшәсе килеп көтеп торган диярсең, ике нарат арасыннан каршыма тып итеп чибәр бер гөмбә чыгып басты. Шундый да чуар, карап торуга шундый да сөйкемле иде үзе, тәкатьсез туктап калдым, хәтта баш кагып сәлам дә бирдем:

— Исәнме, гөмбә! — дидем.

— Исәнме! — диде ул да. Кыңгыр салынган кызыл эшләпәсендә борчак-борчак ап-ак тәрткеләр тагын да елтырап киткәндәй булды. Шунда мин үземне күптән борчып йөргән сорауны бирдем:

— Шундый матурсың, сөйкемлесең, нигә соң сине әшәке гөмбә диләр, исемеңне дә, мыскыллап, Чебен гөмбәсе дип кушканнар?

Гөмбә югалып калмады, чатнатып җавап бирде:

— Мине ашый алмыйлар. Ашарга маташып карап та булдыра алмагач, шундый мыскыллы исем кушканнар,— диде.

— Ашалмый торган башка гөмбәләр дә бар, берсенең дә исеме синеке кебек ямьсез түгел... Берсен дә Чебеннеке дип йөртмиләр.

— Әшәке гөмбәләр бар да нинди дә булса яхшы гөмбәгә охшарга тырышалар, ә мин берәүгә дә охшарга тырышмыйм,— минем үз йөзем, үз төсем. Йә әйт, бармы тагын миңа охшаган берәр гөмбә дөньяда?!

Мин телсез калдым.

Бирем

Автор хикәясен әйтәсе сүзен турыдан-туры әйтеп тәмамлый. Ул юлны без юри төшереп калдырдык. Автор ни белән тәмамлаган? Шул җөмләне үзегез язып куегыз.

Мостай Кәрим

Томау

Шәмсинур кодагый, кич ятканда, син дә мин иде. Авыз эчендә адашып йөргән догасын чак-чак кына кыймылдаган иреннәре аша тышка чыгарып бетерергә дә өлгермәде — җылы түшәктә сары май булып эреде дә куйды.

Иртән торгач, ул, бик моңлы итеп, өч мәртәбә төчкереп алды. Шуннан соң, самавырның суы беткәнче, тәмләп-тәмләп чәй эчте. Чәй эчкәч, борын эче кычыткандай итте. Ул янә ике мәртәбә төчкереп куйды. Үз-үзенә сәламәтлек тә теләп алды:

— Исәнлеккә-саулыкка, тазалыкка-байлыкка...

Бу иртәнге сәгатьтә шуннан артык вакыйгалар булмады.

Баллыбанат карчыкларга уймак сорарга дип кенә кергән Шәмсинур кодагый алда күрәчәкләре барын башына да китерми әйтеп куйды лабаса:

— Томаулап торам, ахры, Баллыбанат күрше...— диде ул, сүзләрен куәтләгәндәй, нечкә генә итеп янә төчкереп алды.

Баллыбанат бу хәбәргә һич тә коелып төшмәде.

— Томаулансаң, килененңнән кызу итеп мунча яктыр,— диде,— ике себерке парлат. Җаның уч төбенә җиткәнче, шулар белән алмаш-тилмәш чабын. Мунчадан кайткач, картыңнан калган теге толыбыңны ябын да баллап мәтрүшкәле чәй эч. Толып якаңнан гөжләп пар чыгып торсын. Бүген генә дөнья күргән кеше түгелсең лә инде. Үзең дә беләсеңдер.

Әңгәмә шуның белән тәмам да булыр иде, бәлки... Гөнаһ шомлыгына, сүзгә Баллыбанатның килене Гайшә кушылды:

— Минем каенанам консерватор ул. Җиһанга корабльләр очырган заманда мунча ташлары, каен себеркеләре, мәтрүшкәләр искерде инде, кодагый. Наданлык бу! Кешегә шундый киңәшләр бирергә оялыр идең, каенанам, чак кына. Пенициллин, аспирин, амбулатория, доктор... Менә нәрсә кирәк аңа!

Чынлап та, новатор килененең сүзләреннән оялып, хурлыгына чыдый алмый, Баллыбанат икенче бүлмәгә чыгып китте. Киленгә куәт биргәндәй, кодагый тагын да нечкәрәк итеп төчкереп җибәрде.

— Әнә минем сүземне үзең дә җөпләп торасың, кодагый,— диде новатор килен.— Сине хәзер үк медпунктка озатырга кирәк.

Гайшә урамга күз ташлады. Анда буш чанага аягүрә баскан үсмер малай Ишмырза атын юрттырып үтеп бара иде. Килен, тәрәзәгә кагып, Ишмырзаны туктатты. Ишмырза йөгереп өйгә керде.

— Өч чакрым арада атыңның алтыны коелып калмас, Ишмырза, менә Шәмсинур кодагыйны медпунктка илтеп килче, салмасалар алып ук кайт.

Ишмырза тыңламый булдыра алмады. Чөнки Гайшәнең ире Иштимер абый — бригадир. Ә Гайшә — бригадир хатыны.

Кодагыйның ике ягына ак халат кигән яшь кенә ике кыз утырып алган. Карчыкның сул култык астына градусник куйганнар, ахрысы. Уң кулы белән сул беләген бастырып тора. Шулай тотсам, тизрәк савыгырмын, дип уйлый ул.

Кызлар алмаш-тилмәш сорашалар:

— Ничә яшьтәсең?

— Алтмыш тугызда. Шөкер, җитмешкә дә аяк басабыз.

— Өегездә барысы да сәламәтләрме?

— Шөкер... Исәнбез. Йорт-җир төгәл. Мал-туар да исән генә кыш чыгып килә. Курмы булгач, чыга инде ул. Курмыны әйбәт бирделәр быел. Әйтер хәл юк, терлекләр көр кышлый. Бәрәннәр дә туп кебек тупылдап торалар. Ала сарыгыбыз быел өч бәрән китерде. Имин алай, бик имин...

Кара кыз чак кына елмаеп куя:

— Өегездә бәләкәч балалар бармы?— дип сорый ул.

Шулкадәр ах итеп хәл-әхвәл сорашуларына кодагый чиктән тыш канәгать. «Нинди тәрбияле, инсафлы, белдекле балалар...»— дип уйлый ул эченнән.

— Шөкер, итәк тулы. Баласыз өйдә кот буламыни ул! Ике улымның сигез баласы бар. Болай шугралар да... Ир балалар бит. Шулай да зарланыр хәлем юк, дәү әни, дип өзелеп торалар. Югыйсә әнә күрше Миндиярның балалары дәү әниләрен һич кенә дә санга сукмыйлар...

— Балачакта нинди чирләр белән чирләдегез, дәү әни?

— Телкәйләрең балдан-майдан өзелмәсен, балакаем. Бала чакларыма кадәр сораша бит, рәхмәтләр яугыры! Балачакта мин чирләшкә булмадым. Бик теремек идем. Җиде яшьтә җеп эрләдем, тугыз яшьтә киндер суктым. Мине кияүгә дә уйнап йөргән җиремнән генә тотып бирделәр. Сөйләмә инде ул заманнарны...

Ишмырза дәшмичә бер читтә утырып тора. Тик кодагыйга үзенең дөньяда барлыгын, тышта ат көтеп торганын белдерер өчен генә йөткергәләп куя. Әмма кодагый моңа игътибар итми.

Сипкелле кыз Шәмсинур әбинең култык астындагы градусникны алып карый.

— Нинди мәкерле, астыртын чир!— дип борчыла ул.— Хәтта температура да бирми — 36,9. Кай җирегез авырта соң?

— Буыннарым сызларга иткәндәй тора.

Кара кыз борынын җыерып куя:

— Мондый чирне без дәвалый белмибез шул, әби. Сине район больницасына җибәрергә туры килә.

— Башка чара юк,— дип җөпли сипкелле кыз.

Шәмсинур кодагый бәхәсләшеп тормый:

— Сез әйткәннән узып булмый инде. Сез укымышлы кешеләр бит,— ди ул,— юл йөрергә хәйран әвәсмен болай үзем. Әйдә! Ишмырза, дөнья күреп кайтыйк. Кышкы сахра — үзе бер тамаша ул.— Шулай дип әйтеп тә өлгермәде, ике алымга бүлеп, биш мәртәбә төчкереп тә алды. Башта өч мәртәбә төчкерде, аннан тагын икене өстәде.

Кодагый тунын киде, шәлен бөркәнде. Ишмырза күн бияләйләрен киеп, шапылдатып, бер-берсенә сугып куйды. Янәсе: «Без теләсә кайда барырга әзербез»,— димәкче инде. Үзе кызларга карап алган була.

Кызлар кодагыйга язу язып тоттырдылар.

Армактан чыккач, юл икегә аерыла. Уңга киткән юл районга бара. Очлы тактага «12 км» дип язылган. Сулга суктырганы — шәһәр юлы. Анысына «15 км» дип язылган.

Шушы юл чатында Ишмырза ала бияне шып туктатты.

— Кодагый,— диде ул,— өс-баш та ару гына, кесәдә калачлык акча бар. Әллә шәһәрнең үзенә үк җилдерәбезме? Аермасы — нибары өч километр. Ала бия өчен чүп кенә ул. Профессорның үзенә туп-туры барып керербез.

— Шәһәрнең юлы да такыррактыр... Адәм йөрмәгән җир түгел ләбаса.— Ала бия сулга тартылды.

Табиб кабул итә торган бүлмәнең ишек төбендә, култык астына градусник кыстырып, Шәмсинур кодагый һәм, ГТО значогын ялтыратып, гамьсез Ишмырза утыра. Аның бернәрсәгә дә исе китми, янәсе. «Күрмәгән шәһәрме?»

Шәфкать туташы кодагыйның яшен, кай җире авыртуын, элек чирләгән чирләрен, өй эчендәгеләрнең сәламәтлеген сораша. Шәмсинур кодагый һәр сорауга бәйнә-бәйнә җавап бирә. Күрше-күләнне, нәсел-ыруны да телгә алып үтә. Балалары турында сүз кузгалгач, ул бөтенләй җәелеп китә:

— Балалар таза ул. Монау кече оныгым Апкадыйр гына күзен бүсер белән изаланды...

Шәфкать туташы термометрны алып карый:

— 37,4. Чак кына эссегез бар, әби.

— Булыр шул. Әле юлда җил кагылгандай итте. Аркам чымырдап куйды.

Шәмсинур кодагыйны табиб чакыртты. Шәфкать туташы да аның белән керде. Ишмырза, ялгыз калгач, өй эченә тиз-тиз генә күз йөртеп чыкты. Әмма урыныннан кузгалмады. Шулай да, сары калай савытындагы тарагын суырып алып, чәчен тарап куймый чыдамады.

Кодагый байтак торды. Башта шәфкать туташы чыкты, аннан кодагый күренде. Карчыкны ишеккә кадәр табиб үзе озата килде. Табиб рус икән, ләкин башкортча да ару гына сукалый. Ишек төбендә баскан көе ул киңәшләр бирә...

ХИКӘЯНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Башкорт халкының яраткан язучысы Мостай Кәримнең бу хикәясен дә тулы килеш басмыйбыз. Башкортча ярыйсы гына сөйләшә торган рус табибның Шәмсинур кодагый белән сөйләшүен юри төшереп калдырдык.

Мостай Кәрим абыегыз — татар халкына да бик танылган, яратып укыла торган әдип. Аның «Айгөл иле» исемле пьесасы радиодан гына да әллә ничә мәртәбә яңгырады. Шундый тәҗрибәле язучы, билгеле инде, хикәяләрдә нинди алымнар кулланасын яхшы белә һәм әсәренең ахырын да безгә таныш алымны кулланып тәмамлый.

Сораулар

1. Мостай Кәрим хикәясен ничек тәмамлаган? Ягъни табиб Шәмсинур әбигә нәрсә дигән?
Ә әби аңа ничек җавап бирергә мөмкин?
2. Чыннан да, әбинең ничек җавап бирергә тиешлеген каян белеп була?

Билгеле инде, әби табиб сүзләренә җавап биргәндә, ул әйткәннәрдән дә файдалана. Әйдәгез әле, хикәядә катнашкан персонажларга бәя биреп карыйк. Табиб күренеп кенә китә. Аның башкорт телен бозыбрак сөйләү кебек үзенчәлегеннән башка бер үзенчәлеге дә юк.

Хәер, ул бит авыл шәфкать туташыннан күбрәк белә. Шуңа күрә ул әйткәнне кабатламаска тиеш.

Хикәядә Ишмырза ничек сурәтләнә? Ул аз гына мактанчык, аз гына кыланчык, җае чыккан саен үзен күрсәтергә тырыша. Ләкин бик әйбәт егет. Олы кешегә ярдәм итәргә тора һәм ярдәм итә дә.

Хикәя ахырында Ишмырза турында сүз бара икән, димәк, аның менә шул безгә билгеле сыйфатлары тагын бер кат күренеп китәргә тиештер. Мәсәлән, аны аз гына булса да рәнҗетсәләр, ул бик тиз үпкәли ала.

Ә Шәмсинур кодагыйның төп үзенчәлеге — ул беркатлы әби һәм сөйләргә ярата. Күрдегез бит, аңардан авыруы турында сорыйлар, ә ул сыерлары, азык, оныклары турында сөйләп ташлый. Табибка нигә кирәк аның сыеры һәм ул сыерның көр булуы. Әмма әби үзенең тормышы турында ихластан сөйли. Ул башкаларның да үзе кебек ихлас күңелле, кешенең шатлыгына шатлана белә торган кешеләр булуына

аз гына да шикләнми. Яхшы күңелле, шәфкатьле, рәхмәтле һәм сөйләргә ярата торган кеше табиб сүзләренә каршы ни әйтергә мөмкин?

Ә хәзер истә калдырыйк. Персонажларның үз-үзләрен тотуындагы үзенчәлеккә холык диләр.

Кешеләрнең үзенчәлекле холкы хикәяләргә генә түгел, хәтта хикәядән күпкә күләмлерәк повестьлар, повестьлардан да күләмлерәк романнарга да сюжет юнәлешен билгеләүче нигез була.

Кешенең үз-үзе белән каршылыкка килүенә дә (Нәҗипне искә төшерегез), кешеләрнең бер-берсе белән конфликтка керүенә дә күп очракта холыклары сәбәпче була. Тагын бер нәрсәне онытмыйк: кеше холкы — җирдәге иң катлаулы күренешләрнең берсе. Матур әдәбият шул катлаулы күренешне өйрәнергә бик күп көч түгә. Әгәр дә беренче биремгә җавап таба алмасагыз, әсәрне вакыйгаларга бүлегез. Баштагы берәр вакыйганың соңыннан мәгънәсен беркадәр үзгәртеп кабатланырга тиешлеген исегезгә төшерегез. Шуннан соң тагын беренче бирем турында уйланыгыз.

О' Генри

Соңгы яфрак

Хәзер сез искиткеч матур сюжет белән танышырсыз. Аны бөтен дөньяга иң оста хикәяче дип танылган инглиз әдибе О' Генри уйлап тапкан. Хикәянең сюжеты мондый.

Өч катлы кирпеч йортның иң соңгы катында ике дус кыз яши. Берсенең исеме Сью, икенчесенеке — Джонси. Алар икесе дә — рәссамнар. Бу йортның зур якты бүлмәсен рәсем ясау бүлмәсе итеп җайлаганнар.

Май аенда менә нәрсә була. Үпкә Чире исемле бер усал әфәнде, каяндыр килеп, шәһәр буйлап йөри башлый. Ул әле бер кешегә, әле икенчесенә кагылып үтә. Урамнан урамга бик җәһәт күчеп, ул уннарча кешенең башына җитә. Үпкә Чире атлы әфәнде әдәп дигән нәрсәне белә торганнардан түгел иде. Зәгыйфь, бәләкәй буйлы Джонси да бу карт, кызыл битле, авыр сулаучы әфәндегә каршы тора алмады. Әфәнде аны да егып салды.

Иртәләрнең берсендә борчулы табиб, куе ак кашларын сикертеп кенә, Сьюны башка бүлмәгә чакырып чыгарды.

Термометрның терекөмешен төшерә-төшерә, ул:

— Үзе бик яшисе килсә генә, ул исән калырга мөмкин. Ләкин өмет унга бер генә. Ә сезнең кечкенә туташыгыз гомере белән хушлашкан инде. Ни турында уйлый ул?— диде.

— Джонси дингез ярын ясарга хыяллана.

— Буяпмы? Юкны сөйләмәгез. Башка хәсрәте юкмы?

— Юк, табиб әфәнде, башка хәсрәте юк.

— Алайса, ул бик нык зәгыйфьләнгән. Бер генә мәртәбә үлү уеннан арынып, быел нинди күлмәк фасоны кияләр, дип сораса да, үлү ихтималы бишкә бер генә калыр иде.

Табиб киткәч, Сью, мастерскойга кереп, бик озак елады, аннары, күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, Джонси яткан бүлмәгә керде.

Джонси, күзләрен тәрәзәгә текәп, юрган астында беленер-беленмәс кенә булып ята иде. Ул зур күзләрен тәрәзәгә текәп саный да саный. Һәм кире якка саный иде.

— Унике, унбер, ун,— ди, аннары: тугыз, сигез, җиде,— дип төшә. Сью тәрәзәгә карады. Тәрәзәдән нибары каршы якның дивары һәм кирпеч йортка сыланып ук үскән үрмә гөлдән башка берни дә күренми. Ни саный ул?

— Ни санайсың, җаным?— дип сорады Сью.

— Алты,— диде ишетелер-ишетелмәс кенә итеп Джонси.— Хәзер алар бик тиз һәм күпләп өзелеп төшәләр. Моннан өч көн элек кенә алар йөзләп иде әле. Саный-саный башлар әйләнә иде. Хәзер санавы җиңел. Алтау гына калды. Әнә тагын бер яфрак өзелеп төште. Соңгы яфрак өзелеп төшү белән, мин үләчәкмен. Мин моны өч көн элек белдем. Ник, сиңа табиб әйтмәдемени?

— Беренче мәртәбә ишетүем. Юкны сөйләмә. Синең сәламәтләнүеңә карт үрмә гөл яфрагының ни катнашы бар? Табиб миңа, син тиздән терeләчәксең, диде. Тавык шулпасы эч тә йоклап ал. Мин кибеткә чыгып керим. Ит алып кайтыйм.

— Ит алма, кирәкми,— диде Джонси, тәрәзәгә карап.— Менә тагын бер яфрак өзелеп төште. Дүртәү генә калды. Минем соңгы яфрак төшкәнен күрәсем килә. Шуннан соң мин дә үләчәкмен.

— Джонси, күгәрченем, рәсемемне тәмамлаганчы гына күзләреңне йомып ята алмассыңмы? Яфракларга карамыйча гына. Пәрдәне төшерер идем дә, миңа яктылык кирәк.

— Рәсемеңне тәмамлагач әйтерсең,— диде агарып калган хәрәкәтсез Джонси.— Мин кәтә-кәтә арыдым инде. Уйлый-уйлый да туеп беттем. Минем үземне тотып торган дөньядан

аерыласым килә. Ычкынып китеп, яфрак кебек аска очып төшәсем килә.

— Йокларга тырыш,— диде Сью.— Мин Берманны чакырып керәм. Рәсемдәге алтын эзләүче кешене шуңа охшатып ясамакчы булам. Мин кергәнче селкенми ятарга тырыш.

Берман исемле карт түбән катта яши иде. Аңа алтмыш яшь күптән тулган иде инде. Ул да рәссам иде. Гомере буена үзенең иң гүзәл рәсемен ясарга җыенып, өмет итеп яшәде. Ләкин ясый алмады. Ике яшь рәссам кыз ул яшәгән йортка күчеп килгәч, карт үзен аларның сакчысы дип игълан итте.

Сью ишекне ачып керде. Карт бүлмәсендә егерме биш ел буена рәсем ясарга дип тарттырып куйган киндер тора.

Ул киндер шул гомердән бирле картның иң гүзәл рәсем ясаганын көтеп тора. Сью картка дустының каты авыруын, соңгы яфрак кебек бу дөньядан тиздән китеп бару ихтималын сөйләде.

— Ниндидер үрмә гөлдән яфрак төшкән өчен генә кеше үлә димени! Шундый мәгънәсезлекне беренче кат ишетәм. Юк, минем, алтын эзләүче булып, синең каршыңда басып торасым килми. Их нәни, мескен Джонси! Ярый, әйдә, яса үзеңнең алтын эзләүчеңне. Каршыңда басып торам! Шушы да булдымы шундый чибәр кызның авырып ята торган урыны. Юк, берзаманны мин барыбер үземнең иң гүзәл рәсемемне ясаячакмын. Без аны кыйммәт бәягә сатачакбыз, һәм мин сезне шул акчага барыбер моннан алып китәчәкмен. Күрерсең менә! Барыбер икегезне дә бу эт оясыннан алып китәчәкмен!

Алар өскә менеп бүлмәгә кергәндә, Джонси черем итеп ята иде. Икесе дә, тәрәзә янына килеп, карт үрмә гөлгә шомлы бер караш белән карап тордылар.

Урамда салкын карлы яңгыр ява. Берман, иске зәңгәр күлмәген киеп, йөзтүбән әйләндерелгән чәйнек өстенә утырды. Чәйнек — таш кыяны, ә карт алтын эзләүче дәрвишне алыштырырга тиеш иде.

Икенче көнне Сью бик иртә уянды һәм дусты бүлмәсенә керде. Джонси, тоныкк күзләрен зур ачып, тәрәзәне каплаган пәрдәгә карап тора иде.

— Күтәр әле, күрәсем килә,— диде Джонси.

Сью пәрдәне күтәрде.

Ни күзләре белән күрсеннәр! Шундый көчле җилдән, коеп яуган яңгырдан соң да яфракларның берсе һаман асылынып тора. Соңгы яфрак әле һаман куе яшел төстә, дөрес, аның

кыр-кырлары саргая башлаган, әмма ул әле һаман ботагына бик батыр бер кыяфәт белән ябышып тора.

— Бусы соңгысы. Мин аны төнлә төшәр дип көткән идем. Төшмәгән. Ләкин бүген барыбер төшәчәк. Ул төшкәч, мин дә үләчәкмен.

— Алла хакы өчен ул турыда сөйләмә. Әзрәк кенә булса да минем турыда да уйла,— диде, арыган башын мендәргә салып, Сью исемле кыз.

Ләкин Джонси аңа җавап бирмәде. Теге дөньяга китәргә җыенып беткән күңел башкалар хәленә керә алмый. Тормыш белән кешеләр арасын бәйләп торган җепләре өзелә барган саен, аның аңын бәйләнчек уе күбрәк били барды.

Көн үтте. Ләкин хәтта кичкә таба да соңгы яфрак ботагында эленеп тора иде. Төнлә җил тагын күтәрелде, тәрәзәгә яңгыр тамчылары бәрде.

Таң ату белән, Джонси тагын пәрдәне күтәрергә кушты.

Яфрак һаман өзелмәгән иде.

Джонси аңардан күзен ала алмады. Аннары дустын чакырды.

— Мин кире беткән бер юньсез кыз,— диде Джонси.— Мөгаен, теге соңгы яфрак минем нинди юньсез булуымны күрсәтер өчен эленеп калгандыр. Хәзер миңа бераз тавык шулпасы бирсәң була. Аннары сөт эчәр идем. Хәер, башта көзге китерсәң иде. Аннары кырыма мендәрләр тезеп чык. Аш пешергәнеңне карап торасым килә.

Ә бераздан ул:

— Беләсеңме, Сьюди, мин диңгез ярын барыбер ясаячакмын,— диде.

Көндез аны табиб килеп карады һәм озата чыккан Сьюга:

— Хәле яхшыланган. Яхшы тәрбия булганда җиңеп чыгачаксыз. Ә хәзер мин астагы башка авыру янына төшәм. Ул да үпкә авыруы белән авырый. Карт кеше. Хәле бик авыр. Терелүенә һичнинди өмет юк. Аны бүген шифаханәгә алып китәчәкләр. Анда аңа тынычрак булыр,— диде.

Икенче көнне табиб Сьюдига:

— Тәки җиңеп чыктыгыз. Хәзер яхшы аш белән беркадәр игътибар гына кирәк булачак,— диде.

Шул ук көнне кичен Сью дустын мендәре-ние белән кочаклады да:

— Сиңа бер хәбәр әйтмәкче булам, сөеклем,— дип сүз башлады.— Берман әфәнде бүген шифаханәдә үпкә авыруыннан

үлде. Ул нибары ике генә көн авырды. Беренче көнне аның бүлмәсендә аңсыз ятуын швейцар күргән. Идәндә яткан булган. Аяк киемнәре дә, өс киемнәре дә шабыр су, боз кебек салкын булган. Шундый төндә аның урамга чыгып кая баруын берәү дә күрмәгән. Аннары әле һаман да янып торган фонарен, диварга терәлгән баскыч астында чәчелеп яткан яшел, сары буяуларын, рәсем ясый торган пумалаларын тапканнар. Тәрәзәгә, андагы соңгы яфракка җентекләбрәк кара. Сиңа аның җилгә селкенмәве гаҗәп тоелмадымы? Шулай, сөеклем, Берман картның иң гүзәл рәсеме — шул яфрак.

Ул аны үрмә гөлнең соңгы яфрагы очып төшкән төнне ясаган.

ХИКӘЯНЕҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Сүзне сюжеттан башлыйк. Шундый кыска хикәядә берберсе белән кисешә торган ике сюжет бар. Беренчесендә яшь рәссам кыз язмышы, икенчесендә карт рәссам язмышы турында сөйләнә. Соңыннан ике рәссам язмышлары бөтенләй көтелмәгән вакыйга булып кисешәләр. Ә сюжетларның эче тулы каршылык. Кайсы сюжет, кайсы хикәянең төзелеше икәнлеген белә дә алмассың.

Сюжет сызыклары үзләре үк каршылыкта тора. Каршылык мондый: кыз үләргә әзерләнеп беткән, ясыйсы килгән рәсемен ясамаска карар кылган. Карт рәссам, киресенчә, әле һаман үзенең иң гүзәл рәсемен ясаячагына өметләнеп яши. Рәссамнарның берсе чирле, берсе сәламәт, берсе яшь, берсе карт.

Ә төп каршылык әсәрнең төзелешендә. Беренче өлештә яшь, чибәр кыз соңгы яфрак өзелгәнне көтеп ята. Соңгы яфрак төшүгә үләчәкмен, дип ышана. Икенче өлеш шуның нәкъ киресе була: чирле кыз үлми, киресенчә, яфрак ясаган карт үлә. Ә шул вакыйгаларның барысы да үзәк образга килеп бәйләнәләр. Бөтен хикәяне җыеп торучы төп образ — соңгы яфрак. Ул үзе — коеп куйган каршылык. Чөнки соңгы яфрак бер үк вакытта бар да, юк та.

Әйдәгез, яфракка аерым тукталыйк. Әгәр дә бөтен вакыйганың җепләрен үз кулында тота икән, ул безгә хикәянең эчтәлеге турында да сөйләмәсме?

Яфракта кыз язмышы бар. Кызның өмете дә, өметсезлеге дә — шул соңгы яфракта. Яфрак төшсә — кыз үлә, калса — яши. Ләкин шул ук яфракта карт рәссам язмышы да бар. Ул бит гомере буена иң гүзәл рәсем ясарга җыенып йөри.

Шул өметен бөтен яшәешенең мәгънәсенә әйләндерә. Яфрак карт рәссам өметенең тормышка ашуы булып чыга. Яфрак ясауга ул үзенең бөтен осталыгын, гомере буена җыеп килгән мәхәббәтен сала. Бөтен гомеренең төп максатына ирешү өчен, ул вакытын да, гомерен дә кызганмый. Нәрсә ясый соң рәссам карт? Нибары бер яфрак кына ясый бит! Шул буламы иң гүзәл рәсем?

Әмма бу яфрак яшь кыз гомерен саклап кала. Хәзер яфрак рәсем генә түгел, хәзер ул чиксез зур игелекне, изгелекне алмаштырып килә. Символга әйләнә. Яфрак картның, үз гомерен корбан итеп, яшь кыз гомерен саклап калуы турында сөйли.

Хикәядә карт рәссамның кырыс, усал, хәтта еш кына салгалый да торган кеше булуын беләбез. Әмма яфрак безнең беренче тәэсирне юкка чыгара. Нечкә күңелле, шәфкатьле, кеше хәленә керә белә торган кеше икән безнең ул карт. Өстәвенә ул бит әле — үзенең һөнәренә гашыйк булган кеше. Рәссам буларак ул хәзер үзенең яраткан һөнәренә дә хезмәт итә. Яшен яшәгән уңышсыз рәссамны — үзен корбан итеп, яшь, өметле рәссамны исән калдыра. Соңгы яфрак хикәянең шундый эчтәлеге турында да сөйли.

Биремнәр

1. Бик матур хикәя укыдык. Аның кып-кыска булуын, ләкин эчендә дүрт персонажның кысанлыкка тарсынмыйча катнашуын күрдек. Алар арасыннан төп персонажларны сайлап алыгыз. Ни өчен нәкъ менә сез сайлаганнары төп персонаж булуын исбат итегез.

2. Хикәядә төп персонажларның төс-кыяфәтләре дә, ни өчен ялгыз яшәүләре, ничек яшәүләре турында да әйтелмәгән. Һәркайсының берәр генә сыйфаты ачылган. Ләкин алар — персонажларның холкы булырлык даими сыйфатлар. Мәсәлән, Джонсиның ихтыяр көче юк... Калганнарның холкын әйтегез.

3. Джонси алтын эзләүче кешене Берман картка охшатып ясамакчы була. Хикәядәге вакыйгадан соң, ул Берман картны ничек ясарга мөмкин?

4. Безгә хикәядәге матурлыкны табарга кирәк. «Кайда ул?» дигән сорауга сез, карт рәссамның холкы матур, диячәксез. Матур кеше, — әлбәттә, карт рәссам. Ул бик матур, чөнки кешеләрнең иң күркәм сыйфаты — шәфкатьлелек, мәхәббәт. Картта бу сыйфатларның икесе дә бар. Яшь рәссам да матур, диярсез. Шулай да булсын, ди, яшь рәссамның дусты да матур, ди. Тагын, ә тагын матурлык бармы? Бар. Табыгыз шул матурлыкны.

Тоткын Сөембикә җыры

(Халык иҗаты)

Ничә еллар бу бинада
Ялгыз утыра башым,
Бер савыт су,
Бер телем икмәк —
Минем ашаган ашым.

Күрмәмештер ике күзем
Якты дөнья йөзине,
Көне-төне елый-елый
Бетте инде күз яшем.

Хәсрәт утының сөреме
Каплады күзләремне,
Ут кабынган йөрәгемә,
Тышка да чыга аһым.

Кая китте яшь вакытым,
Назлы үскән чакларым?
Йөз мең алтын торыр иде
Минем атланган атым.

Чыга торган идем ауга,
Башыма таҗлар киеп;
Инде таҗ урынына калды
Бу озын кара сачем.

Аһ, насыйб булырмы миңа
Якты дөньяны күрү?
Әллә бу зиндан эчендә
Чыгармы газиз җаным?

Хәтфә кебек яшел булып
Тора микән җир йөзе,
Яндырып бетердеме әллә
Аларны да дошманым?

Бакчаларда сандугачлар
Сайрый микән әле дә?
Әллә аларны да тоткын
Итте микән дошманым?

Чорнала иде як-ягым
Кәнизәк кызлар белән;
Һәрвакытта да баш вәзир
Янымда иде юлдашым.

Алтыннар илә бизәлгән
Иде минем тәхетем,
Инде тәхетем булды хәзер
Шушы утырган ташым.

Бәеттәге лирик герой Сөембикә белән танышыйк.

Сөембикә — тарихи шәхес. Ул XVI гасырда яшәгән. Ире Сафагәрәй шул заманның Казан ханы булган. Ире үлгәч, хан хатыны Казан дәүләте белән үзе хакимлек иткән. Ләкин аның хакимлеге озак бармаган, Казанны рус патшасы Иван Грозный гаскәрләре камап алган. Казан егетләре яулап алучылар белән батырларча сугышалар. Әмма көчләр тигез булмый. Казан Кремлен шартлатып, Иван Грозный гаскәрләре татарларны җиңә. Казан ханы Сөембикәне Мәскәүгә озаталар һәм аны Шаһгали исемле кешегә көчләп кияүгә бирәләр. Чибәрлеге белән Казан ханлыгында гына түгел, тирә-юньдә дә дан казанган Сөембикә рус патшасына татарларны җиңүдә булышкан Шаһгали белән яшәргә теләми. Шуның өчен Шаһгали аны төрмәгә яптыра.

Коллыкка төшкән татар халкы дәүләт булып яшәгән заманын сагынган. Сөембикә язмышында үз язмышын да күргән. Аны чын күңелдән кызганган. Шуның өчен Сөембикәгә багышлап шушы җырны чыгарган. Казанда Сөембикә манарасы дип йөртелә торган бик матур, биек борынгы манара бар. Манараның исеме Казан ханы Сөембикә исеме белән бәйле. Аны, имеш, Сөембикәнең ире Сафагәрәй хан яраткан хатынына багышлап салдырган.

Биремнәр

1. Халык җырларын ничек тарката идек, исегезгә төшерегез.
2. Хис күрсәткән урыннарны табыгыз, хиснең эчтәлеген әйтегез. Аларны бергә җыегыз һәм барысына да гомуми исем бирегез.
3. Бәеттәге кичереш сәбәпләрен табыгыз.

Җибәрәсем килми җанымдин

(Халык җыры)

Йөгереп ләй кердем өйләргә,
Киемемне элдем чөйләргә;
Сез туганнарым килеп кергәч,
Ямьнәр керде безнең өйләргә.

Чакырып алдым чакрым ярымдин,
Җибәрәсем килми янымдин.

Өстеңә лә кигән күлмәгеңне
Әллә сабын белән юдыңмы?
Кашкайларың кара, буең зифа,
Әллә җомга көнне тудыңмы?

Яуса иде яңгыр, әй, яуса иде,
Кыеклардан тамчы тамса иде;
Әлегәй дә лә бергә без йөрибез,
Тагы да йөрешергә язса иде.

Бу җыр без моңа кадәр өйрәнгән җырлардан нык аерыла. Ләкин бу аерымлык — эчтәлек аерымлыгы гына. Лирик җыр буларак, бу җыр да без белгән алымнар ярдәмендә өч өлешкә таркала.

Биремнәр

1. Җырны өч өлешкә таркатыгыз.
2. Лирик герой хисен әйтегез.

Югалган башмак бәете

Һәркемгә бер килгәнгә, язмышы шул булганга,
Бер кайгы да күрерсең, түзмәенчә ни чара.

Берәүнең баласы юк, берәүнең булса да шук,
Шуклыгыннан тагын тук, түзмәенчә ни чара.

Кемнең баласы үлә, кемдин дошманы көлә,
Кемнең кесәсе бөлә, түзмәенчә ни чара.

Кайсы белми сабагын, кайсы җуя башмагын,
Дөньяда торыш шулай, түзмәенчә ни чара.

Сиңа зур кайгу булган, башмакларың югалган,
Артыгы мөмкин түгел, түзмәенчә ни чара.

И ул башмак дигәнең, рәхәтләнеп кигәнең,
Бигрәк килешә иде, ләкин җуйдың, ни чара.

Юкәдән иде бите, сырлаган иде чите,
Бик тыгыз үргән иде, югалды шул, ни чара.

Башы бик очлы иде, күтәрергә көйле иде,
Көймә су ерткан кебек, карны ерта, бичара.

Сөян иде табаны, гизәр иде япанны,
Армас, ялыкмас иде, югалды шул, бичара.

Эче бик шомартылган, биле бик юкартылган,
Җиңеллек күзәтелгән, югалды шул, бичарам.

Биле бик беркетелгән, чөе тәмам кертелгән,
Бер-берсенә тиң килгән, югалды шул, бичарам.

Үкчәсе биек иде, тирәлектә киң иде,
Юрга ат кебек иде, югалды шул, бичара.

Сиңа күп хезмәт итте, бик күп елларга җитте,
Күп рәхмәтләр ишетте, югалды шул, бичара.

Бик яхшы атлар кеби, кыйммәтле затлар кеби,
Мәгәзиндә тора иде, югалды шул, бичара.

Капка яхшыябылган, тимер йозак салынган,
Ачкыч янга эленгән, югалды шул, бичара.

Тупсасыны ватканнар, мәгәзинне бушатканнар,
Башмакны алып качканнар, югалды шул, бичара.

Арзан шәйне хурлыйлар, кыйммәтлене урлыйлар,
Кадере афәткә сәбәп, югалды шул, ни чара!

Бу бәет тә — үзенчәлекле бәет. Аның эчтәлеге дә кайгы кебек. Кайгының сәбәбе дә югалту, аерылу. Шулай булгач, монда да, лирик шигырьләрдәге һәм җырлардагы кебек, өч өлеш бар. Ләкин шул ук вакытта бәет лирик бәет түгел. Нинди бәет? Анысын анализ нәтиҗәсендә беләчәкбез.

Сораулар һәм биремнәр

1. Бәеттә катнашучылар ничәү? Кемнәр алар?
2. Башмак югалтучының кайгысы зурмы? Кайгы дәрәҗәсен күрсәткән урыннарны табып исбат итегез.
3. Кайгының сәбәпләрен табыгыз. Алар ничә төрле?
4. Әсәрнең бөтен өлешләрен җыеп торган төп алымны табыгыз.
5. Бәеттә кабатлаулар күп. Аларның әһәмияте бармы?

Зыя Мансур

Умырзаялар

Чылтырап кинәт,
Өй артларында
Уала тамчы-боз —
Әйләнә онга.

Ә уйнап, көлеп,
Яр буйларында
Умырзаялар
Чыга җыенга.

Шәп түгел, димәк,
Кышның эшләре.
Коела аның
Соңгы тешләре...

Сораулар

1. Шигырьнең беренче өлешендә сүз кыш турында бара. Икенчесендә яз күренешен күзәтәбез. Моңа кадәр танышкан шигырьләрдәге кебек җансыз табигать бу әсәрдә дә кеше белән чагыштырыла. Кыш белән кешенең нинди охшаш яклары бар? Бу шигырьдә шуларның кайсы алынган?
2. Яз кешеләргә кайсы ягы белән охшаган?
3. Бу охшатулар авторга ни өчен кирәк булган?

Муса Җәлил

Кышкы шигырь

Кар —
Әйтерсең ап-ак кәгазь;
Теләсәң шигырь,
Теләсәң җыр яз.
Нур каләмен кулына тотып
Чыгып баскан шагыйрь кояш.
Кыш иртәнге җиле белән
Карны сөрә җиңел генә,
Нурга төренеп, карлар оча,
Бу, ичмаса, шигырь менә!..

Аны зәңгәр урман укый,
Бөдрә карлы кырлар укый.
Чыршы кызы җырлап утыра,
Ә күрәсең, ул да укый.
Яшел бәрхет күлмәк кигән,
Итәкләре җиргә тигән.
Беләм, беләм,
Кояш менә
Шушы чыршы кызын сөя.

Сораулар һәм биремнәр

1. Автор кышның кояшлы көнен ничек күрә? Шигырьне үз сүзләрегез белән сөйләгез.

2. Кояш язган шигырь нәрсә? Шагыйрь аны ни өчен «шигырь» ди?

3. Лирик геройның кисе турында сөйләгез.

Мәҗит Гафури

Гомерем йомгагы

Җыеп караганда, алай бик зур
Төсле түгел гомерем йомгагы.
Сүтеп караганда, чак күренә
Аның бер ягыннан бер ягы.

Бирем

Әсәргә анализ ясагыз. Аннан соң мондый сорауга җавап бирегез: шигырен язганда авторга илле яшь тулган, дип уйлыйк. Илле

яшьне ничек сузарга мөмкин? Күпме сузсаң да, аңа шул ук илле яшь булмыймыни?

Равил Фәйзуллин

Яңгырдан соң

Чиләк-чиләк
Эре яңгыр
Явып үтте.
Җиребезне
Саф һавага
Күмеп китте.

Кояш чыкты,
Болытларның
Читен ачып,
Җиде төрле
Буй сөлгесен
Иңгә асып.

Бирем

Шигырь әчтәлеген рәсемгә төшерегез. Анда катнашучыларның барын да ясарга тырышыгыз.

Сибгат Хәким

Көз

Көз. Яфраклар коела урманда.
Нәрсәдер бар бүген, күр анда.
Нинди әмер кинәт кубарга,
Очлы таяк тотып кулларга.

Нишләп йөри икән минёрлар —
Вәсиләләр белән Мөнирләр?
Карый алар, карый һәр төпне,
Чистарталар гүя Харьковны.

Әзли-әзли әчкә керәләр,
Бу минёрлар нигә көләләр?
Җылы матур булса көн әгәр,
Төртеп чыгып тора гөмбәләр.
Иртәгә дә әле килерләр,
Йөри бирсен мондый минёрлар.

Сораулар һәм бирем

1. Автор хисе турында сөйләгез.
2. Ни өчен Сибгат Хәким гөмбәчеләрне минёрлар дип уйлый?
3. «Җылы матур булса көн әгәр, Төртеп чыгып тора гөмбәләр» сүзләренең башка мәгънәсе була аламы?

Гомәр Толымбай

Буран

Урамда буран,
Мин өйдә торам.
Тәрәзә аша
Тик авыз ерам...

Мичләр ягылган,
Өйләр җылынган.
Тиздән яз килер,
Кирәгең бирер!

Биремнәр

1. Әкият алымын хәтергә төшерик. Анда баштагы вакыйга үзенең киресенә әйләнә, дидек. Шигырьдә сөйләгәннәрне баштагы вакыйга дип алыгыз һәм, әкият алымын файдаланып, аны киресенә әйләндерегез. «Буран» шигыренең дәвамын шигырь итеп тә, сөйләм теле белән дә яза аласыз. «Кирәгең бирер!» җөмләсенең кире мәгънәсен файдаланырга тырышыгыз.
2. Яз кышның кирәген бирер, ди өйдә утырган авызы ерык малай. Шул сүзләрне рәсемдә ничек ясар идегез? Ясап карагыз.

Муса Җәлил

Чишмә җыры

Тау астында җырлап чишмә ага,
Камышлыкка кереп югала.
Татлы суы, дәртле җыры белән
Гөлчәчәкле җирне сугара.

Җир яшәрә аның суын эчеп,
Ак каеннар яфрак яралар.
Таң алдында аның җырларыннан
Сандугачлар канатланалар.

Теләр идем мин дә гомерем юлын
Чишмә төсле җырлап үтәргә.
Җырым белән җирне сугарырга,
Күңелләрне бакча итәргә.

Биремнәр һәм сорау

1. Шигырьдәге төп алымны табыгыз. Өлешләргә бүлегез. Ике өлешкә исем бирегез.
2. Чишмә сыйфатларын лирик герой теләкләренә кушыгыз. Нинди нәтиҗә ясарсыз?

Фатих Әмирхан

Балалар атавы

I

...Бара-бара торгач, бөтен төркемебез белән без бер диңгез янына килеп җиттек. Безнең төркемемездә миннән башка бер ир бала, дүрт кыз бала бар иде.

Бу диңгезнең зурлыгы искитәрлек, матурлыгы таңга калырлык, киңлеге очсыз-кырыйсыз булып, чит-читләре күкнең җиргә килеп тоташкан төшенә хәтле сузылган шикелле күренә иде. Аның яшькелт-күгелҗем саф суының эчендә йөзә торган алтын канатлы балыклары, аның төбендәге төрле төскә кереп елкылдый торган энҗе кашыклары, яр читенә килеп җиткәч тә, безнең күзгә аермачык күренә башладылар. Аяз күкнең нурлы кояшы диңгезнең өстенә алтыннар коя, су өстенә сирпелеп китә торган акрын вә тыныч җылы җил, кечкенә-кечкенә тулкынчыкларны яр буендагы мәрмәр ташларына китереп бәреп, алардан якут шикелле нурлы тамчылар аера, энҗе шикелле ак күбекләр чыгара иде.

Без яр буена килеп туктаган бер кечкенә пароходчык янына җыелдык. Бу пароходчык шулкадәр матур һәм шулкадәр кечкенә иде ки, ерактан караган кеше, аны асылташлардан ясалган уенчык пароход дип уйлап, күзен аннан ала алмый торырлык иде. Аның кечерәк кенә, чикләвек агачыннан эшләнгән гаять таза, ләкин бик җиңел көпчәкләре, зуррак буйлы бала озынлыгындагы көмеш морҗасы кояш нуры белән ялтырап торалар. Аның кечкенә генә ефәк әләме җем-җем итә, әләм эленгән сап-сары камыш таяк өстендәге кечкенә генә җәүһәр ташы елкылдап тора иде...

Пароходка якынрак баргач, без аның әләменә «Исмәгыйль баба Гаспринский» дип язылган икәнен күрдек. Шул ук исем кечкенә-кечкенә алтын хәрефләр белән пароходның төрле җирләренә язып куелган иде. Бу исемне күргәч, без пароходчыкның үз пароходымыз, татар пароходы икәнен аңлап алдык та, аның эченә кереп йөреп чыкмакчы булдык. Пароходчыкның эче дә, билгеле инде, зур түгел иде. Алай да, безгә күпме кирәк соң? Безнең иң олуг дигәнемезнең буе әле ике аршынга[1] ничек кирәк алай гына тулырлык иде. Кечкенә

---

[1] *Аршын* — 71 см.

вә матур бу пароходчыкның эче тышыннан да матуррак булып чыкты. Бөтен диварлар кыйммәтле асыл[1] белән кагылган, бөтен кечкенә-кечкенә утыргычлар әгъла[2] хәтфә белән тышланган, өстләренә ефәк дәстәрханнар[3] җәелгән бөтен өстәлләр дә кыйммәтле кызыл агачтан гына ясалганнар иде.

Өстәлләрнең берсе өстендәге алтын тышлы бер дәфтәр безнең барымызның да күземезгә чалынды. Аның өстенә: «Пароход эченә кергән балалар карасын өчен» дип язып куелган иде. Бу язуны укыгач, билгеле инде, без барымыз да дәфтәргә ябырылдык һәм аны ачып укый башладык. Аның әүвәлге битендә болай дип язылган иде:

«Сезнең теләгәннәрегезне бу пароход Балалар атавына илтәчәктер. Ләкин ул атауга барырга теләгән һәр бала төрки кабиләләре сөйләшә торган шивәләрнең[4] берсе белән сөйләшә, укый һәм яза белгәне өстенә, хисап, җәгъръәфия һәм шул кабиләләрнең тарихын бик яхшы укыган булырга тиештер. Барачак җирегездә һәркем үз өлешенә төшкән эшне үзе эшләп торадыр. Шуңар күрә кешегә ышанып торырлык ялкау балалар бармасыннар, ата-аналарын сагынып еларлык балалар да юлга чыкмасыннар!»

Моны укыгач, без бер-беремезгә карашып бераз тордык та, кинәт барымыз берьюлы:

— Ни эшлимез? Барамызмы?— дип кычкырышып җибәрдек.

— Барамыз!— дидем мин.— Без барымыз да татарча сөйләшә дә, укый да, яза да белгән өстенә, хисап, җәгъръәфия һәм татар тарихын да беләбез бит!

— Беләбез, беләбез!— диештеләр минем иптәшләрем.

Тик Гомәр генә, бераз аптырап:

— Мин тарих укымаган идем шул,— диде, аның күзләренә яшьләр килгән иде.

Гомәрнең бу сүзе бетүгә, арада иң кечкенәбез булган Сара да бару тугрысында уйга калганлыгын белгертте:

— Әнине сагынмый чыдый алмам шул мин!— диде ул.

— Алай булгач, сез икегез каласыз, Гомәр Сараны өенә озатып куяр,— диештек без.

---

[1] *Асыл* — кыйммәтле тукыма.
[2] *Әгъла* — бик яхшы.
[3] *Дәстәрхан* — ашъяулык.
[4] *Шивә* — диалект, җирле сөйләм.

Алар кайтып киттеләр, без, калган сигез бала, алар аркылы ата-аналарыбызга сәламнәр җибәрдек.

II

Мин иптәшләрем арасында җәгъръфиягә остарак хисаплана идем; шуңа күрә аларның сайлавы буенча, мин пароходка капитан булдым. Үзбәк арамызда машиналар белән булышырга сөя торганыбыз иде. Ул, пароходның эченә төшеп, машиналарын карап менде һәм өстәлдәге дәфтәрнең пароход машинасы белән ничек-ничек эш күрәсен өйрәткән җирен укып чыкты да:

— Ходайга тапшырып, мин машиначы булып пароходны йөртермен,— диде. Башкалар башка эшләрне эшләмәкче булдылар. Кызлар, ашханә тирәсен карап, пароход эченең җыйнаклыгын саклап баруны өстләренә алдылар.

Мин пароход капитаны өчен хәзерләнгән укалы киемнәрне, Үзбәк машиначы өчен хәзерләнгән таза киемнәрне киендек тә, мин пароходның өстенә чыктым, Үзбәк астка, машиналар янына төшеп китте. Башка юлдашлар, пароходның төрле җирләренә таралып, ярдан кузгалуны көтә башладылар. Пароходның өстендә, капитан өчен ясалган биек урында, пароходның машиналары яныннан чыгарылган бер көпшә бар иде. Мин шул көпшә аркылы Үзбәктән:

— Машиналар юлга чыгарга хәзерләрме?— дип сорадым.

— Хәзер!— дип ул җавап биргәч, пароходны суздырып вә бераз моңлы итеп кычкыртып җибәрдем дә теге көпшә аркылы Үзбәккә:

— Ходага тапшырып кузгалыйк! Акрын йөрт!— дидем.

Пароход, үзенең кечкенә көпчәкләрен акрын гына әйләндереп, ашыкмыйча гына ярдан кузгалып китте; ул пошнап-пошнап бу чыгара, акрын гына суны яра, ярны арткарак-арткарак калдыра бара иде... Ярдан бераз китеп, пароходны кояш чыгышы ягына турылап җибәргәч, мин кыйблага карап дога кылдым.

— И Хода, көймәләрнең йөрешләре дә, тукталышлары да синең иркеңдә! Сау-сәламәт килеш теләгән җиремезгә барып җитүдә син безгә ярдәмче бул!

Моннан соң инде мин Үзбәккә:

— Йөрешен җәһәтләт!— дип кычкырдым.

Пароход алга таба катырак омтыла башлады. Көпчәк тавышлары яңгырый, су, ярылып, саф бөртекләр чәчрәтә.

Безнең бөтен тирәмез киткәннән-киткәнгә диңгез белән күбрәктән-күбрәк чолгана барып, җир йөзе ераклашканнан-ераклаша иде. Һава тыныч, су өсте тигез, алда судан башка бернәрсә дә күренми...

Мин, пароходны юлга салып җиткергәч тә, теге дәфтәрдән үземезнең нинди-нинди юллар белән барырга кирәк икәнемезне өйрәнергә тотындым. Алда тугры киләчәк атаулар тугрысында язылган нәрсәләрне укып чыктым.

Өч-дүрт сәгать баргач, кызлар инде чәй вә аның янына ашарга кайбер нәрсәләр хәзерләп өлгерткәннәр иде. Без бер-беремезне алмаштырып торып ашадык-эчтек тә матур диңгезнең күз чагылдыргыч гүзәл күренешен тамаша итеп бара башладык.

Озак вакытлар без шулай бардык. Инде икенде[1] вакытлары якынлашты, шул арада безнең уң ягымыздан, ерактан-ерактан бер атау шикелле нәрсә күренә башлады. Диңгез харитасында[2] бу җирдә һичбер атау күрсәтелмәгәнлектән, без барымыз да, бу нәрсәдән гаҗәпсенеп, аны бинокльләр аркылы карарга тотындык. Яхшылабрак карагач, бу нәрсәнең без уйлаганча атау түгел икәнлеге, бәлки, бик тизлек белән күчеп йөри торган бернәрсә икәнлеге һәм хәзерге шикелле күчүе белән күчкәндә, аның нәкъ безнең юл аркылы үтеп китүе ихтимал икәнлеге беленде. Бу нәрсәнең безгә таба башындагы бер җиреннән нечкә генә бер багана шикелле булып, фонтаннан атылган шикелле, югарыга таба су атылып тора иде. Моны күргәч, без ул нәрсәнең зур, бик зур кит балыгы булуын уйлый башладык. Безнең пароход шикелле кечкенә нәрсәләр өчен мондый зур кит балыгының куркыныч икәнлеген без барымыз да уку китабында күреп белә идек. Безнең эчкә курку төште: кызларымызның берсе инде елаудан да ерак түгел иде. Безнең пароход бара да бара, теге нәрсә дә килә дә килә. Без аңар һаманнан-һаман якынлаша торамыз. Иптәшләр инде чын-чынлап куркыштылар. Кызлар елаша да башладылар, мин дә аптыраштa калдым. Капитан булганга күрә, пароходымызны бу бәладән котылдыру минем өсткә төшә торган бурыч иде. Озак уйлагач, мин пароходны бөтенләй туктаттырдым да китның якынрак килүен көтеп тора башладым. Ул гаҗәп бер ашыгычлык белән килә иде. Ахыр, аңар безнең юлны кисеп китәргә өч-дүрт йөз

[1] *Икенде* — кичке намаз.
[2] *Харита* — карта.

сажиннан[1] артык калмады. Мин дә, елаша торган кызларга юату сүзләре әйтеп, пароходны урыныннан кузгаттырып, кырт кисеп кенә уң якка бордым да бөтен көче белән шулайга таба илтә башладым. Безнең пароход очып бара, кит инде безнең юлны түгел, бәлки без ташлап киткән юлны кисәргә бара. Менә без, кит белән арамызны йөз генә сажин калдырып, аны үтеп тә киттек. Ләкин ул калдырган тулкын шулкадәр куәтле иде ки, безнең пароходымыз ул тулкыннар арасында бер таудан икенче тауга күчеп торган кеше шикелле итеп йөри иде. Бу тулкыннарның куәтеннән безнең юлдашлар инде пароходның идәненә егылып беттеләр. Мин үзем дә көч-хәл белән койрык бора торган көпчәккә тотынып кына аяк өстендә кала алдым. Безгә, тулкыннарга яныбыз белән барырга тугры килмәсен өчен, шактый вакытлар шул бара торган якка таба барырга туры килде. Китның тулкыны азайгач кына, инде без яңадан кояш чыгышы ягына борылып китә алдык ки, шулай итеп, бу мәхәббәтсез кит безне әллә никадәр кирәкмәгән җирләрдән әйләндерде.

Бу куркыныч үтеп беткәч, инде без барымыз да шатландык, кызларымыз да тынычландылар...

Моннан соң инде без тагын үз юлымыз белән киттек. Мин Үзбәккә пароходны бөтен көче белән алып барырга куштым. Су өсте тын вә тыныч. Алдымыз очсыз-кырыйсыз киң вә иркен!

Төн булды. Күк йөзенә меңнәр вә меңнәрчә йолдызлар чыктылар. Боларның диңгезгә төшкән шәүләләре бөтен диңгезне чуп-чуар итеп күрсәтә, диңгезнең төбенә куәтле һәм гаять матур электрик лампаларын меңәрләп яндырып куйган шикелле итеп күзләрне алдый иде. Ай чыкты. Бөтен диңгез өсте үзенә бертөрле тонык яктылык белән яктырды. Аның диңгезгә төшкән шәүләсе, җир белән күкне тоташтырып, нур күпере шикелле һәм гаҗәп матур, һәм гаҗәп олуглыклы иде. Без, бер-беремезне алмаштырып, нәүбәт белән йоклап, төнне уздырдык.

Икенче көнне һава ап-ачык кояшлы һәм бөтен-бөтенгә җилсез булганга күрә, диңгез өсте тип-тигез, шоп-шома, бөтен җир йөзенә җәелеп яткан бер гаҗәеп көзге шикелле күренә иде. Күзләр еракларга-еракларга карыйлар, ләкин судан, шул гаҗәеп тигезлектән башка бернәрсә дә күрә алмыйлар. Безнең матур пароходчыгымыз бу очсыз-кырыйсыз тигезлек өстендә,

---

[1] *Сажин* — 2 м 13 см.

караңгы төннең очсыз-кырыйсыз күгендәге бердәнбер йолдыз шикелле, һәм ялгыз, һәм кечкенә, гаять кечкенә тоела иде.

Озак вакытлар без, шушы күренешне тамаша итеп, тыныч кына, рәхәт кенә бардык. Бер сәгать, ике, бәлки дә, өч сәгать без шулай тыныч вә рәхәт бардык. Шуннан соң кайдандыр, безгә мәгълүм булмаган җирдән, җил исә башлады. Акрын гына башланган бу җил куәтләнә барды. Башта җыерчыклар гына чыгарган диңгез өсте дә, җил куәтләнгән саен, үзенең җыерчыкларын зурайта башлады. Озакламады, инде ул җыерчыклар тулкынчыкларга, ул тулкынчыклар тулкыннарга әйләнделәр. Ул тулкыннар да зурайганнан-зурая бардылар. Баштарак безнең пароходчыгымыз бераз калтыранды гына, аннан соң инде нык ук селкенә, тирбәнә башлады. Бу тирбәнү киткән саен артты, куәтләнде. Безнең йомшаграк иптәшләремезгә инде аяк өстләрендә басып тору да уңгайсыз була башлады. Кайбер иптәшләремездә инде диңгез авыруы башланды: алар укшыйлар, косалар иде, тулкыннар зурайган саен, безнең хәлемез куркынычтан куркынычрак була бара, безнең бу кечкенә пароходчыгымызның бервакыт бөтенләй тулкын астында калуы вә безнең һәммәмезнең батып үлүемез дә бик ихтималга әйләнеп бара иде. Без гаять куркыштык. Кыз балалар гына түгел, инде ир балаларның да күбрәге еларга ук тотындылар.

Менә шулвакытта пароход эчендә теге дәфтәрне укып утырган бер иптәшемез, өскә йөгереп менеп, безгә пароходның мондый тулкыннар вакытында, тәмам йомырка шикелле, эченә су үтми торган бер хәлгә китерелергә мөмкин икәнлеген хәбәр бирде һәм, теге дәфтәрдә өйрәтелгәнчә, безгә өйрәтергә тотынды. Без иң әүвәл бер кечкенә машинага озакка җитәрлек һава җыеп алдык та барымыз, ава-түнә, абынасөртенә йөгереп, теге дәфтәрдә өйрәтелгән юл белән бөтен пароходчыгымызны корыч кабык белән каплап алдык.

Бу кабык эченә кергәч инде, без батып үлү куркынычыннан котылган идек, бары әгәр бу давыл бик озакка сузылып, безнең машина белән җыеп алган запас һавамыз бетсә генә безнең хәлемез уңгайсызланачак иде. Бу корыч йомырка эчендә без һәрникадәр үлем куркынычыннан котылган булсак та, ләкин тулкыннарның көчәйгәннән-көчәя баруы белән безнең барымызда да инде диңгез авыруы бик каты башланганлыктан, пароходымызның барышын бөтенләйгә туктаткан вә үземез, кайсымыз кайда аяктан егылып бетеп, һичбер эш эшли алмас хәлгә килгән идек.

Безнең пароходчыгымыз берничә мәртәбәләр бөтенләй су тулкыны астында калды бугай, бик күп мәртәбәләр аны бер тулкын икенчесенә атып бәреп, ыргытып җибәреп, астын өсткә, өстен астка китерде бугай, ләкин хәлсезләнеп егылып беткән безләр бу эшләрнең берсен дә чын-чынлап аңлап җиткермәдек.

Мин, диңгез авыруыннан бераз айнып, аяк өстенә басарлык хәлгә килгәндә, инде тулкын басылган, пароходчыгымызның атылып бәрелүе дә беткән, фәкать җиңелчә бер калтырануы гына калган иде. Озак үтмәде, иптәшләрнең дә күбрәге айнып җиттеләр. Без, пароходымызның корыч кабыгын ачып, тизрәк һавага чыгарга ашыктык.

Ярты сәгать үткәндә, без инде, кыйбланамә белән тугрылап, пароходымызны юлга салып өлгергән идек.

Биш-алты сәгать без шулай тыныч кына, күңелле генә бардык. Диңгез авыруы белән бозылган кәефләремез дә төзәлеп җиттеләр. Шулай итеп, шактый вакытлар киткәч, безнең алдымызда ерак-еракта бер атау күренә башлады. Бу атауны без әүвәл үземез бара торган атау түгелме икән дип уйласак та, теге дәфтәрдән карагач, аның хакында әллә нинди куркыныч нәрсәләр белдек.

Бу атау тирә-ягына караңгылык чәчеп тора торган Нурсыз атау исемле бер атау булып, аның өстендә әллә нинди, борын тишекләре алга карап тора торган кеше төсле җанварлар тора икән. Болар, кап-кара, шап-шакшы көймәләргә утырып, зур-зур күсәкләр белән коралланып, үз атаулары тирәсеннән үтә торган көймәләргә һөҗүм итәләр, әгәр җиңә алсалар, җиңгәннәрне, үз атауларына алып барып, ачлы-туклы тотып, хезмәт иттерәләр; аларның борын тишекләрен дә үзләренеке шикелле алга карап тора торган итәр өчен, әллә нәрсәләр кыландырып, азаплап һәм бу мескеннәрне, атауның иң караңгы бер җиренә илтеп куеп, күзләрен сукырайтырга тырышалар икән.

Бу нәрсәләрне укыгач, без бик куркыштык, кызларымыз тагын кайгырышырга тотындылар. Без, егетләр, шундый куркынычка очрый калсак, нишләргә тиешлегемезне уйлаша башладык. Ләкин, уйлашып-уйлашып та, ышанычлы бернәрсә уйлап чыгара алмадык. Бары атаудан мөмкин кадәр ераграк юл тотарга һәм, һәрбер ихтималга каршы, һәркаюларымыз пароходтагы тимер-томыр белән коралланырга карар бирдек.

Мин пароходны атауның уң ягына тоттым, ике арада өч-дүрт чакрым кадәр җир калдырып үтәрлек итеп чамаладым да, Аллага тапшырып, каранып бара башладым. Пароход үз җае белән бара, без атауга якынлашканнан-якынлашамыз. Әллә нинди бер күңел caралткыч караңгылыкка чумган бу атау шул караңгылыгын үзенең тирә-ягына чәчеп утырганга күрә, ул якка озак карап торып булмый: күзләр тала, авырта башлыйлар иде.

Безгә әле атау тирәсенә барып җитәргә биш-алты чакрым бар иде. Аның тирәсеннән, караңгылык эченнән, нурсыз, кара бер көймәнең килеп чыкканы күренде. Аның өстендә ун-унбиш кеше сыман нәрсәләр бар икәнен без бинокль (ерактан күрсәтә торган труба) аркылы карап белдек. Боларны күргәч, безнең пароход эченә гаҗәп бер курку төште. Арадан берничәмез, бигрәк тә кызлар, борылып кайтып китик диешә башладылар. Ләкин, Үзбәк белән киңәш иткәч, ул эшнең мөмкин түгеллеге беленде: чөнки пароходымызда инде кил-гән юлымыз кадәр җир кайтырлык күмеремез калмаган икән. Нишләмәк кирәк? Теләсәң дә, теләмәсәң дә барудан башка чара юк иде. Без теләсә нишләргә, әмма аларга терелэй бирелмәскә, барымыз үлеп яки суга батып беткәнче сугы-шырга карар бирдек.

Без барамыз, алар да киләләр. Ара якынлашканнан-якын-лаша бара... Без барымыз да кыйблага карап дога кылдык.

— И һәрнәрсәгә көче җитә торган Тәңре! Без кечкенә колларыңны бу рәхимсезләр кулына төшермә. Аларга безнең борыннарымызны үзләренеке шикелле итәргә ихтыяр бир-мә. И Хода! Без кечкенә колларыңа бу тигезсез сугышта ярдәм ит.

Менә бервакыт тегеләр, көймәләрен җәһәтләтеп, нәкъ безнең юл өстенә чыгарга вә, шулай итеп, безне тотып алырга килә башладылар. Бу куркыныч кешеләрнең инде алга карап тора торган зур борын тишекләре һәм җилкәләренә кадәр төшкән аксыл-сары чәчләре безгә ап-ачык күренә башлады. Без фикеремезне җыеп өлгерә алмадык, тегеләрнең берсе инде кулындагы калын күсәген безнең пароходның башында басып килә торган иптәшемез өстенә ыргытып та җибәрде. Выжгылдап килгән бу күсәк безнең иптәшемезне аяктан екты. Моны күргәч, инде без дә кулларымыздагы тимер-томырны алар көймәсенә таба ыргыта башладык: арада чын-чынлап сугыш китте. Безнең иптәшләремездән күбрәге инде

күсәк тиеп яраланып өлгерделәр, безнең эш гаять куркыныч иде. Бәхеткә каршы, шулвакытта бездән ыргытылган бер тимер, тегеләрнең койрыкчысының башына эләгеп, аны урыныннан екты. Аларны, бер генә минутка булса да, койрыкчысыз калганын күргән мин: «Йә без батып үлик, йә аларны батырыйк!» — дип уйлап,— «Йа Хода! Ярдәм синнән»,— дип, пароходны нәкъ алар көймәсе өстенә тоттым да, бөтен куәте белән җибәртеп, аларның көймәсенең бер ягына башы белән илтеп суктырдым. Аларның көймәсе янтаеп әйләнеп китте. Безнең пароходтагы кешеләр дә идәнгә атылып төштеләр. Мин үзем көч-хәл белән аяк өстендә кала алдым. Бераз киткәч, мин, артка әйләнеп, аларның көймәсенең капланган вә теге җанварларның суга төшкән икәнен күргәч, пароходны бөтен куәте белән баруында дәвам иттердем. Иптәшләр дә инде аяк өстләренә бастылар, кызларымыз, теге күсәк белән яраланган иптәшләремез тирәсенә җыелып, җәрәхәтләрен яза, сылый вә бәйли башладылар.

Теге Нурсыз атаудан безне куарга дип, тагы берничә нурсыз, кара көймәләрнең чыкканнары күренсә дә, без инде үземезнең аларны җиткермәвебезгә ышанып тынычландык, Аллага шөкерләр итеп, юлымызга киттек.

Бу куркынычларны башымыздан уздыра-уздыра, бу көннең ничек үтеп киткәнен тоймый да калдык. Тагы төн җитте, тагы йолдызлар чыктылар, тагы ай чыкты.

Икенче көн иртүк безнең алда тагы бер атау күренә башлады. Яңадан бераз баргач, ул атауның ямь-яшел агачлар эчендә утырганлыгын аерып була иде инде. Атауга якынлашкач, пароходны акрынлатып, без бу яшеллекнең мәһабәт матурлыгын тамаша кылырга тотындык. Безгә күренгән агачлар арасында, без таный торган агачлар булган шикелле, безгә хәзергә кадәр мәгълүм булмаган әллә нинди агачлар да ерактан күренәләр; бу агачларның суга төшкән күләгәләре атау тирәсенә әллә ничек рәхәт бер тынлык вә салкынчалык биреп тора иде. Атауга якын килеп, аның күләгәсе буйлатып бара башлагач, безнең колакка агачлар арасыннан әллә нинди кошларның сайраганнары ишетелә башлады, шул хуш тавышларга мавыкланып бара торгач, без пароход туктар өчен ясалган бер матур пристань күрдек. Бөтен җире төрле агач ботаклары һәм төрле төстәге әләмнәр белән бизәлгән бу пристань үзе дә безнең пароход шикелле кечкенә, нәфис, матур һәм күңелле иде. Аның башына «Балалар атавы» дип

алтын хәрефләр белән язып куелган иде. Мин пароходны аның янына китереп җиткердем.

Без барымыз да монда килеп җитүемезгә соң дәрәҗәдә куанган идек.

III

Бу атауның матурлыгына бер дә чик-чама юк иде. Аның бөтен өсте агачлар, үләннәр, чәчәкләр, кечкенә-кечкенә, ләкин биек-биек таулар белән капланган, бу тауларның өстләре ап-ак чатырлар, кечкенә-кечкенә, ләкин бик матур сарайлар белән капланган иде.

Бу атауның агачлары дөньяның бер төшендә генә үсә торган агачлар түгел, бәлки, иң салкын илләрдә һәм иң эссе җирләрдә үсә торган, күренешләре белән генә түгел, табигатьләре белән дә бер-берсенә капма-каршы агачлар иде. Болар эчендә, безнең җирләрдә генә үсә торган хуш исле таллар белән бергә, иң эссе җирләрдә генә үсә торган хөрмә агачлары, хәтфә шикелле күләгә төшерә торган сәрви агачлары һәм дөньяның бүтән өлкәләрендә өлгерә торган җиләк-җимеш агачлары үсеп торалар; аларның ботакларында дөньяда бертөрле кошлар сайрашып, атауның бөтен тирәсен гаҗәеп матур бер музыка белән яңгыраталар иде. Моның өстендә үсә торган үләннәр дә, шулай ук төрле-төрле вә шулай ук төрле илләр үләннәре булып, бөтен атауны гаҗәеп бер хәтфә палас белән капланган сымак күрсәтәләр иде. Моның елгалары чылтырап агалар, аларның сулары күз яшьләре шикелле булып күренә һәм, шарлавыклар ясап, сихер белән ялтыратылган шикелле, ялтыравыклы тамчылар аералар иде. Моның таулары, урыны-урыны белән бик биек, урыны-урыны белән тәбәнәгрәк булып, төрле төстәге кадерле ташлар белән чуарланып торалар иде.

Пароходымызның тавышы атауга ишетелү белән, безне каршы алырга бер төркем үземез шикелле балалар килделәр дә көләч йөз, яхшы сүзләр һәм дустлык белән безне каршыладылар. Бу балаларны без беренче күрүдән үк дуст тота башладык. Үземезнең кемнәр икәнемезне, ничек-ничек монда килгәнемезне, юлда нәрсәләргә очраганлыгымызны — һәммәсен аларга да сөйләп, атаудагы хәлләрне алардан сораштыра башладык.

Безне алар үзләре сайлап куйган җөмһүрият башлыгы Үтәмеш әфәнде белән күрешергә алып бардылар. Бу баш-

лык, үзе дә безнең кордашлардан булып, унике-унөч яшьләр чамасында иде. Аның киеме, хәтта тора торган сарае да башка балалар киеменнән вә сараеннан артык түгел, әмма үз-үзен тотышы аларныкына караганда мәһабәтрәк, олугларчарак иде. Без аның алдында һәркайсымыз атауда балалар тарафыннан тәгаен ителгән законнар буенча гына йөрергә, бөтенебез өчен кирәк булган эшләрне башкалар белән бергә ихлас вә чын күңелдән эшләшергә, атауга адәмнәнме, хайваннанмы дошман килсә, аңар каршы сугышырга, бер-беремезне хөрмәт итәргә ант иттек. Балалардан төзелгән бер комиссия безне, белгән нәрсәләремездән имтихан итеп, һөнәрләремезгә карап, урыннарга тәгаен итте. Шулай итеп, без атауның үз кешеләреннән булып киттек.

Бу атауда тормыш матур һәм уңайлы төзелгән иде. Балалар төрле-төрле төркемнәргә бүленеп, һәр төркем үзенә бертөрле эш белән шөгыльләнә һәм бөтен бу эшләр аркасында ясалып чыккан иркен тормышның рәхәтләре белән яши бирә иде. Бер төркем балалар, җир эшләп, ашлык вә җимеш эшләрен карыйлар; икенче төркем җирдән чыгарылган бу ашлык вә җимешләрдән төрле-төрле нәрсәләр хәзерлиләр; өченче төркем исә, бу эшләнгән нәрсәләрнең атау халкыннан артканын икенче атауларга илтеп, алардан үз атавымызда булмаган нәрсәләрне алып кайталар; дүртенче төркем, җирдән казылма байлык вә ташлар чыгарып, аларны эшкәртәләр; бишенче төркем, шушы эшләрнең хисапларын күзәтеп, язусызу эшләрен йөртәләр; алтынчы төркем исә, гыйлем эшләре белән шөгыльләнеп, балалар өчен лекцияләр, сабаклар тәртип итәләр, гәзитә вә әдәбият эшләрен алып баралар; җиденче төркем диңгездән асылташлар чыгару, балык тоту һәм диңгездә йөрү эшләрендә хезмәт итәләр. Калганнары тагын башка эшләр артыннан йөриләр иде. Минем иптәшләремнең дә төрлесе төрле төркемгә кушылып, уртак эшләргә, уртак тормышка катышып киттеләр. Мин үзем җәгъразфиядән дәресләр укыта һәм атауда чыга торган гәзитәмездә эшләшә башладым.

Шулай итеп, без менә дигән тормыш белән тора, көннең билгеле вакытларында тырышып эшли, аннан соң җыелышып уйный, кәеф вә сафа сөрә идек. Ашлыкчы вә җимешчеләремез безгә ашлык вә җимеш җитештерәләр. Башкалар алардан төрле нәрсәләр хәзерлиләр. Мал алмаштыручыларымыз үземездән арткан нәрсәләр белән башка атауларга

йөреп алыш-биреш итә бирәләр иде. Бу эшләрнең беренчеләре һәрникадәр хәвеф-хәтәрсез генә эшләнә барсалар да, соңгысы, ягъни атауларга йөреп мал алмаштыру, бөтенләй куркынычсыз булмый: безнең юл өстендәге Нурсыз атауның кеше төсле җанварлары, безнең мал төягән көймәләремезгә әледән-әле һөҗүм итеп, кайсыбер көймәләремезне батыргалап, иптәшләремезне качырып кайтаргалап торалар иде. Менә бу эш безнең күңелле вә иркен тереклегемезнең бер караңгы ягы иде. Бу нурсызлар аркасында кайсы вакытта безнең атавымызга төрле кирәкләреннән мәхрүм булып торырга да тугры килгәли башлады. Шулай бервакыт болар, безнең атауга тоз төяп килә торган көймәне талап, атавымызны бер атна бөтенләй тозсыз ашлар гына ашап торырга ирексез иттеләр. Икенче бервакыт тагы, безнең кызыл мал төяп килә торган көймәмезне талап, күлмәк вә башка киемнәрне яңартудан безне мәхрүм итеп тоттылар. Бу уңгайсызлыклардан гаҗиз калып, без бик күп уйлашып карасак та, моңар чара таба алмый аптыраштык. Башлыгымыз Үтәмеш әфәнде бервакыт, безнең барымызны җыеп, коралландырып, өстләренә барырга уйласа да, аларның күпме икәнлеген, үземезнең көчемез аларны җиңәргә җитәрме икәнлеген ачык белмәгәнгә күрә, ирексез тукталып калырга тугры килде.

Ләкин эш моның белән генә бетми иде әле. Без алар өстенә бармасак, көннәрнең берсендә аларның безнең өстемезгә килүләре дә бик ихтимал иде. Шуңар күрә без, атауның бөтен балалары, зур бер җыен ясап, бу тугрыда үзара киңәш итештек. Киңәш мәҗлесемез бик озак уйлап, бик озак сөйләшкәннән соң, атавымызны бик ныгытып, төрле җирләрдән сугыш кораллары китереп, сак торырга карар бирде.

Бу карардан соң ук без, үз атавымыздан чыгарган кыйммәтле ташларымызны биреп, берникадәр иптәшләремезне бу асылташлар бәрабәренә сугыш кораллары алып кайтырга җибәрдек һәм, үз арамыздан яртымызны аерып, аңа атауны һәртөрле юллар белән ныгыту эшен тапшырдык, иң батыр иптәшләремезне сугышта башлык итәр өчен сайлап куйдык.

Бер атна үткәндә инде, безгә сугыш кораллары килеп җиткән һәм атавыбыз да ныгытып өлгертелгән иде. Бары шулкадәрлесе бар, безгә, бу сугыш хәзерлекләрен күргәндә, әүвәлдә хәзерләнгән запас азыкларыбыздан беразын тотарга тугры килде. Чөнки, иптәшләремезнең яртысы сугыш хәзер-

лекләре белән мәшгуль булганлыктан, калган яртысының гына эше белән барымызга да җитәрлек кирәк-ярак хәзерләнеп өлгертелә алмый иде...

Безнең бу хәзерләнүемез бушка чыкмады: төннәрдән бер төнне атау тирәсендә каравылда торган иптәшләремез, быргылар кычкыртып, бөтен атау халкын йокыдан уяттылар. Бу эш атауга теге дошманнарның килә икәнлекләрен белгертә иде.

Атауның бөтен ир балалары, ярымсәгать эчендә коралланып, алдан тәгаен ителеп куелган урыннарына килеп урынлашып өлгерделәр, кызлар, сугыш сафының артында урынлашып, яраланганнарны бәйләргә кирәкле нәрсәләрне хәзерләп җиткерделәр.

Ләкин без бу хәзерлекләрне күреп җиткергәнче, дошманнар инде атауга шактый якынлашып өлгергәннәр иде. Ярты ай белән яктырган диңгез өстендә аларның ике-өч кадәр кап-кара көймәләре күренделәр. Көймәләрнең һәрберсенә ун белән унбиш арасында дошман урынлашкан иде.

Без бу көймәләрне мылтык һәм пулемётларымыздан гаять кызу ут ачып каршы алдык. Алар безнең өскә олуг вә салмак күсәкләрен ыргыталар һәм уклар аталар иде. Ул күсәкләр һәм уклар, выжгылдап, безнең баш очларыбызда очып йөриләр, килеп эләккән иптәшләребезне аякларыннан ега вә җәрәхәтлиләр иде. Моның өстенә аларның өч-дүрт көймәләрендә мылтыклар да барлыгы мәгълүм булды. Бары ул мылтыклар безнекенә караганда күп начарлар, һәм алар үзләре бу мылтыклардан яхшы ата белмиләр иде.

Шулай да сугыш кызды: безнең санымыз аз, әмма аларныкы безнекенә караганда бик күп артык, без кечкенә һәм көчсезләр, әмма алар зур, таза вә көчлеләр иде. Безнең мылтык һәм пулемётымыз белән кырылуларына да карамыйча, алар һаман алга үрмәләргә тырышалар, алар алга килгән саен, безнең иптәшләребездән яраланучылар арта бара иде. Сугыш кызганнан-кыза барды, без инде ара башладык, җәрәхәтләнүчеләремезнең күбәюе дә безгә курку сала башлады. Менә шул вакытта тегеләрнең мылтыклы өч көймәләре тәмам-тәмам безнең ярга якынлаштылар. Безнең мылтык белән атып торуымызга да карамыйча, бу көймәләрнең берсеннән инде унлап дошман атауга да сикерделәр. Моны күргәч, безнең шул җирне саклый торган иптәшләремез кычкырышып чигенергә, хәтта кайберләре качарга тотындылар.

Эш харап иде! Боларның атауга төшүләре безнең җиңелүемез, безнең сугыш сафымызның өзелүе иде! Бу минут безнең бөтен атавымыз өчен, безнең һәммәмезнең тереклегемез өчен куркынычның тәмам килеп җиткән минуты иде...

Менә шушы минутта безнең сугыш эшләрендә башлыклык итәр өчен сайлап куелган иптәшләремез, ахыр көчләрен җыеп, бик тиз арада атауның икенче җирләрендә сугышып тора торган иптәшләрдән бер бүлеген монда ярдәмгә китереп өлгерттеләр һәм башлап үзләре атауга төшкән дошманнар өстенә сөңгеләр белән ыргытылдылар, болар артыннан башка иптәшләр дә сөңгеләр белән дошманнар өстенә атылдылар, кача торганнар да тукталдылар, курыкканнар да бер гайрәткә килделәр:

— Ур-ра!— дип кычкырдылар... Тәкбир әйтеп, сөңге сугышына керештеләр...

Менә моңа каршы инде дошманнар чыдый алмадылар, аларның күбрәге һәлак булдылар, фәкать берничәсе генә, көймәләренә кереп өлгереп, атау ярыннан читкәрәк, үз иптәшләре янына сыздылар. Бу арада инде атауның икенче башында да дошман көймәләре бик каты ут астында калдырылып, дошманнан бик күпләре үтерелгән һәм яраландырылган икән.

Бу эш, бер яктан, безне тергезеп һәм гайрәтләндереп җибәрде, икенче яктан, дошманның күңелен төшереп һәм өметен җимерде. Без аларның көймәләрен яңа көч вә яңа тырышлык белән мылтык вә пулемёт утлары астында калдырдык.

Яңадан бер-ике сәгатьлек гаять кызу сугыштан соң дошман көймәләре качарга тотындылар, без аларны ут белән озатып калдык...

Шулай итеп, Ходаның ярдәме, үземезнең хәзерлегемез аркасында, без дошманның бу һөҗүмен кайтардык.

Бу сугыш безгә бик күп зарар китергән иде: атауның ярларында ясаган нәрсәләремез ватылып, андагы җиләк-җимеш агачлары да кырылып беткәннәр, боларны яңадан төзер өчен, әллә никадәр хезмәт кирәк иде. Моннан башка сугыш вакытында яраланган иптәшләремез озак вакытлар хезмәткә ярамаслык булып калганнар, боларның һәммәсе өчен эшләү сау калганнарымыз җилкәсенә төшә иде. Безгә хәзер әүвәлгегә караганда бик күп артыграк тырышып эшләргә кирәк булды.

Хәзер без, җиргә кайтып, үземезгә тагы иптәшләр җыярга һәм шул иптәшләр белән бергә Нурсыз атау халкы өстенә

йөреп, алар кулында тоткынлыктагы кешеләрне коткарырга һәм аларның нурсыз, кара көймәләрен яндырып бетерергә хәзерләнәмез. Әгәр без шул эшне булдыра алсак, ул вакытта алар безнең мал төягән көймәләремезне талап тора алмаслар, алар да, безнең шикелле, үзләре эшләп көн итә башларга өйрәнерләр, мәҗбүр булырлар...

Сораулар һәм биремнәр

1. Бөек татар әдибе Фатих Әмирханның балалар өчен язган бу хикәясендә чынлыкка туры килмәгән вакыйгалар да, теләк тә, чынлык та бар. Шуларның өчесен дә табыгыз.
2. Хикәя 1914 елны, ягъни Октябрь революциясенә кадәр язылган. Анда Фатих Әмирхан татар халкының үзе күрәсе килгән тормышын тасвирлаган. Ул тормышның сезгә кайсы яклары ошый?
3. Нурсызлар талау, сугышу белән генә яшиләр. Димәк, сугышырга осталар. Аларның саннары да күбрәк. Ләкин барыбер җиңеләләр. Нигә җиңеләләр?
4. Безнең танышлар Нурсызларны тәмам тар-мар иттеләр, ди. Билгеле инде, алар анда мәктәпләр ачып җибәрәчәкләр. Үзләре теләгәнчә укый башлаячаклар. Үзләре теләгән укытучылар сайлап алачаклар. Шул эш сезгә тапшырылды, ди. Сез нинди мәктәп салып, нинди фәннәрне арттырып, кайсыларын киметер идегез? Үзегез укытучы булсагыз, ничек укытыр идегез?
5. Ә үзегез укучылар булып, шул үзегез төзегән мәктәпләрдә укысагыз, ничек укыр идегез?
6. Корабка утырдыгыз да, сез дә ниндидер бер атау эзләп йөзеп киттегез. Бер утрауга барып чыктыгыз, ди. Нинди утрауга барып чыгарга теләр идегез? Шул утрауны сурәтләгез.

Х.К. Андерсен

Патшаның яңа киеме

Борын-борын заманда бер патша булган, ди. Ул киенергә, бизәнергә бик яраткан, шуңа күрә бөтен акчасын киемгә туздыра торган булган. Яңа киемдә күренер өчен генә дә, ул урам йөрешләре оештыра, шәһәр читләренә чыга һәм көн дә театрларга бара икән. Патша шулай сәгать саен кием алыштырып тора, киемнәре дә берсеннән-берсе яхшы икән. Башка патшалар турында, еш кына: «Патша вәзирләре белән киңәшә»,— дип әйтсәләр, бу патша турында исә бары тик: «Патша киемен алыштыра»,— диганне генә ишетергә туры килә икән.

Патшаның башкаласында тормыш бик күңелле булган. Көн саен диярлек анда чит илләрдән кунаклар килеп тора икән.

Менә бервакыт шулай бу шәһәргә ике алдакчы килеп төшкән. Алдакчылар үзләре турында: имеш, алар данлыклы тукучылар, хәтта кеше хыялы ирешә алмаслык искиткеч бер тукыма тукый алалар дигән хәбәр таратканнар. Янәсе, ул тукымада иң ялтыравыклы буяулар белән иң матур бизәкләр төшерелгән була икән. Шуларның һәммәсе өстенә, имештер, аның тагын искиткеч бер үзенчәлеге бар икән: имештер, аны бары тик акыллы кешеләр генә күрә ала. Ахмак яки хезмәтенә яраксыз кеше, янәсе, ул тукыманы күрә алмаячак икән.

Патша үзенә: «Менә монысы яхшы,— дип уйлап алган.— Минем матур яңа киемем булачак. Шуның өстенә мин тагы үз кул астымдагы түрәләрнең кайсысы хезмәт хакын бушка алып ятканын, кайсысы акыллы, кайсысы ахмак икәнен беләчәкмен. Ул искиткеч тукыманы тизрәк кенә тукып бирсеннәр!» — дигән.

Һәм ул, алдакчыларга алдан күп кенә акча биреп, аларга хәзер үк эшкә башларга боерык биргән.

Алдакчыларга сарайда зур бүлмә биргәннәр, һәм алар, анда ике киндер станы куеп, шулар янына кереп утырганнар да тырышып эшләгән төсле кыланганнар. Үзләренең станнарында исә бернәрсә дә юк, бер генә җеп яки бер генә тукыма кисәге булсачы, ичмасам.

Алдакчылар үз эшләре өчен көн саен иң нечкә ефәк белән саф алтын таләп итеп кенә торганнар. Боларның барысын да үз кесәләренә яшереп, алар таң атудан алып төн уртасына кадәр буш станнар янында утыра биргәннәр.

Көннәрнең берендә патша тукучыларның эшләре белән кызыксынган. Ләкин шунда ук бу тукыманың искиткеч үзенчәлеге исенә төшкән дә патшаның кәефе киткән. Аңа куркырга урын юк югын, әлбәттә, ләкин... алай да башта кем дә булса иkенче барәү карасын әле.

Шуннан соң патша: «Алар янына мин үземнең карт вәзиремне җибәрим әле. Ул бу тукыманы күрә дә күрә инде: ул акыллы һәм үз урынында намус белән хезмәт итә»,— дип уйлаган.

Менә шуннан карт вәзир буш станнар янында алдакчылар утырган бүлмәгә килеп кергән дә: «Менә сиңа мә! Мин бит бер генә нәрсә дә күрмим ләбаса!»— дип аптырап калган.

Ләкин эченнән шулай уйласа да, тышыннан белдермәгән.

Алдакчылар хөрмәт белән генә аңардан якынрак килүен үтенгәннәр, буш станнарга күрсәтеп, бизәкләре һәм буяулары

ошыймы икәнен сораганнар. Бичара вәзир исә, күзен күпме генә акайтмасын, барыбер берни дә күрә алмаган. Соң инде күзгә күренергә бернәрсә дә юк бит.

Вәзир үзенә үзе:

— Шулай ук мин ахмак микәнни!— дип пышылдый икән.— Менә монысын гомердә уйламаган идем! Алла сакласын, бу турыда кем дә булса белә күрмәсен тагын! Тукта, бәлки, мин дәрәҗәмә югарырак хезмәт урынында утырамдыр? Юк, юк, тукыманы күрмим, дип әйтергә һич тә ярамый.

Тукучыларның берсе:

— Нигә сез безгә берни дә әйтмисез?— дип сораган.

Карт вәзир ни дисен? Күзлек аша буш станга караган да:

— Һай, бик матур ич бу,— дигән.— Бизәге дә матур, буяулары да шәп. Патшага әйтермен, сезнең эшегез бик ошады дип мактармын!

— Шатланып эшлибез,— дигәннәр алдакчылар. Аннары, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, тукымаларындагы рәсемнәрне мактарга керешкәннәр.

Вәзир бик зур дикъкать белән тыңлап торган һәм, кайткач, ишеткәннәрен төкми-чәчми патшага сөйләп биргән.

Алдакчылар шуннан соң ефәк белән алтынны тагын да күбрәк сорый башлаганнар. Билгеле инде, алган бер ефәкләрен һәм алтыннарын кесәләренә сала барганнар.

Берничә көн үткәч, болар янына патша икенче бер түрәсен җибәргән. Бу да беренче вәзир кебек мактаган, тегеләрнең мактанганнарын тыңлап торган. Үзе бөгелеп тә, сыгылып та караган, әмма туку станогында бер генә бөртек җеп заты да күрмәгән.

Алдакчылар исә кулларын бик авыр нәрсә күтәргәндәй итеп җәяләр дә сорыйлар икән:

— Ничек соң? Ошыймы? Менә нинди гүзәл бит ул,— дип, әйләндереп-тулгандырып күрсәтәләр икән.

Түрә: «Әлбәттә, мин ахмак түгел, димәк, мин үз урынымда утырмыйм була? Менә сиңа кирәк булса! Ләкин моны белдерергә ярамый ич!»— дип уйлаган.

Һәм ул күренмәгән тукыманы мактарга, булмаган бизәкләргә сокланырга керешкән.

Ә патшага ул тукыманы:

— Бик яхшы, бик матур була!— дип килеп әйткән.

Тиздән бу искиткеч тукыма турында бөтен шәһәр сөйли башлаган.

Ниһаять, бу гаҗәп тукыманы патшаның үзенең дә станнан төшкәнче үк күрәсе килгән.

Менә патша, сарай хезмәтчеләрен һәм түрәләрен ияртеп, тукучылар янына юнәлгән. Болар арасында алдакчылар янында бер мәртәбә булган әлеге ике түрә дә бар икән. Алдакчылар исә шул ук вакыт үз бүлмәләрендә тырыша-тырыша буш станнарда тукыган булып утырганнар.

— Гаҗәп тукыма! Шулай бит, ә?— дигәннәр әлеге ике түрә.— Карагыз әле, бизәге дә, буявы да нинди матур!

Алар, башкалар чынлап та бу гаҗәп тукыманы күрәләрдер, дип уйлап, буш һавага бармаклары белән төртеп-төртеп күрсәткәннәр.

Патша үз-үзенә: «Моны ничек аңларга? Мин бернәрсә дә күрмим! Ләкин бу бит — коточкыч хәл! Шулай ук мин ахмак микән? Бәлки, мин патша булырга ярамый торганмындыр? Монысы инде тагын да начаррак булыр иде!» — дип уйлаган.

Үзе, башкаларга ишетелерлек итеп:

— Әйе шул, начар түгел бу. Минем мактавыма бик тә лаек нәрсә бу,— дигән һәм, канәгать булуын белдереп, башын селкеп куйган. Иярченнәре күзләрен зур ачып карасалар да, патшаларыннан артык берни дә күрмәгәннәр. Алай да алар, бертавыштан:

— Һай, нинди шәп! Гаҗәп тукыма бу!— дип, тукыманы мактап, патшага, тантаналы йөрештә кияр өчен, бу тукымадан үзенә кием тегәргә тәкъдим иткәннәр.

Патша, алдакчыларны орденнар белән бүләкләп, аларга сарай тукучысы дигән исем биргән.

Тантанага каршы төнне алдакчылар, төн буена эшләгән булып, уналтыдан артык шәм яндырып бетергәннәр. Күз буяр өчен, алар тукыманы станнардан төшергән булып, аны зур кайчылар белән кискәләгән булып маташканнар. Аннан соң инде алар җепсез энәләр белән патшага яңа кием тегә башлаганнар, ниһаять:

— Кием әзер! — дип игълан иткәннәр.

Иртә белән патша, үзенең иярченнәрен ияртеп, яңа киемне алырга дип килгән.

Алдакчылар:

— Рәхим итегез, патша хәзрәтләре, менә ыштаннар, менә камзул, ә менә монысы чикмән. Бик күркәм кием! Пәрәвездән дә җиңелрәк. Сез хәтта кигәч тә аны сизмәссез,— дип

сөйләнә-сөйләнә, әйтерсең лә нәрсәдер тоткан кебек итеп, кулларын өскә күтәреп торганнар.

Сарай хезмәтчеләре дә:

— Әйе, әйе!— дип, алдакчылар әйткәнне җөпләп торганнар. Үзләре, билгеле инде, шулай ук берни күрмәгәннәр. Ни күрсеннәр — ялганчылар кулында бит берни дә булмаган.

Ниһаять, алдакчылар патшага әйткәннәр:

— Инде хәзер үзегезне яңа киемгә киендерик, көзге каршына басыгыз,— дигәннәр.

Патша өстендәге киемнәрен салгач, алдакчылар аңа үз күлмәкләрен киендерергә тотынганнар. Әле яңа ыштан кидергән кебек итәләр, әле камзул кидергәндәй маташалар. Аннары, төймә төймәләгәндәй, бармакларын селкеткәннәр. Ә соңыннан әйтерсең патша җилкәсенә җиләнен салалар, кулларын һавага чөеп болгап җибәргәннәр. Патша көзге тирәсендә әйләнә, ди. Әле бер якка борылып карый, әле икенче якка борыла.

— Һай, ничек килешә бу яңа кием патшага! — дип мактап тора, ди, патша түрәләре.— Кара инде син аны нинди килешле итеп тегелгән. Буяулары күз явын алырлык, үзе нинди килешә!..

Ул арада хезмәтчеләрнең берсе патша арбасы әзер булуын кереп әйтә.

— Хәзер чыгам,— ди патша.— Йә, ничек, кием ошыймы?

Көзгегә тагын бер кат борылган. Якынрак килгән, киемен баштан аякка кадәр карап чыккан. Аның үз киемен ничек җентекләп тикшереп карауларын барысы да күрергә тиешләр лабаса.

Патша җиләненең арткы чабу очыннан күтәреп барырга тиеш булган камергерлар, идәннән нәрсәдер күтәргән булып кыланганнар да, кулларын алга сузып, патша артыннан юнәлгәннәр, күтәреп барырлык әйбер юк икәнлекне белдерү кая, төсләренә чыгарырга да курыкканнар.

Менә тантаналы йөреш башланган. Патша даирәсе ачык купшы чыбылдык күләгәсендә гаять тантаналы бер кыяфәттә атлый, ә урамнарда җыелган халык:

— Ах, нинди кием! Нинди шәп җилән! Бу кием патшага нинди килешә!— ди икән.

«Бернәрсә дә күрмим»,— дип әйтергә бер генә кеше дә батырчылык итмәгән, беркемнең дә ахмак булып танылासы, яки үзенең бернәрсәгә дә яраксыз икәнлеген белдерәсе килмәгән.

Кинәт шунда ниндидер бер сабый бала:

— Ә патша ялангач бит!— дип кычкырып җибәрмәсенме!

— Ах, бу гөнаһсыз сабыйның нәрсә әйткәнен тыңлагыз әле! — дигән бу баланың әтисе.— Бала — бала инде ул. Димәк, ул дөрес әйтә.

— Кара әле, дөрес бит бу! Патша ялангач бит! — дип пышылдаша башлаганнар бар да.

Кинәт бөтен халык:

— Патша ялангач! Ялангач! — дип кычкыра башлаган.

Патшаның йөрәге жу итеп киткән: «Бу кешеләрнең барысы да ахмак түгел бит инде. Димәк, минем түрәләр мине алдаганнар. Ни эшләргә? Хәзер сер биреп булмый бит инде!» — дип уйлаган, ди, патша.

Шуннан соң ялангач патша үзенең чыбылдыгы астында тагын да масаебрак атларга керешкән. Ә түрәләре юк күлмәкнең юк итәкләрен тотып баралар, ди.

Сораулар

1. Бу әкият халык әкияте түгел. Шуңа күрә халык әкиятләре төзелешенә охшамаска да мөмкин. Әкиятләр гадәттә ни белән башлансалар, шуның киресе белән тәмамланалар. Әлеге әкияттә шул алым файдаланыламы?
2. Әкият нәрсә турында?
3. Ни өчен берәү дә тегүчеләр ялганын күрми?
4. Ә ни өчен сабый сүзеннән соң бар да: «Патша ялангач»,— дип кычкыра?

Фәнис Яруллин

Зәңгәр күлдә Ай коена

(*Әкият*)

Төннәрен, барлык кешеләр йоклап беткәч, бакалар бакылдаудан, кошлар сайраудан, яфраклар шаулаудан, җилләр исүдән туктагач, Зәңгәр күлгә төшеп, Ай коена икән. Чөнки ул чисталыкны бик яраткан. Бөтен тәнен исле сабын белән ышкый-ышкый икән дә күлнең иң тирән җиренә чума-чума рәхәтләнә икән. Шулай әллә ничә тапкыр тәнен сабынлап, әллә ничә тапкыр чумып чыкканнан соң, ул күп итеп төнбоек чәчәкләре җыярга тотына икән. Чәчәкләрнең дә төрлесен түгел, иң акларын, тәмам ачылып җиткәннәрен генә җыйган ул. Ике учы тулганчы төнбоек чәчәкләре җыйганнан соң, Ай, үзенең болыттан ишеп ясаган баскычының йомшак басмала-

рына сак кына баса-баса, күккә күтәрелә икән. Күккә менеп җиткәч, кулындагы төнбоек чәчәкләрен әле бер якка, әле икенче якка ыргытып уйнарга тотына икән. Ә ул ыргыткан төнбоек чәчәкләре, күкнең түшәменә кадалып, йолдыз булып яна башлыйлар, ди. Әгәр төн уртасында урамга чыгып күккә карасагыз, Айның үз учындагы чәчәкләрен күккә кадап йөрүен күрер идегез, мөгаен. Ул чагында төн көндезге кебек яп-якты була, чөнки яңа гына Зәңгәр күлдә коенып чыккан айның тәне чип-чиста, җилләр йоклагач, болытлар да бүредән курыккан сарык көтүедәй чабышып йөрми, ояларында әкият тыңлап, тыныч кына ята бирәләр. Ә Айга рәхәт, ашыкмый гына дөнья гизә, йолдызлар бер-берләренә зәбәрҗәт ташлар ыргытышып уйный башласалар: «Әй балалар, артыгын шашмагыз. Ыргыткан ташларыгыз җиргә килеп төшәр дә берәрсен һәлак итәр. Шуннан соң кешеләрнең безгә ачуы чыгар»,— дип, йолдызларны тыеп тора икән.

Һәр көн шулай көн артыннан төн туган, күкнең биек түшәмендә йолдызлар җемелдәшкән, һәр төн шулай Зәңгәр күлдә коенырга Ай төшкән.

Бер төнне, гадәттәгечә, Ай күлдә чума-чума коенып ятканда кинәт кенә җил уянган, чөнки җилнең җирдәге койрыгына, ялгышып, бер сукыр тычкан китереп баскан. Җил койрыгы, авыртуга түзә алмыйча, үрле-кырлы сикергән. Аннары авырткан җиренә сулышын өрергә тотынган. Җил койрыгына шулкадәр өргән, ди, аның өрүеннән күл читендәге камышлар шаулый башлаган. Әнә шулай итеп, сукыр тычкан җилне, җил камышларны, камышлар су өстендәге дулкыннарны уяткан. Йокысыннан вакытсыз уянган дулкыннар күл өстендә галәмәт тавышлар чыгарып чабышканнар. Кайбер усалраклары күлдә үсеп торган төнбоекларны йолыккан, кайберләре кулы авыртканчы ярны кыйнаган, ә кайберләре су читендәге бака ефәкләрен йолкып-йолкып эчкәрәк, Ай коенып ята торган төшкәрәк китергән. Ай, су керүе белән мавыгып, җилнең йокыдан уянуын да, дулкыннарның ачуланышып төрле якка йөгерешүләрен дә күрми калган. Ә инде күргәч, судан атылып чыгыйм дигән икән, яр буеннан дулкын куып китергән бака ефәгенә уралган да калган. Ай әле тегеләй ыргылган, әле болай ыргылган, әмма бу ефәк ятьмәдән ычкына алмаган. Айның тыны бетә башлаган.

— Коткарыгыз, батып үләм,— дип кычкырган ул бар көченә. Аның тавышын иң беренче булып карт Чуртан ишеткән.

— Нәрсә төнне куркытып кычкырасың? — дигән ул Айга.

— Чуртанкай,— дигән Ай,— зинһар, коткара күр. Синең тешләр бик үткен, бу ефәкне «эһ» дигәнче ерткалап атачаксың.

— Бик коткарыр идем дә, тешләрем сызлап тора шул,— дигән Чуртан, Айның батуына сөенеп. Чөнки ул Айның шундый матур, шундый якты булуына, бөтен дөньяны сокландырып торуына бик көнләшеп йөргән икән. Аннары Айның ашамыйча-эчмичә яши алуына да бик эче пошып йөргән булган Чуртанның.— Без монда көн саен тамак туйдыру турында уйлыйбыз, әллә кемнәрнең кармакларына эләгәбез. Ә син эшләмичә рәхәт кенә яшисең,— дигән Чуртан.

— Минме эшләмим?— дигән Ай.— Мин, беләсең килсә, төне буе бөтен дөньяны яктыртам. Мин булмасам, төнге юлчылар барыр юлларын таба алмаслар, диңгезләрдә кораблар батар, караңгыда юлбасарлар, караклар бер гөнаһсыз кешеләрне таларлар.

Чуртан аның сүзен бераз гына тыңлап торган да, Айның һаман саен тирәнрәк бата баруын күреп, бәладән башаяк дип китеп барган. Ай тагын бар көчен җыеп кычкырган:

— Коткарыгыз, батып үләм!..

Бу юлы Айның тавышын бер бик ямьсез, чатан аяклы, карлыккан тавышлы Гөберле бака ишетеп килгән.

— Әй, син нәрсә,— дигән ул Айга,— безнең ефәкне урларга килдеңме әллә?

— Коткарчы, зинһар,— дигән Ай,— тыным бетә. Күктә ялтырап торыр вакытым җитә. Кешеләр күктә минем юклыкны күрерләр дә хафага калырлар. Ә минем кешеләрне бер дә кайгыга саласым килми.

— Ярар, коткарырмын,— дигән Гөберле бака,— тик башта син минем тавышымны тыңлап кара. Матур сайрыйммы мин?

Бака әллә нинди тавышлар чыгарып бакылдарга тотынган.

Тавышы аның авызына су кабып гөбердәткән кешенеке кебек гөбердәгән-быкырдаган.

— Йә, матур сайрыйммы?— дигән Гөберле бака.— Тавышым минем сандугачныкыннан матуррак бит, әйеме?

— Сандугачныкыннан матур дип булмый инде анысы,— дигән ялганларга өйрәнмәгән Ай.— Ләкин син аңа бер дә борчылма. Син бит бака: баканың үз җыры, сандугачның үз җыры.

— Ә-ә, шулаймы?— дигән Гөберле бака.— Әгәр бөтен күлгә ишеттерерлек итеп: «Гөберле баканың тавышы сандугач-

ныкыннан матуррак»,— дип кычкырмасаң, синə бу күлдəн чыктым юк. Йə, кычкырасыңмы, мин китəм. Өчкə хəтле санаганчы авызыңны ачалмый торсаң китеп барам. Йə, башладык: бер... ике... өч...

— Юк инде,— дигəн Ай,— мин ялганлый алмыйм. Ялганласам, минем йөзем каралачак, ə кара йөзле Айның кемгə кирəге бар?

— Алайса, үзеңə үпкəлə,— дигəн дə китеп барган Гөберле бака. Ай, соңгы көчен җыеп, тагын кычкырып җибəргəн:

— Əй-əй-йй! Коткарыгыз, батып үлəм.

Бу Зəңгəр күл буенда гына бер балыкчы яши икəн, балыкчының Айсылу исемле кызы булган. Шушы балыкчы кызы Айсылуның ни өчендер ике як битенə дə уч төбе кадəрле кап-кара миң үскəн булган. Үзенең шул миңнəреннəн оялып, Айсылу урамга да төннəрен генə чыга икəн. Менə шушы Айсылу исемле кыз күл буенда:

Битлəремдəге миңнəрем
Бетми күпме юсам да,
Бəхетлерəк булыр идем,
Бака булып тусам да,—

дип, моңаеп җырлап йөргəндə, Айның ярдəм сорап кычкырганын ишеткəн. Ишеткəн дə, аны-моны уйлап тормастан, күлгə таба йөгергəн. Айның инде ныклап кычкырыр хəле дə калмаган булган. Ул бер баткан, бер калыккан.

— Əй сөйкемле Ай, матур Ай,— дигəн Айсылу,— əз генə түз. Мин хəзер... — Кыз бөркəнеп чыккан шəлен иңеннəн алып ыргыткан да, йөзə белмəвен дə онытып, суга ташланган. Ике чумып бер калкуга, ул инде Ай янына барып җиткəн. Тик аның үзенең дə кулларына, муеннарына бака ефəге уралган. Əмма кыз үзе турында уйламаган, тизрəк Айны коткарырга тырышкан. Калын бака ефəген ул бөтен көченə ерткаларга, өзгəлəргə тотынган. Менə бермəлне ефəк арасыннан Айның түп-түгəрəк, як-якты йөзе күренгəн.

— Рəхмəт, Чибəркəй,— дигəн Ай чын күңеленнəн,— коткардың.

— Алай əйтмə,— дигəн Айсылу,— мин чибəр түгел, мин — ямьсез кыз. Шул ямьсезлегемнəн оялып, мин көндезлəрен урамга чыкмыйм.

Ай үзенең баскычы буйлап күккə таба үрмəли башлаган, Айсылуга əллə нинди ягымлы, матур сүзлəр əйтəсе килгəн

аның, ләкин вакыты бик аз калган булган. Чөнки, күккә менеп, йолдызларны кабызырга вакыт җиткән. Күккә менеп җитә язгач, ул түбәнгә караган да Айсылуга болай дип кычкырган:

— «Чибәркәй» дип ялганламадым. Син,чынлап та, дөньяда иң-иң чибәр кыз. Әгәр минем сүзләремә ышанмасаң, йөгереп өеңә кайт та көзгегә кара.

Кыз йөгерә-йөгерә өенә кайткан. Ут кабызган. Курка-курка көзге каршына килгән. Озак кына көзгегә карарга йөрәге җитми торган. Ә караса... Ә караса — көзгедә гүзәлләрнең гүзәле бер кыз басып тора икән. «Мин түгелдер, бу бүтән берәр кыздыр»,— дип, Айсылу үзенең битләренә кагылган, көзгедәге кыз да шул ук хәрәкәтләрне кабатлаган. Айсылу толымнарын сүтеп иңнәренә тараткан, көзгедәге гүзәл дә шуны ук эшләгән.

Бик озак ышана алмаган Айсылу моның үзе икәнлегенә. «Битемдәге олы ямьсез миңнәр кая китте икән соң?» — дип уйлаган ул.

Мин дә башта, кызның миңнәре кая китте икән соң, дип уйлаган идем. Хәзер белдем инде. Ай аның йөзенә, үзен коткарган өчен, якты нурларын ягып калдырган икән. Шуңа хәзер иң матур кызларга:

Ай туганда тудыңмы әллә,
Ай нуры бар йөзеңдә,—

дип җырлыйлар бит. Ә Ай үзенең якты нурын бары тик күңеле матур кешеләрнең йөзенә генә яга ала. Чын-чын. Әгәр минем сүзләремә генә ышанмасагыз, кемгә дә булса яхшылык эшләп карагыз, шунда сез айның тылсымлы нурларында коенгандай матурланып китүегезне күрерсез.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әкиятнең темасын әйтегез.

2. Әгәр безгә таныш алымны кулланскак: әкиятнең ахырында баштагы вакыйганы кабатласак, аңа нинди мәгънә бирергә була?

3. Ай Чуртан, Бака һ. б. белән бәйләнешкә керә: ярдәм сорый, тегеләре ярдәм итмиләр. Ләкин шул ук Ай күл суы, җил, йолдызлар белән дә бәйләнешкә керә. Мәсәлән, Ай суда юына диярга дә, су Айны юа диярга дә була. Әгәр су юа икән, нигә шулай итә? Дулкыннар Айга һөҗүм итәләр. Ни өчен? Аларга Айның кай җире ошамый? Аннары, бәлки, дулкыннар кемнеңдер кушуы буенча

канығалардыр Айга? Ә Бака ефәге Айны нигә батырмакчы була? Чуртан Айның ашамый яшәвенә көнләшә. Бәлки, ашамый яшәү Айның иң матур сыйфаты түгелдер. Бәлки, аңа Айның аклыгы, пакьлеге, биеклеге ошамыйдыр. Шактый уйлап, әкиятне шул рәвешле үзгәртеп сөйләгез яки башка әкият языгыз.

Габдулла Тукай

Иссез чәчәк

(Русчадан)

Болынлыкта үсә гади генә, иссез чәчәк, яңлыш
Гүзәл исле чәчәкләр бәйләменә бергә бәйләнмеш.

Ярар, бәйләнгән ул анда, соңыннан нәрсә булган соң? —
Булып киткән үзе хуш исле бик аз берзаманнан соң.

*

Шуның күк, безне тәүфыйклы дуст-ишләр һәм белешләр дә
Өйрәтерләр гүзәл гадәткә һәм дә изге эшләргә.

Биремнәр һәм сорау

1. Чагыштырылучы якларны табыгыз.
2. Шигырьдә ничә чагыштыру бар?
3. «Чәчәк»нең мәгънәсен әйтегез.

Габдулла Тукай

Китап

Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,
Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,
Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны
Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә.

Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,
Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса
Хәзер генә сыгылып-сыгылып елаган яшь, —

Шулвакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам.

Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем
Була минем юл күрсәткүче йолдызым;
Сөйми башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,
Ачыладыр, нурланадыр күңлем, күзем.

Җиңелләнәм, мәгъсумләнәм[1] мин шулчакта,
Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка;
Ышанычым арта минем үз-үземә,
Өмид берлән карый башлыйм булачакка.

Биремнәр һәм сорау

1. Шигырьне ике өлешкә бүлик: беренчесенә «Сәбәп» дип исем кушыйк. Чөнки әдип, кабатлый-кабатлый, китапны ни өчен укый башлавы турында яза. Икенче өлештә лирик геройга китап ясаган тәэсир турында языла. Шуңа күрә аңа «Ярдәм» дип исем бирә алабыз.
Өлешләрнең эчтәлеген сөйләгез: сәбәпләрне һәм ярдәмнәрне санап чыгыгыз.
2. Ә сез китапны ни өчен укый башлыйсыз? Сез дә үз сәбәбегез турында сөйләгез.

Фатих Хөсни

Малай белән солдат

...Бусы менә Наилләр өе. Аны узып бераз барасы да — күпер. Күперне узып бераз баргач — каланча. Аның башында зур җиз чаң, аннары тагын тире толып кигән Галәви абзый басып тора... Шунда ук тыкрык, тыкрыктан бераз баргач — ындыр. Аннары басу капкасы, аннары тимер юл, аннары калай түбәле кызыл станция. Станциянең аргы ягында — кар басып киткән кыр. Куян белән тулган урман. Урманның аръягында кайдадыр шунда якында гына — Наилнең этисе... Ә үзе — шул эти кайтмый да кайтмый. Әнисе әйтә Наилгә, сораган саен әйтә: әнә шул якка, урман артына таба китте безнең этиебез, кайтса, шул яктан ук әйләнеп тә кайтырга тиеш, ди. Элегрәк Наилгә сугыш үзе дә шунда, урман артында гына булгандыр кебек тоела иде, үсә-үсә ул инде белә башлады: юк, сугыш урман артында гына булмаган, сугыш каладан да ары, Теләчедән дә ары, кайдадыр еракта-еракта булган, аны хәзер тагын да ераккарак куганнар, ә Наилнең

---

[1] *Мәгъсумләну* — сафлану.

этисе алай еракта түгел, менә монда — урман артында гына. Шулай уйлау рәхәт, шулай уйлау күңелгә тынычлык бирә, әни дә шулай уйлый, күршедәге Нурҗиһан әби дә шулай уйлый, кем белә, бәлкем, каланча башындагы Галәви абзый да шулай уйлый торгандыр!

Наил хәзер бала-чага түгел, ул инде укырга өченче класска йөри, өйдә әнисенә булыша, абзар-кура арасында терлек-туар карый, бүтәнен әйтеп тә торасы юк, ул быел, кулына балтапычкы тотып, үзенә чаңгы да ясады. Шулай да әти турында ул элек ничек уйлаган булса, хәзер дә шулай уйлый: әти урман артында мәңгелеккә калырга тиеш түгел, әти кайчан да булса бер кайтырга тиеш. Сугыш булган да беткән, башка кешеләрнең әтиләре инде әллә кайчан кайтканнар, тик менә Наилнең әтисе генә кайтмый да кайтмый.

Кышкы каникул вакыты иде. Беркөнне Наил, үзе ясаган чаңгыга басып, япа-ялгыз чыгып китте. Күперне узды, каланча чатына җитте, тыкрыкка борылды, басу капкасы янында аз гына тукталып торды, аны да үтте, басуга чыгып китте. Ә үзе япа-ялгыз, җитмәсә тагын көн кичкә авышып бара, нык кына буранлап та тора.

Станция юлында аңа аркасына рюкзак кигән, кулына кечерәк кенә чемодан тоткан җәяүле бер солдат очрады. Икесе дә туктап калдылар.

— Бу — алда күренә торган авыл — Мүкле-күл авылымы? — дип сорады солдат, малайны башыннан аягынача күздән үткәреп.

— Мүкле-күл түгел, безнең авыл, — дип җавап кайтарды Наил, солдатның соравын аңышып җитмичә. Ул, зурларча хәрәкәт ясап, бүреген артка чөя төште, маңгаен сыпырып куйды. «Менә мин шул авыл егете булам инде!» — дигән кебек итеп, солдатка кыю гына карап алды. Икесе дә көлемсерәп куйдылар. Малайның болай чекерәеп торуы солдатка ничектер сәер тоела иде, шул ук вакытта Наилгә дә кызык: шушындый зур солдат абый, кыр уртасында аны туктатып, аннан авылны сорап тора.

Бераз сүзсез торганнан соң, солдат янә сорап куйды:

— Ә соң син болай кичләтеп кая барасың?

«Әтине эзләп барам» дип чак кына ычкындырып ташламады малай, ничектер уңайсыз булып китте аңа. Шунда ук ул, чаңгысын авыл ягына борып, солдатка ияреп кайтырга булды. Юлда алар, әллә ни сөйләшеп тормыйча, икесе дә бик зур кеше булып, тамак кыргалый-кыргалый гына кайттылар.

Шулай да солдат сорашкалады: янәсе, Наилгә чаңгыны кем ясап биргән? Наил мәктәптә укыймы? Ничәнче класста укый? Укулары ничек бара? Наил киләчәктә кем булырга уйлый? Җитмәсә тагын, бер ачылгач, Наилнең чаңгысын да яманлап ташлады, чаңгыны, имеш, юкагачтан ясамыйлар. Сөйләшмәделәр дисәк тә, байтак кына сөйләшкәннәр икән алар. Кыскасы, Наилләр авылына кайтып җиткәндә, алар инде тәмам дус кешеләр булып өлгергәннәр иде.

Каланча чатында, борылмыйча, солдат үз юлы белән китә башлагач, Наил кинәт аптырап калды:

— Безгә бит бу якка... син безгә кайтмыйсыңмыни?— дип сорап куйды ул, моңсу гына итеп. Аның тавышы бер үк вакытта гаҗәпсенү һәм аптырау белән тулган иде. Солдатка ул шундый бер тилмерү белән карап алды, солдат каланча чатында борылмас җиреннән борылды.

— Кайтыйк, алайса...— дип, шаярткандай итеп кенә әйтеп куйды ул, һәм үзе авыз эченнән генә, әмма уйланып калган хәлдә кабатлады: — Караңгы да төшеп килә, буранлап та тора... Наил белән түгел, үз-үзе белән шулай сөйләнде... Ул кичне Наил, шатлыгыннан нишләргә белмичә, гел солдат тирәсендә бөтерелде: аның йолдызлы бүреген киеп карады, аның бил каешын салдырып, каешны үзе буып йөрде, солдат аның белән шашка уйнаган булды. Тышта буран котыра, буран тәрәзә пыяласына кар китереп сылый, әллә нигә бер күрше Әхми абзыйларның эте өреп куя, ә өй эче җылы, рәхәт, җиделе лампа яна. Наилнең каршысында зур гәүдәле, таза иңбашлы, салынкы кашлы, гел көлемсерәп торучы сөйкемле абый утыра. Бик күңелле булып китте Наилгә, һәм ул, шул рәхәтлектән әкрен генә оеп, мендәргә кәкрәеп төшкәнен үзе дә сизми калды.

Ләкин иртәгесен солдат абый юк иде инде. Наил йокысыннан торганчы, солдат абый җыенып чыгып киткән. Йолдызлы бүрек тә юк, бил каешы да юк, шашка төймәләре дә кайсы кайда сибелеп яталар, кыскасы, өй эче нәкъ элеккечә бушап, ятимләнеп калган иде. Наил, күңелсезләнеп, тәрәзәгә килде, күзләре белән солдат абыйны эзләп табарга теләгәндәй, каланча тыкрыгы ягына таба карап торды. Ләкин солдат абый бер җирдә дә күренми иде. Ул да түгел, ишекне зур итеп ачып, әнисе яңа чаңгы күтәреп керде.

— Менә сиңа... солдат абыең ясап калдырды,— диде ул, чаңгыны Наилгә биреп. Шулай диде дә, бүтән бер сүз дә әйтмичә, ашыгып кече якка кереп китте. Күреп калды Наил,

энисенең нишләптер иңбашы дерелдәп куйды, кинәт яулык почмагы белән күзләренә тотынды — әллә елый инде?

Менә моны, ичмасам, чаңгы дияргә дә була — үзе киң, үзе озын, үзенең әле олылар чаңгысы кебек башы да кәкрәеп тора. Ә әни, юләр, елый. Солдат абый аның малаена нинди шәп чаңгы ясап калдырган, ул елый...

Сораулар һәм биремнәр

1. Хикәядәге беренче вакыйга мондый: Наил этисен эзләп китә. Нигә эзләп китә?
2. Ни өчен Наил солдатны өенә алып кайта? Ул аңа таныш түгел бит?
3. Тагын бер вакыйга: өендә солдат утырганга Наил шатлана. Ни өчен шатлана?
4. Соңгы вакыйгада Наил тагын бер мәртәбә шатлана. Бу юлы чаңгылы булган өчен шатлана. Ә менә әнисе елый.
Ни өчен бала шатлана, ә әнисе елый?
5. Хикәянең иң баштагы вакыйгасын искә төшерик. Наил чаңгы шуарга чыга һәм карлы юлдан этисен эзләп китә. Урамда буран дулавын да онытмыйк.
Хәзер Наилнең яңа чаңгысы бар. Күңелен бераз юатты. Хикәя ахырында да ул чаңгы шуарга чыгып китә аламы? Китсә, кая барачак һәм ни өчен барачак? Ә көн нинди? Буранмы, аязмы? Без бит хәзер — авторлар. Ни әйтергә теләвебезгә карап, буран да, кояш та чыгара алабыз.

Габделхәй Сабитов

Урман кызы Таңсылу

(Тылсымлы хикәя)

Сәер кеше бу Газизулла абзый. Гомере буе урманда яшәп тә, һаман күңеле урманнан бизмәгән. Яшь чагында әллә кайларда, Иртеш буйларында сал агызган. Аннан соң күп еллар урманчы булып торган. Сугышта яраланып, бер җиңен бил каешына кыстырып кайткач та, җылы урын, төшемле эш сайлап йөрмәгән: кызлар көзгесе кебек түм-түгәрәк урман күле буендагы пионер лагерена каравылчы булып төпләнгән дә калган.

Сәлимә апа әле хәзер дә шул хакта сүз кузгаткалый:

— Урман шүрәлесенә әйләнеп беттек инде. Булмады, кешечә яшәтмәдең,— ди.

Газизулла абзый дәшми. Ул радионы әкрен тавышка көйләп куйган да, бөтен дөньясын онытып, кемнеңдер, бик моңлы итеп, курай тартуын тыңлый.

Сәлимә апа тавышын күтәрә төшә:

— Минем дә бер күрше-күлән белән гөрләшеп яшисем килә. Урман дисең икән, әллә Каф тавы артындамы? Әнә, Сабирлар кебек, ял көннәрендә гуләйткә килеп йөрер идек әле...

Сәлимә апаның сүзе озаккарак китсә, Газизулла абзый, кырын яткан җиреннән үрелеп, радионы бераз көчәйтеп куя.

— Ичмаса, әйткән сүзеңне колагына элсен иде,— дип дәвам итә Сәлимә апа.— Әзрәк бала турында уйлар идең. Мәктәбе җәһәннәм астында бит. Язын-көзен зат-пирут өч чакрым ләпшердек ера. Кеше балалары әнә шәһәрдә трамвайларда гына йөри.

Газизулла абзый, мыек астыннан гына көлеп, Булатка карый. Әтисенең бу карашын Булат шунда ук төшенеп ала:

— Башка кайгың булмаса, минем өчен борчылма, әни,— ди ул, мут елмаеп.

— Һи, үзең кебек, малаеңа да урман җене кагылган инде.

— Син, әнисе, каты күңелле кеше. Урманның серен аңлый белергә, җырын тыңлый белергә кирәк аның... Әйдә, улым, булмаса, бер әйләнеп керик әле.

Булатка шул сүз җитә кала. Ул шунда ук, сикереп торып, өстенә киенә башлый. Сәлимә апа бөтен чәпчүләрен онытып көлеп җибәрә:

— Менә инде хыялый! Бу кадәр булырсыз икән! Кая барасыз инде?

Капкадан чыгуга, әтисе үзенең сыңар кулын Булатның җилкәсенә сала. Борылмалы тар сукмак буйлап, алар бик озак шулай тын гына баралар. Түгәрәк күл читен әйләнеп узгач, сукмак, сиздермәстән генә бер читкә борыла да, куе куакларга борынын төртеп, аю табаны, сәрдә, балтырган яфраклары астына яшеренә.

Газизулла абзый кинәт кенә туктала да Булатка карап пышылдый:

— Тс-с! Шаулама! Ишетәсеңме?

Булат, гаҗәпләнеп, әтисенә күтәрелеп карый. Газизулла абзый, башын бераз кырын салып, онытылып тыңлый. Кинәт аның йөзе яктырып китә, маңгаендагы тирән җыерчыклар языла төшә, мыек чылгыйлары кыймылдап куя.

— Ишетәсеңме?

— Ишетәм... Усак шаулый.

— Усак кына түгел, Карурман бабай җырлый, улым.

— Ә нигә соң ул үзе күренми? Нигә мин дә ишетмим?

Газизулла абзый, улына карап, серле генә елмаеп куя:

— Син, улым, урманның серләрен белеп бетермисең әле. Таң вакытын йоклап уздырасың. Урман кызы Таңсылуны да күргәнең юк... Әйдә, борылыйк, әнә яңгыр төшкәли башлады. Әниең борчылмасын.

Кайтып йокларга яткач, Булатның күзенә йокы кермәде... Их, бер күрәсе иде шул җырчы бабайны. Отып аласы иде шуның моңлы җырларын! Әти әйткән Таңсылуны гына күрсәң дә... Ул, бәлки, үзенең бабасын да күрсәтер иде. Аны күрү өчен, Булат төн буе керфек какмаска, бер генә түгел, өч төнне йокысыз үткәрергә риза...

Булат, кулларын баш астына куеп, шулай уйланып ята. Тәрәзәнең югары өлгесеннән аңа агач башлары күренә, яңгыр юып киткән күк йөзеннән йолдызлар күз кыса... Чыпчык борыны озынлыгы җәйге төн озакламый эреп тарала да башлады. Менә соңгы йолдызны да таң җиле өреп сүндерде; очлаеп күккә үрелеп торган чыршы башына бер бәйләм кояш нуры килеп кунды. Булат, шыпырт кына торып, өстенә киенде дә мәче кебек кенә басып чыгып китте.

Гаҗәп. Таң вакытында урман тылсымлы бер төскә керә икән! Агач асларында куе күләгә, тау куышы кебек караңгы. Ә кояш төшкән урыннарда агачлар ачык яшел төстә. Һәр агачта, һәр ботакта — меңләгән чык бөртекләре. Аларның һәрберсе, күзләрнең явын алырлык булып, төрле төсләр белән балкый. Үләннәрдәге чыклар да бик кызык: кояш төшкән урында алан өсте күзгә кырау төшкән кебек ап-ак, ә күләгә җирдә — куе зәңгәр. Әйтерсең кемдер төн буе зәңгәр буяу сибеп йөргән!

Кичәге җылы яңгырдан соң беләү ташы[1] кебек шомарган юеш сукмакны яңгыр суалчаннары кисеп шадралаткан. Кая карама, алар казып чыгарган бөртек-бөртек кенә көпшәк туфрак өемнәре. Уйсурак урыннарда әле яңгыр суы кибеп тә өлгермәгән. Ә ботаклардан тып-тып тамчы тама, якадан агып, тәнне чиркандыра.

Сукмак буйлап бара торгач, Булат түм-түгәрәк алан читенә килеп чыкты. Тагын да эчкәрәк керергә кыймыйча, ул бер агачка аркасын сөяп чөмәшеп утырды. Утыруы булды, тәне оеп, күз кабаклары авыраеп китте...

---

[1] *Беләү ташы* — кечкенә кайрак.

Бермәлне якында гына челтер-челтер итеп чишмә челтерәп куйды. Юк, чишмә түгел икән. Зелпе куагы артында кемдер көлә:

— Һи-һи-һи... Әллә йоклап утыра инде?

— Юк ла, йокламыйм,— ди Булат.— Син үзең кем соң? Нигә көләсең?

— Мин Таңсылу.

— Син... син Карурман бабай кызымыни?— дип шатланып кычкыра Булат һәм тавыш ишетелгән якка йөгереп бара. Барса, беркем дә юк... Әлеге тавыш башка куак артыннан ишетелә.

— Һи-һи-һи...

Булат тагын шунда йөгерә. Менә тамаша! Кызый тагын юкка чыккан. Ә тавышы бөтенләй әллә кайдан, югарыдан яңгырап ишетелә. Булат, гаҗәпсенеп, башын күтәрә:

— Әй кызый, нигә миннән качасың?

— Качмыйм, мин биредә генә.

— Ә нигә агач башына мендең?

— Бөре эчендә яшь яфраклар шытканын тыңлыйм.

— Яфрак шытканын? Син шулай бөре эчендәге тавышны да ишетәсеңмени?

— Ник ишетмәскә! Тыңлыйсың килсә, мен бирегә.

Булат, ашыга-ашыга, юкә агачына үрмәли, ботактан ботакка күчә-күчә бик тиз очка ук менеп җитә. Тик... кайда соң ул Карурман кызы?

— Һи-һи-һи... Мин монда.

Менә могҗиза! Инде хәзер түбәннән дәшә. Әле генә шушы агач башында иде ләбаса! Күзгә күренмичә ничек төшә алды икән?

Булат, ботакларны аралап, түбәнгә карый, ничек кенә булса да шаян кызыйны күрергә чамалый... Әһә, әнә ул! Каен кәүсәсенә сарылып, колагын каенга куеп, нәрсәдер тыңлый.

— Әй кызый, мин сине күрдем. Каен артына качкансың,— ди Булат.

— Качмадым.

— Алайса, нишлисең анда?

— Кәүсә эчендә каен суы акканын тыңлыйм. Кил, син дә тыңла.

Булат, кабаланып, түбән төшә башлый. Бераз төшкәч, юан ботакка тотынып, туп-туры җиргә сикерә һәм, йөгереп

барып, элеге каенга колагын куя. Лэкин аңа үз йөрәгенең дөп-дөп тибүеннән башка бернәрсә дә ишетелми.

— Алдыйсың син мине, урман кызы,— ди Булат.

— Алдыйсың? Нәрсә дигән сүз соң ул? Мин ул сүзне белмим.

— Белмәсәң, менә белдерермен мин сиңа!

Булат, каен кәүсәсе артына үрелеп, шаян кызның чәченнән эләктереп ала.

— Әй, җибәр, авырттырасың! — дип пышылдый Таңсылу.

— Җибәрмирәк торсын әле!

Булат, каен кәүсәсен әйләнеп, Таңсылу торган якка чыга. Лэкин тагын могҗиза! Тагын беркем дә юк... Малай, тәмам аптырап, учын язып карый. Уч төбендә берничә каен яфрагы гына өзелеп калган...

«Менә ничек! Димәк... теләсә күренә, теләмәсә, шунда ук юкка да чыга ала,— дип уйлый Булат.— Миңа үпкәләгәндер дә инде. Чәченә шаярып кына ябышканымны каян белсен ул...»

Булат шулай дип уйларга да өлгерми, Таңсылу якында гына тагын көлеп җибәрә:

— Һи-һи-һи... Мин беләм, син усал малай түгел.

— Каян беләсең?

— Песнәкләр әйтте. Кыш көне ачыккан чакта син аларга җим сипкәнсең. Аннан соң Карурман бабай да әйтте. Әтиең белән сез аның җырларын яратасыз икән.

— Ә җыр яраткан кеше усал булмыймы?

— Җыр яраткан, урман-кырларны яраткан, кошларны кызганган кеше ничек инде начар булсын!

— Алайса, нигә син миңа күренмисең?

— Иң элек миңа энҗе сәйлән тезеп китер...

— Мин аны каян алыйм?

— Һи, әнә ич, аландагы һәр үләндә, һәр чәчәкнең керфегендә таң энҗесе. Тик тизрәк бул. Кояш күрсә, хәзер җыеп бетерә аларны...

Булат шунда ук алан уртасына йөгереп чыга да ромашка чәчәгендә җемелдәгән чык бөртегенә үрелә. Лэкин, ул килеп кагылганчы, чык бөртеге җиргә тама. Булат икенчесенә үрелә, анысы да бармак буйлап агып төшә. Өченчесе, юеш тап кына калдырып, уч төбенә җәелә. Азаплана торгач, тәмам хәлдән тая Булат. Ул узган җирдә чыклы үлән өстендә, куе яшел булып, нечкә аяк эзе сузылып кала. Аның аяклары гына түгел, җиңнәренә кадәр, чыланып, лач су була.

Шулвакыт алан читендә кемдер көрсенеп куя. Булат башын күтәреп караса, әннекәй генәм! Бөтенләй якында гына, әлеге каен агачы төбендә, Таңсылу басып тора! Нинди чибәр кызый! Йөзе алмагач чәчкәсе төсле алсу, чәчләре коңгырт кара. Дулкын-дулкын булып, бөдрәләнеп, иңнәренә төшкән! Яшел чигүле ап-ак күлмәк кигән. Ә күзләре... күзләре нинди! Һавага караса, алар ачык зәңгәр, урманга караса — коңгырт, ә чыклы үләнгә караса, чыклы карлыган кебек ялтырый башлыйлар... Менә Таңсылу Булатка таба борыла һәм, кулларын болгап, ниндидер ишарәләр ясый. Читкәрәк кит, янәсе, безгә артык якынлашырга ярамый...

Булат, урман кызыннан күзләрен ала алмыйча, әкрен генә чигенә башлый. Таңсылу да кузгала. Аның озын ак күлмәгенең итәге җиргә үк тиеп тора. Шуңа күрә ничек аяк атлаганы күренми. Елга өстендәге ак томан кебек шуып кына килә. Шунысы гаҗәп: ул узган җирдә бернинди дә эз калмый, бер генә үлән дә селкенми, чәчәкләрдән бер генә чык бөртеге дә төшми.

Менә ул агач күләгәсеннән кояш нурына чыга һәм шунда ук танымаслык булып үзгәрә дә куя. Коңгырт кара чәче алтын-сары төскә керә, өстендәге ак күлмәге дә кояш нурына маныла... Ул иелә-бөгелә үләннәрдән, чәчкә керфекләреннән чык бөртекләре җыеп ала да аларны, неп-нечкә пәрәвез җебенә тезеп, кат-кат итеп муенына тага. Таң энҗеләре шунда ук әллә нинди сихри нурлар белән җемелдәшә башлыйлар. Таңсылу өнсез калган Булатка карап елмая. Янәсе, миндәй чибәр кызны синең гомердә дә күргәнең юктыр әле... Шулай көязләнеп бер бөтерелгәннән соң, урман кызы, ак томан сыман, алан өстен бер әйләнә дә агачлар арасында күздән югала.

— Менә кыбырсык!— дип куя Булат.— Карурман бабай турында тәки оныттыра язды бит... Әй урман кызы, тукта әле...

Ләкин Таңсылу җавап бирми. Тик бөтенләй икенче юнәлештә сузып-сузып «тру-ту-ту!» дип кычкырган тавыш кына ишетелә. Бу тавыш Булатка бик таныш кебек тоела. Ул күзләрен ачып җибәрә... Караса, һаман шул баягы агач төбендә утыра.

Кояш шактый югары күтәрелгән, алан өстендә ак томан йөзә. Түгәрәк күл ягыннан быргы тавышы яңгырап ишетелә:

— Тру-ту-ту!.. Тру-ту-ту!..

Булатның башыннан «лагерь килгән» дигән шатлыклы уй чагылып уза. Лагерь килгән! Моңа кадәр тын гына яткан Түгәрәк күл буена быргы, барабан тавышлары килгән. Шат җырлар, ал галстуклар, кызыл байраклар, төнге учаклар килгән. Булат өчен бәхетле, күңелле көннәр килгән!

Булат утырган урыныннан сикереп торды һәм, куак асларына чума-чума, быргы тавышы килгән якка чапты.

Лагерь капкасы төбендә ике буш автобус тора. Ә пассажирлары лагерьга хуҗа булып та алганнар. Берәүләре таган атына, карусель әйләнә, икенче берәүләре яшел чирәм өстендә мүкәли, кайберәүләр туп тибеп йөри. Көлеш, кычкырыш, ыгы-зыгы, шау-шу...

Бу лагерь Казандагы бер заводныкы. Шуңа күрә анда ел саен диярлек бер үк эшчеләрнең балалары килә. Булат аларның күбесен таный. Әнә Кар бабай кебек юантык гәүдәле, зур башлы, кыска муенлы бер малай капкага таба йөгереп килә. Ул Кәли исемле. Аның артыннан куып килүче яшел чалбарлысы — Ваня. Ул, кулларын болгый-болгый, Булатка кычкыра:

— Әй Булатик, чыгарма Кәлине! Җибәрмә. Без тоткан еланны алып качты.

Булат, кулларын җәеп, капкага аркылы басты. Ләкин Кәли, җитез генә иелеп, аның кул астыннан шуып узды. Инде куып җитеп якасыннан эләктердем дигәндә, ялт итеп борылды да аяк астына ауды. Булат аңа абынып яшел чирәм өстенә мәтәлде. Арттан куып килүче башка малайлар Булат өстенә килеп өелделәр. Кәли шул арада сикереп торып куак астына чумды. Аны көчкә эзләп таптылар. Тагын кычкырыш, тагы шау-шу купты:

— Әнә ул, әнә-нә-нә! Юкә агачы артында!

— Тотыгыз, тот!

— Ваня, юлын кис!

Бу юлы Кәли ычкына алмады. Малайлар аны уратып алдылар да кесәләрен актара башладылар. Кәли карышып тормады. Йөгерә торгач, карышыр хәле калмаган иде инде.

— Туктагыз, малайлар. Үзем бирәм,— диде ул, мыш-мыш сулап.— Үзем бирәм... Җибәрегез кулны...

— Ай-яй хәйләкәр! Тагын качар иде бугай!

— Җир упсын, качмыйм... Кысмагыз беләкне. Еланны үтерәсез.

Малайлар аның кулларын җибәрделәр дә, шунда ук эләктереп алырга әзерләнеп, як-ягына бастылар. Кәли, күлмәк якасыннан кулын тыгып, сул җиңе эченнән уклау озынлыгы кап-кара елан тартып чыгарды. Елан, пружина кебек бөтерелеп, аның беләгенә уралды. Аларның тавышына йөгерешеп килгән бер төркем кызлар, куркынган чыпчыклар кебек чырылдашып, төрле якка сибелделәр.

— Әй тиләләр, курыкмагыз. Тузбаш бит ул, чага торган елан түгел. Менә карагыз, башында ике сары табы бар,— дип, еланын болгап кычкырды Кәли. Ләкин шул арада тузбаш аның кулыннан шуып төште дә, малайлар эләктереп алганчы, коры яфраклар астына кереп тә шылды.

— Тотыгыз, тот, әй ачык авызлар, ычкындырдыгыз бит,— дип кычкырды Кәли.

— Кара, кара! Үзе ычкындырды да безгә сылтый!

— Юри җибәрде ул аны.

— Бирегез кирәген, малайлар!

— Ботарлагыз!..

Шулвакыт Кәли лып итеп җиргә утырды да, болай да кып-кыска муенын җыерып, кулын күтәрде:

— Тсс! Шауламагыз! Хәзер бер фокус күрсәтәм! Менә күрәсезме, бу нәрсә?

— Нәрсә булсын, борчак!

— Борчак булса карап кына торыгыз!

Ул учындагы борчакны һавага чөйде һәм, калын иренле зур авызын ачып, борчакны тел өстенә төшерде дә голт итеп йотып та җибәрде.

— Йоттым. Хәзер менә тагын карагыз! Фукс-мукс, аллиһоп!

Кәли уң кулы белән үзенең җилкә тамырына шап итеп сукты. Сугуы булды, авызыннан ике юеш борчак килеп төште.

— Кызыкмы? Кызык булса, тагын күрсәтәм. Карагыз, бу нәрсә?

— Кульяулык.

— Бусы нәрсә?

— Шырпы.

— Шырпы булса карап торыгыз...

Кәли кульяулыгын җиргә җәеп салды, яулык уртасына шырпыны куйды, яулыкны, чит-читеннән тотып, дүрткә бөкләде.

— Йә, әйтегез, шырпы кайда?

— Яулык эчендә.

— Эчендә булса сындырыгыз! Йә, кайсыгыз сындыра?

Булат яулык аша шырпыны капшап тапты да урталай сындырды. Башка малайлар да тотып карадылар, сынуы хак булсын дип, шырпыны вак кисәкләргә турап бетерделәр. Шуннан соң Кәли, авыз эченнән нindидер тылсым укыган булып, яулыкка өрде:

— Фукс-мукс, әлли-һоп!

Кәли яулыкны сүткән иде, аның эченнән сынмаган шырпы килеп төште.

Малайлар тагын шаулаша башладылар.

— Тукта әле, тукта! Ничек эшләдең?

— Икмәктер, сынмаган!

— Хәрәмлисең. Уч төбендә икенче шырпы булган.

— Әйе, әйе. Кулында булган. Күрсәт әле тагын!

Кәли, болай да чепи күзләрен кысып, калын тавыш белән көлеп куйды:

— Хо-хо-хо! Күрсәтмирәк торсын. Бик күрәсегез килсә, миндә фокус бетәрлек түгел. Давай, дүрт кулъяулык бирегез.

Малайлар аңа унлап кулъяулык суздылар. Кәли аларны ашыкмыйча гына очын очка төйнәп тезә башлады.

Ялгап бетергәч, ике башыннан тотып тартты да түгәрәкләнеп тезелгән иптәшләренә күрсәтте:

— Күрдеңме?

— Күрдем.

— Барыгыз да күрдегезме?

— Күрдек.

— Алайса, бүтән күрә алмассыз!

Кәли яулыкларны, бөтәрләп, кесәсенә тыкты. Малайлар, шау-гөр килеп, аның өстенә өелделәр, кесәләрен актарырга керештеләр. Бер кесәсеннән шыбырдап борчак коелды, әллә нинди тимер-томырлар, шөрепләр чәчелеп китте.

Икенче кесә төпсез булып чыкты. Ваня кулын тыккач, Кәли тузбаш кебек боргалана башлады:

— Хи-хи-хи... Җибәр, Ванька, кытыкны китерәсең! Җибәр!

— Җибәрми торсын. Яулыкларны кая куйдың?

Шулвакыт Кәли әллә ничек кенә малайлар кулыннан ычкынды да сикереп торды. Аның чалбар балагыннан кулъяулыклар килеп төште. Иптәшләре яулыкларны бүлешергә тотындылар, шул арада Кәли юкка чыкты.

— Ә, малайлар, качкан бит!

— Куыгыз! Урра!

— Әллә кая китә алмас! Каршысына төшегез!

— Уратып алыгыз!

Шулвакыт кемдер Булатның аягыннан тартты. Борылып караса — Кәли! Муенын җыерып, артыш куагы артында утыра:

— Шаулама, малай, кил! Алар — мине куып йөрсеннәр әле, мин сиңа фокус өйрәтим...

Малайлар ераклашкач, куак артыннан чыкты да бармагы белән Булатка төртеп көлеп җибәрде:

— Хо-хо-хо! Фокус өйрәнәсең килә инде синең, ә?

— Килә шул.

— Акылың алтын икән! Өйрәнмирәк тор әле. Өйрәнәсең килсә, бергә — бер...

— Мин сиңа урман кызын күрсәтермен...

— Нинди урман кызы? Мин аларны күреп туйган. Әнә чырык-чырык көләләр... Бик кирәкләре бар иде...

— Юк, алар түгел. Алар — лагерь кызлары бит. Ә мин күргәне — чын урман кызы. Бөре эчендә яфрак шытканын, кәүсә эчендә каен суы акканын тыңлый белә. Әгәр теләсә, синең башыңдагы уйларыңны да ишетә...

— Хо-хо-хо! Алдарсың инде Кәли абзаңны!

— Җир упсын, алдамыйм.

— Узган ел да син миңа поши эзе дип сыер эзе күрсәттең.

— Сыер эзе алай озынча булмый...

— Йә, ярый. Урман кызын күрсәтсәң, борчаклы фокусны өйрәтәм...

— Юк, икесен дә...

— Йә, ярый, килештек. Ну, син аларны беркемгә дә өйрәтмисең! Килештекме?

— Килештек.

Икенче көнне Булат белән Кәли, таңнан торып, әлеге алан читенә килеп яшеренделәр.

— Әнә шунда гына карап тор,— дип пышылдады Булат,— урман кызы чык бөртекләреннән сәйлән тезәргә килер...

Алар, сулыш алырга да кыймыйча, бик озак яттылар. Инде үләннәрдән чыклар да кипте, кояш та шактый күтәрелде. Төрле төстәге күбәләкләр, чәчәктән чәчәккә кунып, аланда куышып уйный башладылар. Ләкин урман кызы күренмәде. Кәли, түземсезләнеп, Булатның кабыргасына төртте:

— Йә, нишләп чыкмый?

— Тагын бераз көтик инде.

Нәкъ шулвакыт лагерьда «подъём» сигналы уйнадылар. Кәли, йокысыннан уянган кебек сискәнеп, башын күтәрде. Ул озак кына Булатның йөзенә текәлеп торды да кинәт бер карарга килгәндәй әйтеп куйды:

— Булмаса булган, бер фокус өйрәтим үзеңә!

— Кайсысын?

— Яңаны. Син аны белмисең әле. Ябагадан ялкын чыкканын күргәнең бармы?

Ул кесәсеннән нечкә резин тасмага тагылган кечкенә кызыл туп алды.

— Настоящий ябага туп. Язгы каникул вакытында авылга әбиләргә баргач, коба сыер йонынннан əвәләп ясадым. Тагын да зуррак итә идем дә, сыерның ябагасын саесканнар йолкып бетергән... Әйдә, ничава, болай да ярый ул. Карап кына тор. Шушы тупның менә шушы төшеннән ялт итеп ут күренер.

Кәли резин тасманы сузды да кинәт ычкындырып җибәрде. Туп, шундый каты итеп, Булатның күзенә килеп бәрелде, малайның күзеннән аллы-гөлле утлар чәчрәп киткәндәй булды.

— Хо-хо-хо! Менә сиңа фукс-мукс,— дип шаркылдап көлде Кәли,— урман кызын күрсәткәнең өчен булыр. Кабат алдамассың мине! Синең аркада иртәнге аштан коры калдым.

Ул, үзләре килгән сукмак буйлап, лагерьга таба йөгерде. Ә Булат шул урынында утырып калды. Аның күзеннән өзлексез яшь тәгәри иде. Авыртудан да бигрәк «ялганчы» исемен күтәргәнгә күңеле әрни иде аның.

Булат яшь белән тулы күзләрен ачып җибәрде... Караса, Таңсылу әллә кайда, аланның аргы башында ботаклары сынган миләш агачын кочаклап тора. Башы иелгән, йөзе сагышлы. Булатка карап, моңсу гына елмаеп куя да миләш кәүсәсен сыйпап назларга керешә... Их, менә хәзер күрсәтәсе иде аны Кәлигә. Булат, ашыга-ашыга, күз яшьләрен сөртте. Ләкин миләш агачы төбендә урман кызы юк иде инде.

Булат, сикереп торып, лагерьга чапты. Ашыга-ашыга койма аша кергәндә, чалбар балагы эләкте дә койма буенда фотоаппарат тотып яткан Кәли өстенә мәтәлеп төште.

— Тагын синмени әле бу? — дип кычкырып җибәрде Кәли. Кадрны боздырдың бит, тиле!

— Ә син, син нәрсә төшерә идең соң?

— Ашханәне төшерәм. Әнә бит, Ванялар котлет ашап утыра,— дип, телен ялмап куйды Кәли.

— Ә син ник бармыйсың?

— Барырсың! Тәрәзәдән төшеп, урман кызы карап йөргәнеңне вожатый апа белсә... Синең аркаңда көндезге ашка кадәр ураза тотасы була инде...

— Беләсеңме, Кәли... Син киткәч тә, урман кызы килде. Әйдә, барабыз...

Кәли ялт итеп Булат ягына борылды да яткан урыныннан сикереп торды.

— Ике күздән дә ут чыгара торган фукс-мукс өйрәнәсең киләме? Мин андыен да беләм!

Кәли, бик кызыклы нәрсә уйлап тапкан кебек, телен шартлатып куйды, кечкенә күзләрен челт-челт йомгалап, Булатка якынайды:

— Әйт дөресен, алдамыйсыңмы? Алдамасаң, менә сиңа аппарат! Үзең генә барасың да кәртечкәгә төшереп кайтасың! Хо-хо-хо! Нигә телсез калдың? Тотылдымы ялганың!

Иптәшенең авызыннан шундый сүз чыгуга, Булат бер карарга килде:

— Китер. Плёнкасы бармы?

— Сиңа җитәрлек. Өч кенә кадр төшерелгән...

Булат юлсыз, сукмаксыз җирдән тагын әлеге түгәрәк алан ягына йөгерде. Кинәт ул, үзенең каршысында шау чәчәккә күмелгән ике гөләп куагы күреп, шып туктады... Берсенең чәчәкләре гап-гади, ә икенчесенеке бик гаҗәп! Сабый бала калфагы зурлыгында. Таҗ яфраклары ялкын телләре кебек янып тора, серкәләре нәкъ саф алтындай ялтырый... Үзеннән әллә нинди башларны әйләндерә торган хуш ис бөркелә.

Ирексездән Булатның куллары чәчәккә үрелделәр. Ләкин, ул килеп кагылуга, чәчәк зур кызыл күбәләк булып күтәрелде дә икенче бер куакка күчеп утырды. Утыруы булды, яңадан шундый ук гөләп чәчәгенә әверелде. Булат тагын аңа якынлашты, тагын сакланып кына кулларын сузды. Гөләп куагы салмак кына чайкалып куйды, тураеп, башын читкә борды, һәм тылсымлы чәчәк, тагын куактан аерылып, күбәләк булып очты.

Булат, сихерләнгән кебек, аның артыннан йөгерде. Чәчәк-күбәләк, куактан куакка, агачтан агачка куып, бик озак очып барды, үлән асларына кереп качты, биеккә-биеккә, зәңгәр һаваларга күтәрелде, тагын түбән төште, тагын урман

аланнары буйлап Булатны үчектереп йөрде. Йөгерә торгач, Булат тәмам хәлдән тайды... Тәмам өмет өзеп, киселгән агач төбенә утырды. Ә күбәләк әйтерсең шуны гына көткән, Булатның нәкъ каршысына ук килеп төште дә кунды... Инде менә кулны гына сузасы да канатыннан эләктереп кенә аласы. Ләкин Булат, кул сузарга түгел, хәтта сулыш алырга да кыймыйча, тәп башына берегеп үскәндәй, тик утыра. Әз генә селкенсә дә, тылсымлы күбәләк тагын очып китәр дип курка.

Бик озак шулай утырганнан соң, ниһаять, батырлыгын җыеп, ул башындагы кепкасын салды да ялт итеп күбәләк өстенә каплады.

— Вәссәлам! Инде хәзер ычкынып кара!

Булат, сакланып кына, кепкасының бер читен күтәреп карады... Кепка астында тапталып ауган сарут кыякларыннан башка нәрсә юк иде...

Нәкъ шулчакны таныш тавыш яңгырап ишетелде:

— Һи-һи-һи... Һи-һи-һи!..

— Карурман бабай кызы! Син шаяртасыңмы?— дип кычкырып җибәрде Булат.

— Бүген урманда үсемлекләр ярышы бара,— дип җавап бирде Таңсылу.— Кояш күк түренә менеп җиткәнче кайсы үлән иң зур үсә, шул җиңүче була.

Булат башын күтәреп караса, каршысында ниндидер алан, уртасына, бер-бере белән җитәкләшеп, нарат малайлары түгәрәкләнеп баскан. Алар әкрен генә чайкалалар, яшел ботакларын селкеп, тавышсыз гына кул чабалар. Әһә, урман кызы да шунда! Нарат малайлары өстеннән аның башындагы зур кызыл бантигы күренә. Юк, бантик түгел икән. Баягы уткүбәләк Таңсылуның башына кунган. Ул да үләннәр ярышын карый, ул да үзенчә кул чаба, канатларын җилпи...

Кәлинең баягы сүзләре Булатның хәтеренә килде дә, ул бер-бер артлы өч кадр төшереп алды. Тик дүртенче кат аппаратын төзәгәндә, урман кызы җир астына кереп киткәндәй юкка чыкты.

— Качсаң качарсың. Сурәтең камерага эләккәч, әллә кая бара алмассың инде,— дип көлде Булат.

Баядан бирле шул тирәдә бер кош чыркылдап йөри иде. Калган кадрларына Булат шуны төшереп алды... Инде хәзер кайтырга да була иде. Тик менә юлны ничек табасы? Теге күбәләк артыннан йөри торгач, әллә кайларга китеп адашты бит ул.

Тирә-ягына ныклабрак караса, тагын кызык хәл! Якында гына ботаклары сынган әлеге миләш агачы үсеп утыра, әнә таныш каен, менә таныш сукмак! Озакламый агачлар арасыннан лагерь да күренде...

* * *

Кичен Кәли, вожатыйдан рөхсәт сорап, Булатларга керде. Алар, чолан тәрәзәләрен томалап, плёнка проявить иттеләр. Мәктәптә түгәреккә йөреп, бу эшне Булат яхшы өйрәнгән иде. Иң элек плёнканы өч-дүрт минут чамасы проявитель эремәсендә тотасың, аннан соң чиста суда чайкап аласың да гидросульфид эремәсенә саласың. Анда ул егерме минут чамасы торырга тиеш. Иң теңкәгә тигәне әнә шул егерме минут инде. Нәрсә булыр, нәрсә чыгар дип, караңгы чоланда көтеп утырганда, егерме минут түгел, егерме сәгать булып тоела ул. Чөкердәшеп утырырга янында иптәшең булса, тагын бер хәл. Алай дисәң, иптәшнең дә төрлесе була бит. Кәли ул канга тоз сибәргә генә белә: гидросульфид савытының өстен каплап куйды да, кесә фонарен яндырып, Булатның күзенә үк китереп терәде.

— Алдалаган булсаң, беләсеңме мин сиңа нәрсә өйрәтәм? Үгез догасы! Синең аны ишеткәнең дә юктыр әле. Аның янында ябагадан ут чыгара торган фукс-мукс чүп кенә! Тфү! Түшәм аркылы йолдыз саный беләсеңме? Самавыр торбасы белән бер чүмеч су гына китер, хәзер үк күрсәтәм...

Ул тагын әллә нинди тузга язмаган фокуслар сөйләп бетерде, тагын алдаган булсаң дип, Булатка әллә нинди җәзалар уйлап куйды.

Аның тыкылдавын тыңлап утыра торгач, шактый вакыт узды. Ниһаять, Кәли плёнканы, гидросульфид эремәсеннән алып, салкын суда юды да фонарь яктысына китерде. Булат та утырган урыныннан сикереп торып муенын сузды... Әнә агач атка атланган бер кыз, әнә туп тибеп йөрүче малайлар, әнә ашханә... Болары — Кәли төшергән рәсемнәр. Булат аларына рәтләп күз дә салмады. Ләкин үзенә таныш түгәрәк алан рәсемен күрүгә, аның күз аллары караңгыланып китте. Шул ук чәчәкле алан, шул ук яшь наратлар... Хәтта ут-күбәләк тә шундагы бер агачта утыра. Барысы да бик ачык, барысы да үз урынында. Хәтта урман кызы утырган агач төбе дә аермачык күренә. Тик Таңсылу гына беркайда да юк иде...

Икенче көнне лагерьда дружина сборы булды. Ачык тәрәзәдән көннең көнозын кояш нурлары, чәчәк исләре һәм пионерларның шат җырлары бөркелеп торды. Моңа кадәр отряд сборларын да калдырмый торган Булат бу юлы өйдән дә чыкмады. Ул иптәшләренең күзенә күренергә ояла иде.

«Кәли бөтен лагерьга сөйләгәндер инде. Ялганчы дип күзне дә ачырмаслар»,— дип уйлады ул.

Ләкин кичкә таба Кәли үзе атылып килеп керде. Ул, кыска муенлы зур башын гадәтенчә Булатның маңгаена ук терәп, ашыга-ашыга сөйләп китте:

— Ә син нигә кичә әйтмәдең? Шәп булган бит, парин! Соңгы кадрларыңны кәгазьгә төшергәч, күзләрем тонды. Әле берәүгә дә күрсәтмәдем. Мә, үзең генә кара!..

Кәли куеныннан зур-зур өч фото чыгарып өстәлгә куйды. Булат аларны шунда ук таныды. Шул! Кичә уйнап кына төшереп алган теге кошчык. Әйе, нәкъ үзе! Икенче рәсемгә карагач, Булат куркып китте, ә өченчесен күргәч, кычкырып көлеп җибәрде... Рәсемнәрне әле яңа гына күргән кебек, Кәли дә рәхәтләнеп көлде. Көлде-көлде дә, бик зур ачыш ясаган кебек, кинәт шып тукталып, Булатка карады:

— Беләсеңме нәрсә, Булат парин,— диде ул,— әйдә бер кызык ясыйбыз. Бу рәсемнәрне бер кәгазьгә ябыштырыйк та фотогазета чыгарыйк.

— Әйе шул, әйдә, шулай итик!

Алар газетага исем таба алмыйча бик озак баш ваттылар. Аның каравы менә дигән исем табылды.

Икенче көнне иртән «Яшь натуралист» почмагы каршысына бөтен лагерь җыелды. Анда «Күңел күзе» исемле кечкенә генә фотогазета эленгән иде. Газетада өч рәсем. Беренче рәсемдә — әлеге шул кошчык. Ул бер куакның иң түбәнге ботагына кунган да, канатларын җәеп, авызын зур ачып түбәнгә карап тора. Нәрсәгәдер борчылганы, нәрсәдәндер бик нык курыкканы әллә каян күренә... Ә җирдә кап-кара агулы елан. Гаҗәп! Анысын Булат бөтенләй күрмәгән иде... Икенче рәсемдә тагын да кызыграк хәл. Кошчык башка ботакка күчеп утырган. Бераз гына читтәрәк аның оясы. Ояда әле каурые да чыкмаган дүрт кош баласы. Куак астыннан бер керпе чыгып килә. Елан, авызыннан ике япьле угын чыгарып, керпегә ташланырга тора... Өченче рәсемдә — кошчык, тынычланып, балалары янына барып утырган. Ә керпе бик тәмләп кенә елан ите ашап утыра.

Газета тирәсендә җыелган балалар шау-гәр киләләр. Көлешәләр. Кәли барысыннан да күбрәк такылдый:

— Керпесен генә кара син аның, керпесен... Кәпрәйсә дә җае бар шул! Кош балаларын тәки коткарган бит,— дип, калын тавыш белән шаркылдап көлә.— Кем төшереп алган икән?

Башкаларның да шуны беләсе килә. «Яшь натуралист»ларның күзләре ут яна. Алар бер-берсенә көнләшебрәк карыйлар. Яшермә, янәсе, беләбез, синең эшең! Ләкин берәү дә Булат эшедер дип уйламый. Ә Булат үзе бәхәсләргә катнашмый, тыйнак кына елмаеп, бер читтә басып тора.

Өченче көнне иртән «Күңел күзе» янына тагын бөтен лагерь җыйналды. Чөнки анда яңа фото өстәлгән иде... Кечкенә генә кырмыска түмгәге янында эшләпә кадәр ал гөмбә. Гөмбәнең читләре югары кайтарылып, түбәсе таш чынаяк кебек чокыраеп калган да, шунда мөлдерәмә булып яңгыр суы тулган. Кечкенә генә ямь-яшел үлән бакасы шул бассейнда рәхәтләнеп су коена. Гөмбә янында ук үскән кыңгырау чәчәгенә ике кырмыска менгән. Алар баканың су коенганын күзәтеп торалар...

Шуннан соң «Күңел күзе»нә һәр иртәдә яңа рәсем өстәлә башлады. Тик бу серле күзәтченең кем икәнен беркем дә белми иде әле. Сернең ачылуы да кызык кына булды.

Шулай беркөнне Булат белән Кәли соңарып кына газета янына чыктылар, ни күзләре белән күрсеннәр: газетага башка бөтен рәсемнәрдән дә зуррак яңа рәсем өстәлгән. Рәсемдә Кәли һәм Булат!.. Кәли стена буена тезләнгән, ә Булат аның җилкәсенә баскан да газетага ниндидер рәсем беркетеп маташа... Эшнең нәрсәдә икәнен алар шунда ук төшенеп алдылар: кемдер алардан хәйләкәррәк булып чыккан. Сагалап торган да, үзләрен фотога төшереп, стенага элгән...

— Эш харап бит, парин, серне ачканнар. Әйдә тизрәк кубарып ташлыйк,— диде Кәли һәм ашыгып стена буена тезләнде. Булат аның җилкәсенә менеп басарга да өлгермәде, бөтен почмаклардан, куак артларыннан эчләре катып көлә-көлә балалар йөгерешеп чыктылар. Алар Кәли белән Булатны бөтереп алдылар да күтәреп һавага чөйделәр...

Лагерьда беренче сменаның соңгы көннәре якынлашты. Кәли белән Булат аерылмас дуслар булып киткәннәр иде инде. Лагерь ябылу тантанасы алдыннан алар соңгы мәртәбә

бергәләп урманга чыгарга булдылар. Йөри торгач, алар бер бик матур чишмә буена килеп чыктылар. Чишмә ап-ак ташлар арасыннан челтер-челтер итеп агып чыга. Җил исеп куйганда, агач яфраклары арасыннан нурлар төшә дә, су өстендә кояш күбәләкләре уйный. Чишмә өстенә зур бер карлыган куагы җәелеп үскән. Аның берничә тәлгәше, суга манчылып, чишмә акканда әкрен генә тирбәлеп тора. Кәли шушы күренештән күзләрен ала алмыйча бик озак карап торды да, чын күңеленнән сокланып:

— Ух, нинди матур,— дип куйды.

Аның авызыннан шул сүз чыгуга, якында гына кемдер чишмә челтерәгәндәй саф тавыш белән көлеп җибәрде:

— Һи-һи-һи...

Малайлар тавыш килгән якка йөгерделәр. Анда беркем дә юк иде. Тик әлеге чишмәдән дә матуррак икенче бер чишмә генә гөлдер-гөлдер агып ята иде.

Кәли белән Булат, аптырашып, бер-берсенә карашып алдылар. Шулвакыт кайдандыр ялкын кебек җитез бер тиен атылып чыкты да, каршыдагы агач ботагына утырып, алгы тәпиләре белән битен юа башлады.

— Төшереп ал тизрәк, Булат! — дип пышылдады Кәли.

Ләкин шул арада тиен икенче агачка, аннан өченчесенә, дүртенчесенә сикерде.

Ул үзен рәсемгә төшерергә һич ирек бирми, ләкин артык ерак та китми. Малайларны алга әйдәгән кебек, агачтан агачка сикереп һаман бара, һаман урман түренә ераграк керә. Менә ул Кәли белән Булатны бер алан читенә китереп җиткерә дә үзе кинәт юкка чыга.

Менә кояш кечкенә генә болыт артына кереп капланды. Болыт шәүләсе, ала-тилә күләгә ясап, алан өстеннән шуып узды. Бил тиңентен кәрешкәле, сарутлы, кыңгырау чәчәкле түгәрәк алан буйлап вак-вак дулкыннар йөгерешә. Әллә кайдан гына килеп чыккан дуамал җил агач башларына орылып-бәрелеп үтте. Моңа кадәр йокымсырап утырган җилбәзәк усаклар дерт итеп уяндылар да бөтен урманга шаулаша башладылар, пышы-пышы килеп, тынгысыз җилнең гайбәтен саттылар...

Ә чыршы, усаклардан күп биек булса да, мондый гына җилне санга сукмады. Очлы башын алга-артка чайкаштырып, борын эченнән генә гамьсез гүелдәп утыра бирде:

— Гү-ү... гү-ү-ү...

Тагын бераздан карт имән уянды. Ул җилбәзәк усакларның гауга күтәрүләрен ошатмады. Ябалдаш башын әкрен генә калкытып, йөнтәс кашлары астыннан: «Җитәр сезгә, шыбырдыклар»,— дигән кебек усал гына карап куйды да яңадан күзләрен йомды. Усаклар шунда ук: «Тс-с! Ш-ш-ш»,— дип, бер-берсен кисәтә башладылар.

Булатның йөрәге дөп-дөп тибәргә тотынды. Ул, түземсезләнеп, Карурман бабайның җыр башлавын көтә иде.

Болыттан төшкән ертык-портык күләгә кисәге узып китте, ләкин тиздән кояш икенче болыт астына керде. Җил көчәйде, карт имәннең йокысы тәмам бүленде. Җилбәзәк усаклар яңадан шау-шу кубардылар... Кинәт урман караңгыланып китте. Әллә кайда, еракта-еракта, тонык кына булып күк күкрәде. Урмандагы бөтен агачлар, дәррәү кубып, берсен берсе бүлә-бүлә шаулашырга, ухылдашырга керештеләр. Кайдадыр шатыр-шотыр килеп ботаклар сынды, агачлар ауды, сәер кошлар кычкырган, ерткычлар улаган кебек булды. Һәм кинәт... ул тавышлар, барысы бергә кушылып, искиткеч моңлы бер көйгә әверелделәр... Бу көйдә урман шаулавы да, күк күкрәве дә, чишмәләр челтерәве дә бар иде. Бу көйгә тагын әллә кайдан рояль аккордлары, курай моңнары... тагын әллә нинди авазлар кушылды.

Кәли дустының беләгеннән кысып тотты. Аның күзләре зур булып ачылган, калын иреннәре кысылып, юка гына булып калган, йөзе агарынып киткән иде. Ул аланның икенче ягына ымлап пышылдый:

— Булат! Кем ул анда? Син күрәсеңме?— ди.

Булат борылып караса, ни күрсен! Аланның аргы ягындагы йөзәр еллык агачлар арасында агачлар кебек үк зур, шундый ук юан бер бабай басып тора. Аның куе яшел сакалы биленә җиткән, озын чәчләре дә, җилкәсенә төшеп, сакалына кушылган. Үзе мәһабәт тә, әллә ничек бик куркыныч та... Юан имән ботакларына охшаган зур кулларын бер югары күтәрә, бер түбән төшерә, уңга-сулга селтәп җибәрә, кискен хәрәкәтләр белән башын чайкый, сакалын селки. Аның хәрәкәтләренә буйсынып, урман җыры тагын да үсә, ныгый, дәһшәтле бер көч белән яңгырый башлый. Малайларның йөрәкләре ярылырга җитешеп тибә... Һәм алар, сүз берләшкән кебек, кинәт борылып, артка-алга карамыйча лагерь ягына йөгерәләр...

* * *

Кайтып җитәрәк аларга Газизулла абзый каршы очрады.

— Сез кая югалдыгыз, малай актыклары,— диде ул, борчылган тавыш белән.— Күрмисезмени, әнә нинди гарасат килә?!

Малайлар, бер-берсен бүлә-бүлә, үзләрен куркыткан Карурман бабай турында сөйләп бирделәр.

Газизулла абый, сәер генә елмаеп, балаларны тыңлап торды да рәхәтләнеп, гөлдерәтеп көлеп җибәрде:

— Юк, балалар, урманда сез куркырлык бернәрсә дә юк. Шатланыгыз гына, сезнең күңел күзләрегез ачылган. Күңел күзе чыклы алан өстеннән күтәрелгән ак томанны да гүзәл урман кызы итеп күрә, карт имәнне дә серле дирижёрга, җырчы Карурманга охшата. Менә хәзер минем дә күңел тыныч инде. Сез Карурман җырын ишеткәнсез. Кабат беркайчан да ул сезнең күңелегездән чыкмас. Саф күңелле кеше булып үсәрсез.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Хикәя нәрсә турында?» дигән сорауга күбегез, шикләнмичә: «Табигатькә мәхәббәт турында» дип җавап бирәчәк.

— Табигать матурлыгы турында!

— Урман матурлыгы турында,— диючеләр дә булыр.

Укып чыгу белән күзгә ташланган тема шул, әлбәттә. Матурлык. Ләкин табигатьне Булат бер төрле, ә Кәли башкача күрә. Һәрхәлдә, башта башкача күрә. Димәк, табигать матурлыгы нинди күз белән карауга бәйле икән.

Табигатьне хикәядә Булатның әнисе, әтисе, Булат үзе һәм Кәли ничек күрәләр?

2. Персонажлар табигатьне ничек күрә дип әйтелә генә. Чынлыкта исә аларга урманны, андагы кошлар сайравын, күбәләк-чәчәкләрне автор Габделхәй Сабитов абыегыз күрсәтә һәм ишеттерә.

Яфрак бөресе эченә дә керә, чыктан энҗеләрне дә ул тезә, кәүсә эчендә каен суы акканын да ул тыңлый. Аның урманында үләннәр ярыша-ярыша үсәләр, каен малайлары кулларына тотынышып уйныйлар. Гөмбә чокырын ванна итеп, су өстендәге нурларны күбәләк итеп күрү өчен һәм урманның мең яктан ишетелгән мең төрле тавышын бер җыр итеп тыңлау өчен, бик тә ярата белергә кирәк. **Матурлык бит ул аны күргән кешенең мәхәббәтенә бизәлеп кенә матур була.** Урман матурлыгында да без Габделхәй Сабитов абыегызның күңел матурлыгын күрәбез. Шуңа күрә хикәянең темасы да беркадәр үзгәрергә тиеш. Кабатлап сорыйк: бу әсәр нәрсә турында?

3. Әгәр дә хикәя табигать һәм ул тудырган хис турында дисәк, андагы зур бер вакыйганы төшереп калдырган булыр идек. Хикәядә Кәли белән бәйле вакыйга да бар бит әле.

Кәли вакыйгасы аша автор үзенең фикерен әйтә. Автор фикерен табу өчен, Кәли турында мөмкин кадәр тулырак итеп сөйләргә кирәк. Кәли башта һәм соңыннан нинди? Нигә бик тиз төзәлә?

4. Авторның Кәли вакыйгасы аша әйткән фикерен сөйләгез.

5. Бу хикәягә дә үзегез йомгак уйлап табыгыз. Хикәяне ничек тәмамлар идегез?

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайны сез яхшы беләсез. Аның берсеннән-берсе гүзәлрәк шигырьләрен укыдыгыз. Бала чагы белән таныштыгыз. Шагыйрьнең бала чагы моңлы да, фаҗигале дә, шатлыклы да. Шул балачак аны шагыйрь итеп тәрбияләгән. Бөек кешеләрнең тормышы белән танышу һәрвакыт зур кызыксыну тудыра. Бу тормыштагы һәр вакыйга безгә серле, күп мәгънәле булып тоела.

Бала чагының бер өлеше турында Габдулла Тукай үзе яза. Ул бик яшьли үлеп китә. Шуңа күрә тормышының дәвамын язарга өлгерми.

«Исемдә калганнар» әсәренең ничек тәмамланганын хәтерегезгә төшерегез. Габдулланы ерак та яшәүче туганы Газизә апасы янына алып китәләр.

Шуннан соң ниләр була?

Бу хакта язучы Әхмәт Фәйзи үзенең «Кечкенә Апуш» исемле романында яза. Романны кыскартып, Тукайның Җаек шәһәренә килеп җитүеннән башлап китик.

Әхмәт Фәйзи

Кечкенә Апуш

I

...Ниһаять, Казаннан чыкканга унсигез тәүлек булды дигәндә, юлчылар Казан тракты белән борынгы Җаек шәһәренә килеп керделәр.

II

Габдулланы Сапый абзый иң элек үз өенә алып кайтты. Бу — Җаекның читендәрәк бер тыкрыкта читән коймалы йортта эче-тышы белән җыйнак кына бер катлы агач өй иде.

Хуҗаларның кайтып төшүе өйдә биниһая ыгы-зыгы кузгатты. Әллә нинди карчыклар, яшь кенә кызлар һәм зур киез итек кигән бер аксак малай, чыр-чу килеп, аларны каршы алдылар. Сапый абзый, өйгә килеп керү белән:

— Җитәрлек якмагансыз. Болай буламыни? Өстәргә кирәк,— дип боерык бирде.

Алгы якта тышкы ишекнең шыгырдап ачылуы һәм кемдер килеп керүе ишетелде. Ишек төбендә кемнәрдер чышпыш сөйләшеп алдылар, аннан соң Хәят апа:

— Әйдә, Газизә җаным, түрдән уз! — диде.

Газизә дип дәшелгәне басынкы гына кызлар тавышы белән сөйли башлады:

— Рәхмәт, узып тормыйм, кайтканнарын күреп, кереп әйттеләр. Ашыга-ашыга килеп җиттем. Минем энекәш...

Габдулла Газизәнең үз апасы икәнлегенә төшенде һәм тиз генә ал якка йөгереп чыкты. Башыннан ук чапан бөркәнгән һәм буйга җиткән кыз зур кара күзләре белән Габдуллага карап елмайды һәм чапан астыннан ике кулын чыгарып, аңа сузды.

— Апаң бу синең, Габдулла, күреш!— диде Хәят апа.

Апа белән эне бер-берсен танымый гына күрештеләр, аталары үлеп, Сак белән Сок шикелле, Кушлавычтан икесе ике якка аерылып киткәндә, Газизәгә җиде-сигез яшь, ә Габдулла дүрт-биш айлык имчәк баласы гына иде бит! Шуннан соң ун ел узып киткән! Язмыш аларны икесен ике якта хәбәрсезнисез куып йөртте-йөртте дә, менә хәзер генә алар Җаекта олау йөртүче вак сәүдәгәр Сафиулла абзыйның бусагасында очраштылар!

Габдулла, киенеп алып, апасы белән урамга чыкканда, караңгы төшеп җиткән, шуның өстенә, җиңелчә генә буранлап, ябалак кар ява иде.

Госмановлар йортына, чаттан борылып, урам аша гына чыгасы икән, эне белән апа озак бармадылар, асты таш, өсте агач, аслы-өсле җидешәр тәрәзәсе белән урамга караган йортның таш капкасыннан кереп, сары буяулы баскычтан өйнең өске катына менеп киттеләр.

III

Апасы белән Габдулла биек түшәмле һәм берничә бүлмәле зур гына өйгә килеп керделәр. Көн җылы булуга карамастан, өй эссе итеп ягылган һәм пешеп чыккан итле токмач исе аңкып тора иде. Габдулла нәкъ аш вакытына тап булган икән, бүлмәләрдә кашык-аяк шалтыраган тавышлар ишетелеп тора, хатын-кыз, савыт-саба күтәреп, ыгы-зыгы килеп йөри.

Ул ара булмады, чаршаулы ишектән урта буйлы, тулы гәүдәле, түгәрәк йөзле, бала итәкле күлмәк өстеннән күгелҗем төстә хәтфә камзул кигән ягымлы гына хатын чыкты.

— Күреш дәү апаң белән,— дип, Газизә Габдулланың җиңеннән тартты. Габдулла дәү апасына ике кулын сузды.

— Зур шәкерт икән, гомерле генә була күрсен, бәрәкәтле аяклары белән килсен,— дип каршы алды дәү апа һәм Газизәгә Габдулланы чишендерергә булышты. Ул арада бүлмәдән тагын кемнәрдер чыкты һәм, түбәнге каттан булса кирәк, керле генә ак алъяпкыч япкан бер яшь хатын килеп керде. Алар һәммәсе Габдулланы кызыксынып күзәтергә тотындылар. Габдулла аларны күреп бетерергә өлгермәде, дәү апа аны урта ишек янына алып килде һәм, чаршауны ачып, эчтәгеләргә күренми генә дәште:

— Син, монда кара әле, менә шәкертебез килеп төште...

Һәм ул Габдулланы, аркасыннан җиңел генә этәреп, бүлмәгә кертеп җибәрде. Арттан чаршау ябылды, һәм Габдулла стеналарына чиккән намазлыклар, сөлгеләр, пыялаланган шәмаилләр эленгән, зур асылмалы лампа белән яктыртылган көзгеле бүлмәдә әллә нинди өч ят кеше алдында басып калды. Алар өстәл тирәсендә утырган килеш, ашауларыннан туктап, Габдуллага карадылар. Габдулла бераз каушап китте.

Беренче булып зур гына борынлы, җирән мыеклы кеше дәште:

— Ә-ә-ә! Каениш бу минем, каениш! Казан кунагы! Йә, кил, күрешик!

Алар ике кулларын сузышып күрештеләр. Җизнәсенең елмаеп торган ягымлы йөзен күргәч, Габдулланың каушавы бетте.

Аннан соң Габдулланы чыбылдыклы бүлмәгә алып керделәр. Бу бүлмәнең ике почмагында зур-зур яшел калай сандыклар өстенә кат-кат итеп көрпәләр һәм түшәкләр өелгән, лампасы теге бүлмәдәге кебек асылмалы түгел, өстәлгә утыртылган унбишле озынча лампа иде.

— Әйдә, апаң белән янәшә утыр,— дип, дәү апа Габдулланы Газизә апасы янына утыртты һәм аңа тәлинкә тутырып токмач салып бирде. Өстәл тирәсендә дәү апа белән Газизәдән тыш тагын ниндидер ике яшь һәм бер картрак хатын ашап утыралар иде.

Ашаган арада Габдулладан юл килүләрен, Кырлай һәм Казан хәлләрен, аның авылда укулары турында сораштылар. Габдулла бу бүлмәдә иркенләбрәк һәм теләбрәк сөйләште. Бер сорауны да ул җавапсыз калдырмады. Аны кызыксынып

тыңладылар. Кыяфәтендә, төсендә дәү апасы һәм Газизә апасы белән уртак сыйфатлар таптылар.

— Юк, үги әни күгелҗем күзле иде, Габдулла безнең этигә охшаган,— диде Газизә апасы.

Дәү апасы да аның белән килеште:

— Нәкъ, нәкъ этисе инде: күзләреме дисең, борыннарымы дисең... Шундый калку борынлы иде Мөхәммәтгариф. Чибәр егет булыр, Алла боерса... Шуның артыннан ук ул көрсенеп куйды:

— Әй, хәзер Гобәйдуллам исән булса, менә нәкъ Габдулла белән тиң булырлар иде. Икәү бергәләп сабакка йөрерләр иде,— диде һәм, күңеле йомшап, яулык почмагы белән күзләрен сөртеп алды.

Зур сандык өстенә җәелгән йомшак түшәккә яткач, Габдулла рәхәтләнеп бер киерелеп куйды. Унсигез көнлек уңайсыз, зарыктыргыч юлдан соң бай өйдә, йомшак түшәк өстендә тук әрлән кебек йомарланып ятудан да рәхәтрәк нәрсә бар?!

Менә өстәлдәге утны каядыр икенче якка алып чыгып киттеләр. Габдулла караңгыда, түшәк өстендә үз уйлары белән ялгыз калды. Бүген күргәннәре бер-бер артлы аның күз алдыннан кичте. Аны бай өйгә, тук һәм һәрьяктан канәгать гаилә эченә кабул иттеләр. Яхшы каршы алдылар. Бу каршылауда, ни әйтсәң дә, кардәшлек җылылыгы сизелеп торды. Инде аның үзен кызыктырган төп мәсьәләгә тизрәк ирешәсе калды: яңа мәдрәсәне күрү, яңа хәлфә һәм яңа иптәшләр белән очрашу, яңа китаплар кулга төшерү...

IV

Җаекның атаклы мәдрәсәсенә барыр көн килеп җитте. Әлеге кода абыйның улы Талип, озын муенлы, күтәрелеп тора торган җәлпәк борынлы, уйнак күзле малай, букчасын иңенә кыеклап аскан хәлдә килеп керде. Алдан сөйләшү буенча, ул Габдулланы мәдрәсәгә ияртеп алып барырга тиеш иде. Мәдрәсәдә Габдулланы кай сыйныфка утырту, кайсы хәлфәгә тапшыру мәсьәләсе дә хәл итеп куелган иде инде.

Габдулла, Талипка ияреп, мәдрәсәгә китте. Өйдәгеләр аны һәрберсе үзенчә:

— Тырышып укы, улым, бар!

— Изге сәгатьтә!

— Аллага тапшырдык! — дип озатып калдылар.

Кырлайдан киткән көннән алып, бу мәдрәсә Габдулланың күз алдында әллә нинди серле шәүлә булып балкып торды. Соңга таба ул аның төшләренә керә башлады. Аныңча, бу мәдрәсә, әлбәттә, Кырлайныкы сыман тау битендә инешкә таба авышып утыра торган бер катлы иске агач өй түгел, бәлки, Казанның Күл буе мәдрәсәсе кебек ташпулат. Моның хәлфәсе дә Кырлайның Хәбри хәлфә төсле бишбилле иске бишмәт кигән, бөкрәеп йөри торган мужикка охшаган, ябык чырайлы хәлфә түгел, бәлки, озын мәһабәт буйлы, тулы ак йөзле, сөрмә тарткан җитди күзле, ак бикасап чапан, яшел чалма кигән кеше. Тамак кыру да монда Хәбри хәлфәнеке төсле кәҗә йөткергәндәй кәһ! кәһ! итеп түгел, Ташаяк ярминкәсендәге кәмит алдында зур җиз быргы кычкырткандай, күкрәп чыга, мөгаен...

Һәрхәлдә, Габдуллага бу мәдрәсә юлы зур бер батырлык юлы булып, бу көн бәйрәм көне кебек тантаналы булып тоелды. Бу гади йөреш түгел, балалыктан — олылыкка, бүгеннән киләчәккә батыр бер омтылыш, кыю бер сикереш ясау иде.

Юл өстендә бер төркем бала-чаганың пыр тузып, якагаяка килеп сугышулары Габдулланың уйларын тузгытып җибәрде. Бу сугыш читтән карап торыр өчен никадәр генә кызык булса да, мәктәпкә соңга калудан куркып, Габдулла юлын дәвам иттерергә теләде. Әмма аның юлдашы Талип:

— Кая барасың, мәдрәсә шушы бит инде,— дип, аны шып туктатты һәм ике катлы йортка төртеп күрсәтте. Бу — мәчеттән йөз таяк чамасы ераклыкта, Чаган елгасына караган ярның өстенә салынган нәкъ Габдулла килеп төшкән Галиәсгар бай йорты сыман асты таш, өсте агач һәм зурлыгы белән дә аңардан кайтыш булмаса, бер дә генә артык түгел, искерәк бер йорт иде. Аның яртылаш җимерек агач капкасы аша йортның эче ялтырап күренеп ята, түрдә кечкенә бер катлы йорт һәм сул якта мунчамы — нәрсәнеңдер почмагы чыгып тора, алар артында яр астында туңган Чаган өсте җәелеп ята иде.

Пыр тузып сугышучы малайлар шушы мәдрәсәнең укучылары булып чыкты. Бу дөмбәсләшү, мәктәпнең йозагын фәррашь[1] килеп ачканчы, туңмас өчен һәм вакыт уздыру теләге белән ясала торган көндәлек мажара икән.

[1] *Фәррашь* — мәчет-мәдрәсәне карап торучы, сторож.

Габдулла белән Талип килеп җиткәндә, дөмбәсләшүнең иң кызган чагы булып, шау-шу, кычкырыш, көлеш эчендә кычкырып елау һәм оятсыз сүгенүләр дә ишетелеп куя, борыны җимерелгән бер малай, читкәрәк китеп, зур гына кар кисәге белән борыныннан килгән канны туктатырга тырыша, кан ак кар аша кызарып саркып тора иде.

Талип Габдулланы мәдрәсә йортының эченә алып керде. Габдулла йозак белән бикләнгән ишектән тыш икенче баштарак тагын бер ишек күрде. Анысы ачык иде.

— Әнә теге ишектән кереп булмыймыни?— дип сорады ул Талиптан.

— Юк, анысы ятып укый торган өлкән шәкертләрнең ашханәсе. Аннан үтеп була булуын, тик олы шәкертләр безне анда җибәрмиләр.

Һәм шул сүзне дөресләгән сыман, ишектән нәкъ Габдулланыкы төсле камалы бүрек очып чыкты да ерак түгел генә бәдрәф янындагы бозлавык өстенә барып төште. Аның артыннан, кызарынып, бүртенеп, букча таккан бүрексез малай әрләшә-әрләшә чыгып йөгерде.

— Ашханә аша үтсәң, олы шәкертләр бүрекне, алып, менә шулай тышка ыргыталар,— дип аңлатты бу күренешне Талип.

Ниһаять, фәррәш дигәннәре килде. Ул чандыр, озын буйлы, нәзек кенә калдырып кыркылган сары мыеклы, кечкенә сакаллы кеше иде. Ул килеп йозакны ача башлагач, балаларның бердәм төркеме аны ишеккә китереп кысты. Ул, балалар белән төрткәләшеп һәм әрепләшеп, йозакны бераз вакыт ача алмый торды. Ниһаять, ишек ачылды, һәм балалар ташкыны ишеккә бәреп кереп китте. Фәррәш, агым белән читкә тибәрелеп, аягында чак-чак кына басып кала алды.

Балалар артыннан Габдулла да, Талипка ияреп, сыйныфка килеп керде. Сыйныф кечерәк кенә өч тәрәзәле, тәбәнәк түшәмле бик гади бүлмә иде. Бернәрсә генә Габдулланың игътибарын үзенә тартты: балалар Кырлай мәдрәсәсендәге кебек сәкегә яисә коры идәнгә түгел, бәлки, тәбәнәк кенә тар һәм озын өстәлләр арасына кереп, дүртәр-дүртәр булып тезелеп утыралар. Габдулланың билгеле урыны булмаганга күрә, ул, Талип янына сыенып, бишенче булып утырды. Аны шундук кысрыклап төрткәли башладылар:

— Бар, бар, үз көрсиеңә барып утыр! Кеше көрсиенә килеп тыгылма!

Габдулла шундук ике төрле сабак алды: бердән, бу тәбәнәк озын өстәл «көрси» дип атала, икенчедән, монда бишенче булып утырырга ярамый икән!

Төрткәләү дәвам итте. Талипның:

— Юк, ул яңа шәкерт, ул шушы сыйныфныкы, Галиәсгар байның каенише,— дип, торып аңлатуы да ярдәм итмәде. Габдулланы, бәлки, ай-ваена куймый төртеп чыгарган да булырлар иде, әмма шулвакыт әлеге фәррашның кереп, шау-шуны басар өчен, кулындагы пеше чыбыгы белән шәкертләр өстеннән уңлы-суллы чажлатып, селтәнеп алуы, берничә шәкертнең «Әл-лә-лә-лә!» дип чын күңелдән әрнеп куюлары белән Габдулла мәсьәләсе онытылды.

Кырлай һәм Кушлавыч мәдрәсәләрен күргән Габдулланы бу мәдрәсәнең тәртибе һәм балаларның үзенә мөнәсәбәте гаҗәпләндермәде. Аны теге мәдрәсәләр белән бу мәдрәсә арасында әллә ни аерма юклыгы гаҗәпләндерде. Ләкин ул аерманың бер дә булмавына ышанмады, һәм әле сыйныфка килеп керәчәк хәлфә аның бу турыдагы бөтен шикләрен җуеп ташларга тиеш иде. Ул өйдән үк үзенең Шәпеш хәлфәдә укыячагын белеп килгән иде, шуңа күрә ул, Талипның колагына ятып, шыпырт кына сорады:

— Шәпеш хәлфә кем ул, зур хәлфәме?

Җавап бирү урынына Талип Габдуллага әйләнеп, аңа ни өчендер гаҗәпләнеп карады.

«Шәпеш хәлфәне дә белмисеңме?»— дигән караш иде бу.

Габдулла кызарынды. Ул: «Кояш нәрсә, ул кайсы яктан чыга?» — дигән кирәксез һәм көлке сорау биргән сыман тойды үзен. Димәк, Шәпеш хәлфә ул монда — Җаекта — бик зур кеше, һәм аны белмәү — гаеп! Габдулланың күз алдына тагын хыялындагы әлеге ак бикасап чапанлы, яшел чалмалы, мәһабәт буйлы, сөрмә тарткан күзле, җиз быргыдан күкрәп чыккан тавыш белән тамак кыра торган зур галим килеп басты.

— Шәпеш хәлфә кереп килә!— дип ысылдады кемдер. Сыйныф кинәт тып-тын булды. Ишектән, зур кулларын кая куярга белми, селтәнгәләп һәм аунаклап, Талипның атасы, әлеге кода абзый килеп керде. Габдулла, аптырап, авызын ачып калды:

— Менә кем икән ул Шәпеш хәлфә!

V

— Әнә шәкертебез дә кайтты. Йә, ошадымы безнең мәдрәсә?

— Ошамыйча ни, монда мең чакрымнан килеп укучылар бар. Симидән, Сарытаудан, Гурьевтан... Казанның үзеннән килеп укучылар да бар монда.

— Сиңа нәрсә булды? Ник турсайдың? Малайлар кыйнап кайтардылармы әллә? Әллә хәлфә колагыңны бордымы?

Шундый сүзләр белән каршы алдылар өйдә Габдулланы.

Ул үзенең кичерешен берничек тә аңлата алмады һәм моңа үзе дә гаҗәпләнде: ничек аңлатасың? Аны малайлар кыйнамады, хәлфә кыерсытмады. Ләкин ул кайтып куанып сөйләрлек әйбер дә тапмады. Юк, Кырлай һәм Кушлавыч мәктәпләреннән артык җире юк иде бу мәдрәсәнең. Хәлфәсе белән дә, укыган дәресләре белән дә. Хәтта киресенчә: авыл мәктәпләренә ул ияләшкән, шәкертләре һәм хәлфәләре белән үзләшеп беткән иде. Монда бар да ят; салкын, тупас Шәпеш хәлфә үзе генә ни тора!

Икәү генә калгач, Газизә апасы, энесенең хәлен төшенеп булса кирәк:

— Күнегерсең әле, күгәрченем, ияләшмәгәннеке ул,— дип, аның башыннан сыйпап куйды.

Дөрес, кеше вакыты белән бар нәрсәгә дә күнегә. Ләкин Габдулла өчен бу мәктәпкә ияләшү авыр булды. Шәпеш хәлфәгә ул бөтенләй ияләшә алмады. Эш Шәпеш хәлфәнең усаллыгында да, аның балаларны суккан чагында өзеп ала торган, очына агач шакмак таккан камчысында да түгел иде. Әгәр бөтен дөнья хөкеме алдында Шәпеш хәлфә чыгып: «Мин балаларга башка хәлфәләрдән артыграк кул якканым юк»,— дип ант итсә, ул хаклы булыр иде. Шундый заман иде бу, кыйнамый укыту укытуга саналмый, аталар балаларын мәктәпкә: «Хәлфә, мә, ите сиңа, сөяге миңа!»— дип китереп тапшыралар иде.

Шәпеш хәлфә шәкертне кыйнаудан битәр кыйнамый гына үзәгенә үтә белә, һәм ул моның тиңе юк остасы иде.

— Якуб, Шакир, чыгып басыгыз,— дип, әкрен генә боерык бирә ул сабагын тыңлата алмаган шәкертләргә. Ике шәкерт, чыгып, бер-берсенә каршы басалар,— аларны ничек басарга өйрәтәсе юк, алар өйрәтелгәннәр.

— Якуб, ялтырат Шакирның яңагына берне! Күзләреннән утлар күренсен! Кызганып суктың, Шакир! Яле, син ничек

сугарга кирәклекне күрсәтеп бир! Менә шулай! Йомшак суккан өчен тагын берне! Якуб, белдеңме инде ничек сугарга кирәклекне? Яле, Шакирның үз яңагына! Киерелебрәк, киерелебрәк! Менә шулай! Менә шулай! Ай, рәхмәт! Якуб, хәзер син җавап бир! Җавабың сөаленнән (соравыннан) катырак булсын.

Менә шулай ясалма рәвештә ярсытылган ике шәкерт, ниһаять, йөрәкләренә тулышкан әрнүне кая куярга белми, үкереп елап җибәрәләр. Хәлфә, аларның әрнүенә рәхәтләнеп, зур кулларын тезләренә ышкый-ышкый ләззәтләнгән хәлдә, тамашаны карап тора. Әгәр дә ул урта йөзләрдә туып, тәхеттә утыручы булган булса, үзенең колларын цирк мәйданына чыгарып, аларның бер-берсен канга батыруларыннан рәхәт табар иде.

Һәм Шәпеш хәлфәнең бу шәкерт җәзалап ләззәтләнүе һәр көн диярлек кабатлана бирә.

Соңгарак Габдулла мәдрәсәдәге биш хәлфәдән иң астыртыны һәм иң мәкерлесе, шәкертләр тарафыннан иң сөелмәгәне шушы Шәпеш хәлфә икәнен белде. Тора-бара ул, олыраклардан ишетеп, Шәпеш хәлфәнең барлык хәлфәләр арасында иң наданы икәнен дә белеп алды. Ләкин гаҗәп: мәдрәсә ачылганнан бирле монда никадәр мөгаллим килеп китте, китмәгәнен китәргә мәҗбүр иттеләр, бу — кала бирде. Ничек? Мәсьәлә ачык: шәкертләрне укыта белүдән бигрәк, аларны каты кул астында тота белү монда әһәмиятлерәк санала, ә Шәпеш «тота белә» иде. Шуның өчен аның кай елларны, байлар тарафыннан ялланып, бәдәлче хаҗи булып Гарәбстанга китүен һәм мәдрәсәдә яртышар ел югалып торуын кичерәләр, белә торып, аның... әфьюн белән мавыгуын да сизмәмешкә салышалар иде.

Ләкин Габдулла өчен иң авыры бу түгел иде әле. Мәсьәлә шунда ки, үзенең мәдрәсәдә яшәве өчен кемгә, нинди байга һәм нинди көчле куллы кешегә бурычлы булса, Шәпеш моның рәхмәтен тегеләрнең балаларына мөнәсәбәте белән кайтара килде. Андый балаларның ул сабак белмәүләрен дә, шуклыкларын да сизмәмешкә салынды, аларга төшәргә тиеш җәза һәм шелтәне дә икенчеләргә күчерде. Галиәсгар бай Шәпешкә, бердән, кардәш, икенчедән, аның мәдрәсәдә яшәвенә иң нык таяныч булып килде. Ә Габдулла — Галиәсгар байның кардәше. Бу — мәсьәләне хәл итте. Шәкертләрнең иң сөймәгән кешесе, аларның тән һәм җан палачы Шәпеш Габдулланы үз канаты астына алды.

Бу берьюлы шәкертләрнең күпчелеген Габдуллага каршы аякландырды, хәтта Талип, Шәпешнең үз улы, Габдулладан

ераклашты. Ник дисәң, Талип үз әтисен яратмый иде. Башка балалар Шәпешнең шакмаклы камчысы һәм мыскыллауларыннан өйләренә кайтып котылалар, Талип аңардан өенә кайтып та котыла алмый иде бит!

Иптәшләренең, алар белән бергә Талипның (Габдулла аңа иярләшеп килә иде инде), кырыс мөнәсәбәте Габдулланы бөтенләй ялгыз калдырды. Бөтенесеннән авыррак кичерде ул моны. Бу борчылу, Кырлайны, Казанны сагыну тойгылары белән кушылып, Габдулланың күңелен әзме әрнетте, һәм ачы яшь аның күзләрен әзме томалады! Нинди бәхетсез ул хәзер! Шәпеш аны яклап чыккан саен, Габдулланың аңа җен ачуы кузгалды, ул аңа һаман дошманлаша барды.

Кырлайның ябык кына чырайлы, бөкрәя төшкән, кәҗә кебек кәһ! кәһ! итеп тамак кыра торган Хәбри хәлфә, Габдулланың башлап телен ачкан яхшы күңелле хәлфә, кайда ул хәзер, кайда?! Ничек, ничек аны күрәсе килә хәзер Габдулланың! Нинди әйбәт хәлфә булган, ничек Кырлайда чагында аның кадерен белмәгән ул!

Кырлайдан, Сәгъди абзыйлардан, Кушлавычтан, Гайшә апалардан, Яңа Бистәдән, Вәли абзый белән Газизә ападан аерылып, мең бәлаләр белән Җаекка килү, күргән җәфалар, аерылу үкенечләре — һәммәсе, һәммәсе Габдуллага бушка бирелгән корбаннар булып күренделәр. Шулхәтле аның Кырлайдан китәсе, Казаннан аерыласы килмәгән иде бит! Ләкин Җаек һәм андагы зур мәктәпкә кереп уку хыялы барын да җиңде. Һәм менәтерә сиңа нәрсә килеп чыкты?!

VI

Ләкин шуңа да карамастан хәлфәнең «менә тушыннан тушында хәтле» дип биргән сабакларын Габдулла һәрвакыт төгәл хәзерләп килде, чатнатып тыңлатты, ярты кыштан гына тотынуына карамастан, сыйныфта иң алдынгы шәкерт булып китте. Билгеле, эш хәлфәдә түгел иде, әлбәттә. Шәпеш дөньяда бер кешене дә белемле ясамады. Аңардан укыган шәкертләр үзе шикелле томана, дорфа булып чыктылар, адәм рәтле эшкә ярамадылар. Габдулланың үз тырышлыгы, укуга һәм китапка булган үз һәвәслеге ярдәм итте монда. Ләкин Габдулланы болай да үз канаты астына алган Шәпеш аның алдынгылыгы белән үсенеп китте. Урыны чыкса-чыкмаса, шәкертләр алдында да, хәлфәләр алдында да, үзе еш кына йөри торган аш мәҗлесләрендә дә ул Габдулла белән

мактанырга тотынды. Галиәсгар мәчеттәнме, берәр мәҗлестәнме кайтып керсә, каенише белән горурланды:

— Габдулланы хәлфәсе бик мактап торды әле. Имтиханга яңа казаки тектерми булмас үзенә.

Җизнәсенең аның белән горурлануы, ике апасының да моңа куанулары Габдуллага башта бик күңелле булды. Ләкин тора-бара бу хәл үзенең киресенә әйләнде.

Балалар ачуны озак саклап йөрмиләр, балалык — балалык инде ул! Габдулланың да иптәшләре белән арасы төзәлеп килә, кайбере белән ул хәтта дуслашып та өлгергән иде инде. Шәпешнең мактавы, һичшиксез, аны тагы да иптәшләренә каршы куячак. Ни хакы, ни хакы бар аның Габдулла белән мактанырга?! Әйтерсең Габдулланы үзе тәрбияләп үстергән, үзе башлап телен ачкан, үзе, аның күкрәген ачып, аңа үз гыйлемен тутырган! Юк, шатланмады Габдулла бу макталуларга, киресенчә, аны каты эч пошуы басты.

Беркөнне бөтен сыйныфтан ике шәкерт кенә сабакларын әйбәт тыңлаттылар: берсе — Габдулла, икенчесе — Әхмәдулла купец малае Яхъя.

— Басыгыз!— дип, хәлфә бөтен сыйныфны аякка бастырды. Аннан соң ул Габдулла белән Яхъяны алар арасыннан аерып алды да аларга, саф саен йөреп, һәрбер баланың яңагына берәр тапкыр чабып чыгарга кушты. Габдулла аптырап калды. Утызлап баланың күзләре аңа һәм Яхъяга текәлделәр. Аларның һәркайсы белән диярлек Габдулланың көрмәкләшкәне, шаярып дөмбәсләшкәне бар. Ләкин менә монда сиңа каршы торырга мөмкинлеге булмаган иптәшнең бер дә юкка ничек итеп, чынлап, яңагына китереп сугарга мөмкин? Габдулланың күзе Талипка төште. Ул Габдуллага: «Яле, син минем яңакка ничегрәк китереп сугарсың икән?»— дигән сыман, мыскыллы караш ташлап басып тора иде.

— Габдулла, йә!— дип ашыктырды Шәпеш.

Терәлеп торып булмый, бер карарга килергә кирәк иде. Һәм әллә каян үзлегеннән сүзләре табылды:

— Сабакка килгәндә, сала кешесенең чанасы чалулап китте дә иңбашыма китереп сукты. Өзелеп чыктымы дип торам, менә әле дә тоймый,— дип, Габдулла уң кулын асылындырып, чайкап күрсәтте һәм ялганының мондый шома килеп чыгуына үзенең дә исе китте.

Хәлфә, аңа нәрсәдер әйтмәкче булып, ышаныр-ышанмас карап торды-торды да, коры гына:

— Бар, алайса, урыныңа утыр,— диде.

Иптәшләре өстеннән палачлык хезмәтен Яхъяның берүзенә башкарырга туры килде.

Соңыннан иптәшләре дә Габдулланың бу хәйләсен яхшы таптылар. Ә башка көннәрне аңардан аерылып йөри торган Талип бүген мәктәптән Габдулла белән бергә кайтты.

— Син шәп уйлап таптың, әй! Ничек, ничек әле? Чалулап китте дә калак сөягемне сындырып ташлады, дидеңме?

Ул рәхәтләнеп көлде. Габдулланың да күңеле күтәрелеп китте. Алар, юл буе һәр сүздән бер кызык табып, көлә-көлә, шаулашып кайттылар.

Шәпеш белән беренче алыш, шулай итеп, Габдулла файдасына хәл ителде һәм шактый шома гына үтеп китте.

Ләкин икенче алыш шактый җәнҗаллы булды, һәм Габдулла белән хәлфәсенең үзара мөнәсәбәтен бөтенләй өзеп ташлады.

XIII

Габдулла быелгы укуын, «булса да, булмаса да ярый торган» эш итеп, бернинди ашкынусыз каршы алды. Нәрсәгә ашкынсын? Шул ук Шәпеш хәлфә «тушыннан алып тушында хәтле» дип бирелгән йөрәккә ятышсыз сабаклар, шул ук «Хәмдебихәт» белән «Әминтәзәк»ләрне, Гыймади әйтмешли, ач дөя төсле бертуктаусыз күшәү...

Җаекка килгәндәге өметләр һәм хыяллар берәм-берәм юкка чыгалар. Габдулла инде үзенең киләчәген көннән-көн ачыграк күз алдына китерә башлый: менә ул биленә ак алъяпкыч киеп алган да, мичкә башына утырып, чаганнан су ташый. Кайдадыр, кемдәдер хезмәтче малай булып эшли, Гыймади кебек, балта сабы юна-юна, мәдрәсәне сүгә, ә гыйлем алып дәү кеше булу хыялы киштәгә кыстырылган «Әбүгалисина» китабы рәвешендә генә торып кала.

Җитмәсә, аның быел мәктәпкә бергә йөри торган иптәше Талип та юк. Аның урынына ул кем белән иптәш булып мәктәпкә йөрергә тиеш диген? Галекәй белән!

Иртәгә мәктәпкә барам дигән кичне Габдулла шундый күңелсез уйлар белән басылып утыра иде. Өске өйдән Газизә апасы төшеп:

— Габдулла, әйдәле, аккошым, сине җизни чакыра,— диде.

Габдулла өске өйгә килеп кергәндә, Галекәй дә анда иде. Җизнәләре, аларны үз янына чакырып алып, болай диде:

— Балалар, сез иртәгә мәдрәсәдәге сабакларыгыздан соң Әхмәтша хәлфәгә урысча укырга йөри башларсыз. Дөньялык өчен анысы да кирәк. Без менә үзебез, урысча укымагач, прошениеме, адресмы язарга кирәк булса, Әхмәтша учительгә йә судтагы писарьга йөгерәбез. Хәзер муллалар да урысча укый, дөньясы укыта...

Җизнәсенең бу карары Габдуллага шактый сәер тоелды. Былтыр Габдулла русча укырга йөрүне үзе сораган иде. «Сиңа иртәрәк әле!»— дип, аның соравын кире кактылар. Иртәлектә түгел иде хикмәт. Габдулла үз колагы белән ишетте:

— Аксак Әхмәтшага йөртәсегез килсә, башына картус алып киертегез дә аңа гына йөрсен! Мин дин, ислам һәм шәригать кешеләре ясап чыгарырга укытам шәкертләремне,— диде Шәпеш.

Менә моны ишеткәч, Габдулла, җизнәсенең русча укытырга карар итүен белеп:

— Нигә, мин быел кода абыйдан укымыйммыни?— дип, шатлыгын яшерә алмыйча, сорамый булдыра алмады.

— Нигә укымаска?!— дип гаҗәпләнде җизни кеше һәм Габдулланың үз шатлыгын яшерә алмыйча соравын сизеп кызып китте.— Мин сине сабакка кемгә бирсәм, син шуңа йөрерсең, яме? Хәлфә сайлау синең эш түгел. Иң тәкъва, иң укымышлы хәлфәбез ул безнең. Әхмәтша хәлфә дөньялык өчен әйбәт булса, Шәфигулла хәлфә ахирәт өчен әйбәт. Икесе дә кирәк!..

XVI

Бер ай чамасы Габдулла школага авырлык белән йөрде. Икенче һәм өченче ел укучы иптәшләренең русчаны шытырдатып укый һәм яза белүләре, учительнең русчалатып сораган сорауларына рус телендә тоткарсыз җавап бирүләре аны бер яктан сокландырды, икенче яктан кайгыга батырды. Дөрес, ул инде эре хәрефләр белән язылган әлифбаны шактый иркен укый, ләкин учительнең һәм иптәшләренең русча дәшүләренә рус теле белән җавап бирә алмый, укылган җөмләнең сүзләрен бергә оештырып, алардан бер мәгънә чыгарырга көче җитми иде. Бу аны бик-бик ачындырды. Учитель белән русча сөйләшә башлап, җөмләләрне оештыра башлагач та әле ул рус грамматикасындагы родларны берьюлы үзләштерә алмый азап чикте. «Корова пошол» яки «большой лошадь» дип әйтү аның өчен бик табигый иде әле.

Бу родлар мәсьәләсе хәтта шәһәрдә үскән Галекәйгә дә ансат булмады. Ул, Габдулла белән бәхәскә кереп:

— Ты сама ничего не знаешь!— ди торган иде. Ә аңа каршы Габдулла:

— «Ты сама» говоришь. Надо говорить: «Ты сам». Я ведь не дочь твоё...— дип, үзе шундук бер ялгыш ясап ташлый торган иде.

* * *

Язга таба белем ягыннан Галекәйне дә, быел гына укырга кергән иптәшләрен дә узып китте. Моңа аның зирәклеге һәм тырышлыгы нык ярдәм итте. Бервакыт ул, дәрес тыңлатырга аягына баскач, учительдән:

— Карап укыйммы, яттанмы?— дип сорады.

— Белсәң, яттан укып кара,— диде, кызыксынып, учитель.

Габдулла Ушинский шигырен тотлыгусыз яттан укып алып китте:

Дети, в школу собирайтесь,
Петушок пропел давно.
Попроворней одевайтесь,
Смотрит солнышко в окно...

Мактауга бик саран Әхмәтша учитель, Габдулла сөйләп бетергәч, «молодец!» дип куйды, һәм бу бөтен сыйныфны Габдуллага борылып карарга мәҗбүр итте. Габдулла бурлат кебек кып-кызыл булып янып китте. Нигә дисәң, мактауны ишетү һәм бөтен сыйныфны үзеңә карату, рәхәт булу белән бергә, әллә ничек кыен да иде.

— Дәрестән соң миңа керерсең,— диде учитель аңа, русчалатып.

Габдулла учительнең чакыруына кызыксыну катыш каударланып куйды: «Нәрсәгә икән?»

Дәресләр беткәч, ул, учитель кушуы буенча, аның өенә керде. Учительнең квартирасы мәктәпнең түбән катында булып, ишеге баскычтан төшү белән үк сул якта иде.

— Әйдә, уз, Мөхәмммәтгарифов!— дип дәште эчтән Әхмәтша учитель. Ул стена эченә кертеп ясалган кечкенә шкаф янына килде һәм, аның пыяла капкачын ачып, андагы күп кенә эреле-ваклы китапларны актаргалый башлады. Бераздан соң ул тышына буялы рәсемнәр төшерелгән юка гына бер китапны алып Габдуллага тоттырды.

— Менә,— диде ул,— бу — русның зур шагыйре Александр Сергеевич Пушкин язган китап. Бу да бая син укыган әтәч турында, тик бусы инде простой әтәч түгел, алтын әтәч...

Әйтерсең учитель китап тоттырмады, ә канат тагып җибәрде аңар! Ул очынып өенә кайтып җиткәнен сизми дә калды...

* * *

Габдулланың үз гомерендә беренче тапкыр укып чыккан, укып кына түгел, төшенеп укып чыккан русча китабы шушы булды. Ул аны бер генә тапкыр түгел, кат-кат укыды, укыган саен, китап аңа үзенең яңа яклары белән ачыла барды.

— Габдулла акыллым, май бетереп утырма,— дип, Гайниямал аңа кич саен диярлек юкка гына дәште. Габдулла аңа:

— Хәзер, Гайниямал апа, менә әз генә калды,— дип, ятарга вәгъдә итте һәм шундук китап эченә кереп китте дә тагын бөтен дөньясын онытты.

Заманнар үтәр. Галиәсгар байның подвалында яшәгән ятим малай егет булыр, үзе китаплар яза башлар. Шунда ул әтәчнең уяну чорларында никадәр мәгънәви ишарә — символ булып хезмәт итүен, күп кенә халыкларның әдәбият тарихында әтәч, таң иртәсе, кояшның беренче нурлары халыкның йокыдан уянуын күрсәтә торган сурәтләү чаралары икәнен аңлар. Үзенең иҗат биографиясен ул Кольцовтан файдаланып язган «Ник йоклыйсың, мужик?» дигән шигыре белән башлар, үзенең йокыдагы мужикларын таң әтәче сыман үзе уятырга керешер, халык белән бергә:

Таң әтәче кычкырадыр,
Әллә таң ата микән?—

дип җырлар.

Сораулар

1. «Исемдә калганнар» әсәрендә Габдулла Тукай кәни Габдулланың хисләре турында яза. Бер генә җирдә дә аны башка балалардан өстен куймый.
Әхмәт Фәйзи «Кечкенә Апуш» хикәясендә Габдуллага кайсы яктан чыгып бәя бирә?
2. Сезгә кайсы автор тасвирлаган Габдулла ошый: Г. Тукаймы, әллә Ә. Фәйзиме?

ЭЧТӘЛЕК

Кереш 3

Бәя 5
Каршылык 9
Мәгънә 18
Әйтемнәр 20
Мәкальләр 24
Катлаулы каршылык 26
Каршылыкның башка төренә мисаллар. 31
Сыйфат дәрәҗәсе төрләре 36
Мәзәкчәләр 40
Кабатлау алымын өйрәнү 43
Табышмаклар. 45
Метафора. 48
Хис. 59
Әниләргә, әтиләргә мәхәббәт хисе 60
Дуслык хисе 72
Туган илгә мәхәббәт хисе 90
Кешеләрдәге игелеклелек һәм гаделлек кебек әхлак сыйфатларын өйрәнү 100
Мифлар 135
Белемебезне ныгыту өчен күнегүләр 140

Учебное издание

Яхин Альберт Гатуфович (Гатинович)

ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 5 класса
основной общеобразовательной школы
с татарским языком обучения

Издание четвёртое

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатуф улы

ӘДӘБИЯТ

Татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең
5 нче сыйныфы өчен дәреслек

Дүртенче басма

Мөхәррире *З. М. Гыйниятова*
Рәссамы *Т. Т. Фәизов*
Бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вәҗиева*
Техник мөхәррире һәм
компьютерда биткә салучысы *Н. А. Казакова*
Корректорлары *С. З. Гыймалетдинова, А. М. Закирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 04.07.2011.
Форматы 60×90 1/16. Шартлы басма табагы 15,0 + форз. 0,25.
Тиражы 2500 д. Заказ Р-914.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге.
Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете.
Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

КАБАТЛАУ

МАМЫК
ЧАГЫШТЫРУ
16кг

9 785298 020763